# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2021 1(29)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Кириллова З.Н.* Татар милли әдәби теле формалашу чорында тел-стиль чарасы буларак ияртүче теркәгечләр . . . . . . . . . . . 7
*Рәхимова А.Р.* Кешене тасвирлый торган төрки-татар сүзләре: килеп чыгышлары һәм мәгънә үзгәрешләре *(Г. Тукай әсәрләре мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
*Таһирова Ф.И.* Юридик эшчәнлектә татар әдәби тел нормаларын куллану һәм саклау мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
*Мирхәев Р.Ф.* Идел буе һәм Урал төбәге төрки телләренең интерактив картасы (татар, башкорт һәм чуваш телләре) . . . . . . 23

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хасавнех А.Ә.* Суфи шагыйрь Әбелмәних Каргалый иҗатында Сәба шәһәре кешеләре турында Коръән сюжеты . . . . . . . . . . 28
*Закирҗанов Ә.М.* М. Җәлилне өйрәнү фәне: хәзерге торышы һәм бурычлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
*Еникеев И.Ә.* Татарстанда рус телле әдәбиятның милли үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

## Г. ТУКАЙГА – 135

Габдулла Тукайның тууына 135 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
*Надыршина Л.Р.* «Инде эшлик саф, ачык күзләр белән – чын “Аң” белән...» («Аң» журналында Г. Тукай эшчәнлеге һәм аңа бәйле язмалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Юсупова Н.М.* Габдулла Тукай шигъриятендә лирик герой: үсеш-үзгәреше һәм сәнгати үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . 62
*Рәмиев З.З.* Габдулла Тукайның Сәгыйть Сүнчәләйгә хатлары . . 70
*Медведева Л.Ә.* Ә. Урманчиев һәм Г. Тукай . . . . . . . . . . . . . 76
Көлке журналы («Яшен») . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81

## Ф. ӘМИРХАНГА – 135

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Татар халкының рухи һәм мәдәни яңарышында Ф. Әмирхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
*Баттал-Таймас Г.* Параличланган хәлдә 10 ел иҗат иткән әдип Фатих Әмирхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Заһидуллин И.К.* Александр I һәм Казан губернасы . . . . . . . . . 111
*Яруллина Л.И.* Казан сәүдәгәре Апанаев династиясе (XVIII – XX гасыр башы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарлары фольклоры: тарихы һәм бүгенгесе *(«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясе китапларын төзү тәҗрибәсеннән)* . . . . . . . . . . . . . 133

*Хөсәенова Г.Р.* Татар романик дастаннарында Коръәннән килә торган сюжетлар һәм дини мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* 1940–1970 елларда татар телен укыту методикасының торышы *(М.Ш. Галләмова, В.Н. Хангилдин эшчәнлеге мисалында)* . . . . . 150

## СӘНГАТЬ

*Синцова С.В.* Ә. Фәтхетдиновның тирән һәм күпкырлы сәнгати дөньясы турында *(«Өмет» картинасы мисалында)* . . . . . . . . 158

*Ильясова Р.И.* 1960–1970 еллар совет сынлы сәнгатенең яңа парадигмасы чагылышы буларак «6 яшь рәссам күргәзмәсе» (Казан, 1970) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Хуҗин Ф.Ш.* Казан ханлыгының мәшһүр хатыннары турында роман-трилогия (Иванова Ольга. Повелительницы Казани. Нурсолтан. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 495 с.; Повелительницы Казани. Гаухаршад. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 382 с.; Повелительницы Казани. Сююмбика. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 471 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

*Сабитова И.И.* «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» турында (Сәфәров Р.Т., Тимерханов А.Ә., Галимова О.Н. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2019. 156 б.) . . . . . . . . . . . 181

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Кириллова З.Н.* Подчинительные союзы как языково-стилевые средства языка в период формирования татарского национального литературного языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Рахимова А.Р.* Тюрко-татарские слова, характеризующие человека: происхождение и смысловые изменения *(на примере произведений Г. Тукая)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
*Тагирова Ф.И.* Особенности реализации и проблемы соблюдения норм татарского литературного языка в юридической практике . 18
*Мирхаев Р.Ф.* Интерактивная карта тюркских языков Поволжья и Урала (татарский, башкирский и чувашский языки) . . . . . . . 23

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Хасавнех А.А.* Коранический сюжет о жителях города Саба в творчестве суфийского поэта Абульманиха Каргалый . . . . . . . 28
*Закирзянов А.М.* М. Джалиловедение: современное состояние и задачи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
*Еникеев И.А.* Национальные особенности русскоязычной литературы в Татарстане . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

## Г. ТУКАЮ – 135

135 лет со дня рождения Габдуллы Тукая. . . . . . . . . . . . . . . 51
*Надыршина Л.Р.* Обзор деятельности Габдуллы Тукая, связанной с журналом «Аң» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Юсупова Н.М.* Лирический герой в поэзии Габдуллы Тукая: эволюция и художественные особенности . . . . . . . . . . . . . . . 62
*Рамеев З.З.* Письма Габдуллы Тукая Сагиту Сунчелею . . . . . . 70
*Медведева Л.Ә.* А. Урманчиев и Г. Тукай . . . . . . . . . . . . . 76
Сатирический журнал («Яшен») . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81

## Ф. АМИРХАНУ – 135

*Гилязов Т.Ш.* Роль Ф. Амирхана в духовном и культурном возрождении татарского народа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
*Баттал-Таймас Г.* Писатель Фатих Әмирхан: 10 лет творчества в парализованном состоянии . . . . . . . . . . .105

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Загидуллин И.К.* Александр I и Казанская губерния . . . . . . . .111
*Яруллина Л.И.* Династия казанского купца Апанаева (XVIII – начало XX века) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .120

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Фазлутдинов И.К.* Фольклор татар Башкортостана: история и современность *(из опыта создания серии книг «Фольклор татар Башкортостана»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

*Хусайнова Г.Р.* Коранические сюжеты и религиозные мотивы в татарских романических дастанах . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Состояние методики преподавания татарского языка в 1940–1970 гг. *(на примере деятельности М.Ш. Галлямовой, В.Н. Хангильдина)* . 150

## ИСКУССТВО

*Синцова С.В.* Глубина и многогранность художественного мира А. Фатхутдинова *(на примере картины «Өмет»)* . . . . . . . . . 158

*Ильясова Р.И.* «Выставка 6 молодых художников» (Казань, 1970) как отражение новой парадигмы советского изобразительного искусства Татарстана 1960–1970-х гг. . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## НОВЫЕ КНИГИ

*Хузин Ф.Ш.* Роман-трилогия о выдающихся женщинах Казанского ханства (Иванова Ольга. Повелительницы Казани. Нурсолтан. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 495 с.; Повелительницы Казани. Гаухаршад. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 382 с.; Повелительницы Казани. Сююмбика. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 471 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

*Сабитова И.И.* Об орфоэпическом словаре татарского языка (Сәфәров Р.Т., Тимерханов А.Ә., Галимова О.Н. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2019. 156 б.) . . . . . . . . . . . 181

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 81’367.634=811.512.145

*З.Н. Кириллова*

# ТАТАР МИЛЛИ ӘДӘБИ ТЕЛЕ ФОРМАЛАШУ ЧОРЫНДА ТЕЛ-СТИЛЬ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР

Данная работа посвящена исследованию сложноподчиненных предложений, образованных при помощи подчинительных союзов на материале литературных произведений и статей, относящихся к периоду формирования татарского национального литературного языка (конец XIX – начало XX вв.). Автором были проанализированы союзы, которые вводят придаточные причины *(чөнки, чөн, чөнкем, зира // зирә, мадам ки),* времени *(чөн),* условия *(әгәр, гәр, кашки // кяшки, бәртәкъдир, бәрфараз, мәвадә*), уступительности *(гәрчә, әгәрчә),* образа действия или сравнения *(гүя, гүяки, санки, санкем),* а также союз *ки,* образующий разные виды придаточных предложений. Часть подчинительных союзов являются архаичными для современного татарского литературного языка и сохранились лишь в огузской группе тюркских языков.
**Ключевые слова:** подчинительный союз, сложноподчиненное предложение, татарский язык, тюркские языки, архаичная форма.

This work is devoted to the study of complex proposals formed with the help of subordinate unions based on literary works and articles related to the period of formation of the Tatar national literary language (late XIX – early XX centuries). The author analyzed conjunctions that introduce subordinate reasons *(chənki, chən, chənkem, zira // zirə, madam ki),* time *(chən),* conditions *(əgər, gər, qashki // kyashki, bərtəkədir, bərfaraz, məvadə)*, concession *(gərchə, əgərchə),* mode of action or comparison *(gүya, gyaki, sanki, sankem),* as well as the conjunction ki, which forms different types of subordinate clauses. Some of the subordinate conjunctions are archaic for the modern Tatar literary language and have survived only in the Oghuz group of Turkic languages.
**Keywords:** subordinate conjunction, complex sentence, Tatar language, Turkic languages, archaic form.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы – күп гасырлар дәвамында формалашкан татар язма тел традицияләре халык теле белән кушыла барган, тел үзенчәлекләре ягыннан гаять зур төрлелеккә ия булган чор. Әлеге төрлелек шул чорда иҗат иткән язучыларның әсәрләрендә дә ачык чагылыш таба.

Ияртүче теркәгечләрне тикшерү чыганагы итеп түбәндәге татар язучыларының әсәрләре алынды: З. Бигиев, Р. Фәхретдинов, Г. Чокрый, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдев, З. Һади, Ә. Кормаши, К. Насыйри, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Дәрдмәнд һ.б. Шулай ук Ф. Кәрими сәяхәтнамәләре һәм Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан мәкаләләре дә тикшеренү өчен материал

хезмәтен үтәде. Шуны да искәртеп үтик: Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм Г. Исхакый иҗатларында ияртүче теркәгечләрнең кулланылу үзенчәлекләре аерым мәкаләләрдә чагылыш тапты [Кириллова, 2016, 2017, 2018].

Татар милли әдәби теле формалашу чорында теркәгечләрнең иярченле кушма җөмлә төзү үзенчәлекләре буенча без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. XIX йөз ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә иң күп кулланылганы – барлык төр иярчен җөмләләрне дә диярлек төзүдә катнашкан, ләкин күбрәк стилистик мәгънә белдерү өчен хезмәт иткән *ки* иярүче теркәгече [Закиев, с. 456; Зәкиев, б. 257; Татар грамматикасы, б. 359]. Әлеге теркәгеч кергән җөмләләр арасында иярчен ия, тәмамлык, хәбәр һәм күләм җөмләле төзелмәләр зуррак урын алып тора. Мәсәлән: *Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам* (Г. Тукай). *Белмидер ки, тәкъдирнең каләме адәм үзе улып, тәкъдирне язып йөрегәнен* (З. Һади). *Адәмнең табигате шөйләдер ки, мәнфәгатен күргән кешегә мәхәббәт итәр вә зарарын күргән кешегә рәнҗер* (К. Насыйри). *Бу уйлар мине шулкадәр ваттылар ки, мин таң атмыйча йокыга китә алмадым* (Ф. Әмирхан). Мисаллардан күренгәнчә, *ки* теркәгече, хәзерге вакыттагы кебек үк, баш җөмлә составында урын ала. Тикшерелгән чор әдәби телендә шулай ук аның иярчен җөмләдәге теркәгеч сүздән соң кулланылуы да күзәтелә: *Качан ки халык күтәрелде, […] – шуннан соң гына ирек бирелде […]* (Г. Ибраһимов). *Вә никадәр ки Хак Тәгалә сине сәвәр, син ата-анаңны дәхи шөйлә сәүгәйсең вә хөрмәтләгәйсең. […] Бәс, ата-анага итагать кыйлмак фарызлардан бер фарыздыр. Нитәкки (ничек ки) Хак Тәгалә боерыр* (К. Насыйри).

2. Сәбәп мәгънәсен белдергән иярчен җөмләләр төзү өчен, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә *чөнки, чөн, чөнкем, зира // зирә, мадам ки* теркәгечләре кулланыла. Иярчен сәбәп җөмлә хасил итүче *чөнки* теркәгече күпчелек очракта яңа җөмлә башында килә: *Ник йөри мондый вакытта, ник өендә ятмый ул? Чөнки ул – мескин, ятим ул, ятар урын тапмый ул...* (Н. Думави); шулай ук баш җөмләдән өтер белән аерылган иярчен җөмлә составында да урын алырга мөмкин: *[…] бу хатны алгач та, бер минут торма, кайта күр, чөнки Батыргали кода тагын үткән елгы кебек тилерә башлаган, ахры* (Ш. Мөхәммәдев).

Көньяк төрки телләрдә иярчен сәбәп, вакыт һәм шарт җөмләләрне төзүдә катнашкан, хәзерге вакытта исә сәбәп мәгънәсен генә белдерә торган *чүн* теркәгече [Гаджиева, 1973, б. 365; Гаджиева, 1963, б. 69–72] XIX йөз ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә күбесенчә *чөн* формасында кулланыла. Әлеге теркәгеч сәбәп яки вакыт мөнәсәбәтләрен белдерергә мөмкин. Мәсәлән, сәбәп мәгънәсенә мисаллар: *Һәр тараф, һәр җирдә халкың – шул металлның бәндәсе; Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хакыйкать пәрдәсе* (Г. Тукай). *Җавабында диеп, дуслар, чөн аннан сурдыйлар дуслар* (Г. Чокрый). *Чөн*

теркәгеченең иярчен вакыт җөмләле төзелмә хасил итүенә түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *Чөн Печән базары халкы күрделәр, Барча күрешмәк өчен йөгерделәр* (Г. Тукай). *Чөн болар уникешәр яшьләренә керделәр, боларны күргән кеше егермешәр яшендә дип хыял кыйлыр иде* (Ә. Кормаши). Күренгәнчә, *чөн* теркәгеченең иярчен сәбәп җөмлә башында килүе хәзерге телдәге *чөнки* теркәгеченә туры килә, ә иярчен вакыт җөмлә барлыкка китерүче икенче мәгънәсе һәм җөмлә тибы исә хәзерге тел өчен хас түгел.

Төрек, азәрбайҗан һәм төрекмән язма истәлекләрендә урын алган *чүнким* теркәгеченең [Гаджиева, 1963, б. 156] *чөнкем* варианты тикшерелгән чор татар телендә бары Г. Тукай иҗатында гына күзәтелде: *Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм – Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм? (Чөнки азмыни ләззәтле нәрсәләр, ләкин аларның кайсында ләззәт тә кайсында тәм?)* (Г. Тукай).

Сәбәп мөнәсәбәтен белдерү өчен, бигрәк тә XIX гасыр ахыры һәм ике гасыр чиге татар әдәби телендә фарсы теркәгече *зира // зирә* дә актив кулланыла. Нигездә, төрек, азәрбайҗан, гагауз һәм үзбәк телләрендә таралыш алган *зира* теркәгече [Гаджиева, 1973, б. 352; Гаджиева, 1963, б. 157–158] тикшерелгән әдәби әсәрләрдә җөмләләрне бәйләүдә үзе генә яки *ки* теркәгече белән катнаша. Мәсәлән: *Ләкин хатыннарның һиммәте боннан дәхи бәләндтер (артык, бөек). Зира анларның һиммәтләре арсланнардан гайрәтле ирләрне кәнде фәрманнары астында тотарлар* (Р. Фәхретдинов). *Әмма минем суда йөзмәкне үгрәнмәгә күңелем юк иде. Зирәки суга кермәгә курка идем* (К. Насыйри). Мисаллардан күренгәнчә, *зира* теркәгече һәрвакыт иярчен сәбәп җөмләнең башында урын ала.

Гарәп чыгышлы һәм «чөнки, әгәр шулай икән, чынлыкта» мәгънәләрен белдерүче *мадам ки* теркәгече төрек, азәрбайҗан һәм үзбәк телләрендә үтәлгән шарт мәгънәсендәге иярчен җөмләләрне барлыкка китерә [Гаджиева, 1973, б. 360]. Тикшерелгән чордагы әдәби әсәрләрдә әлеге теркәгеч сәбәп мөнәсәбәтен белдерү өчен хезмәт итә, *мадами ки, мадамә ки* формаларында да бирелергә мөмкин: *[...] бу җавапның шафи булмаячагын (файдасы тимәсен) кәндемез дә беләюр идек. Мадами ки, анларда – низам уйләдер: анлар, әлбәттә, таләп итәчәкләр* (Ф. Кәрими). *Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый, мадамә ки ул юк әле, сыйнфый низагларга да иртә* (Ф. Әмирхан). Табылган барлык мисалларда да *мадам ки* теркәгече аналитик иярчен сәбәп җөмлә ясый һәм аны хәзерге телдәге *чөнки* теркәгече белән алыштырырга мөмкин.

3. Иярчен шарт җөмләләрне төзү өчен, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә *әгәр, гәр, кашки // кяшки, бәртәкъдир, бәрфараз* һәм *мәвадә* теркәгечләре кулланыла. Традиция буенча аналитик чара итеп каралса да, хәзерге вакытта синтетик иярчен шарт җөмлә эчендә тикшерелә торган *әгәр* теркәгече тикшерелгән чорда күбесенчә шарт фигыль кушымчасы, сирәк кенә *исә (ирсә)* сүзе белән бергә урын ала. Мәсәлән: *Бала анадан туар ин-*

*сан улып, әгәр дә инсан тәрбиясе бирелмәс исә, калыр хайван улып* (З. Һади). *Әгәр кушсаңыз, баш өсте, ни әйтсәңез, шуны кабул күрәм, итәм* (Ш. Камал).

Фарсы чыгышлы *әгәр* теркәгеченең *гәр* варианты бары шагыйрьләр иҗатында гына табылды, һәм бу кыскарту шигъри юлларның ритм һәм рифма бөтенлеген саклау максатында барлыкка килергә мөмкин: *Илдә бер дуст булмаса гәр*, *Ил бөтен – дошман түгел!* (Дәрдмәнд). *Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр, Шул фәлән атлы кеше кысты диермен сорсалар* (Г. Тукай). Әлеге мисаллардан күренгәнчә, *гәр* теркәгече, *әгәр* кебек үк, өстәмә роль генә үтәп килә.

Фарсы теленнән кабул ителгән, «әгәр дә» мәгънәсен аңлатучы *кашки // кяшки* теркәгече Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдев, Г. Тукай әсәрләрендә һәм Г. Ибраһимов мәкаләләрендә табылды. Мәсәлән: *Кашки бу сөаль укучыларның җөмләсенең күңелләренә килсә иде, мәсьәләнең әһәмияте дәхи артыр иде* (Р. Фәхретдинов). *Аһ! Кашки бу кадәр газаплаганчы, җанымны рәнҗеткәнче, башымны кылыч илә бердән чабып өзсәләр, мең мәртәбә шөкер кылыр идем!* (Ш. Мөхәммәдев). Мисалларда шуңа игътибар итәргә мөмкин: *кашки* теркәгече күп очракта *-са, -са иде* формалы фигыльләр белән кулланыла һәм теләк яки шартка бәйле теләк мәгънәләрен белдерү өчен хезмәт итә.

Шарт мәгънәсен белдергән фарсы-гарәп чыгышлы *бәртәкъдир, бәрфараз* һәм гарәп теленнән кабул ителгән, «әгәр дә мәгәр» дип тәрҗемә ителүче *мәвадә* теркәгечләренә мисаллар аз: *Бәртәкъдир милләтемез үлгән булса, без, үлгән милләтнең башы очында бер кәгазь кисәге булган газеталар шытырдатып, аны уята алырбызмы?* (Г. Тукай). *Мәвадә ул хәрәмгә бирсәләр юл, Үзеңдәй бәгъре канлар тап, әнис бул! (Үзеңдәй бәгъренә кан сауганнарны тап, иптәш бул)* (Дәрдмәнд).

4. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә *гәрчә* һәм *әгәрчә* теркәгечләре иярчен кире җөмләләрне төзү өчен кулланыла. *Әгәр* сүзеннән ясалган *гәрчә* ияртүче теркәгече [Гаджиева, 1973, б. 351] күбесенчә шарт фигыль кушымчасы яки *исә (ирсә)* сүзе һәм *да/дә* кисәкчәсе белән бергә кулланылып, иярчен кире җөмлә ясауда икенчел роль генә үти: *Гәрчә соңыннан Фәхретдин хәзрәтнең указы кайтса да, фәкать Җиһанша хәзрәткә иптәш мулла булды* (З. Һади). Бик сирәк очракта гына *гәрчә* теркәгечле иярчен җөмләнең хәбәре тулы формада була: *Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан, Танып була аны кылган эшеннән* (Дәрдмәнд). *Чөнки картлар егетләрдән артыграк белерләр. Гәрчә егетләрдә бу гадәт бардыр ки, үзләренең белүен картлар белүеннән артыграк күрерләр* (К. Насыйри).

Тикшерелгән чорда бары Дәрдмәнд һәм К. Насыйри әсәрләрендә генә *әгәрчә* формасы күзәтелде: *Кибетчегә биреп, диде, китапны (Әгәрчә дәртләргә дәва бу) [...]* (Дәрдмәнд). *Туган җиремдә үләем димәк лязим килмәс. Әгәрчә ватан икенче анадыр диерләр* (К. На-

сыйри). Мисаллардан күренгәнчә, *әгәрчә* теркәгече аналитик иярчен кире җөмлә ясауда төп рольне уйный. Бары бер мисалда гына әлеге теркәгеч *-са да* формасы белән бергә кулланыла: *Әгәрчә синдә гаклы фирасәт вә һөнәр күрсәм дә, әмма нәсыйхәт тә гакыл бизәгедер* (К. Насыйри).

5. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә *гүя, гүяки, санки* һәм *санкем* теркәгечләре аналитик иярчен рәвеш җөмлә хасил итү өчен хезмәт итәләр. Хәзерге язма әдәби телдә дә актив булган *гүя* бәйләүче чарасы тикшерелгән чорда, нигездә, баш җөмләдән соң урнашкан иярчен җөмләнең башында кулланыла, *ки* теркәгече белән бергә дә килә ала: *Аларны бик сөйкемле кыяфәттә күз алга китерәм. Гүя алар бик шәфкатьле, [...] бик матурлар* (Ш. Камал). *Мостафа илә Фатыйманың да сөенечләреннән башлары гаршегә чыкты, гүя ки бөтен дөнья бонларга ихсан ителде* (Ф. Кәрими).

Тикшерелгән чорда бары Дәрдмәнд һәм Г. Тукай әсәрләрендә генә *санки* һәм *санкем* теркәгечләре табылды. *Санки* теркәгече көньяк-көнбатыш төрки телләрдә, шулай ук комык телендә чагыштыру мәгънәсен белдергән иярчен җөмләләр төзүдә катнаша [Гаджиева, 1973, б. 363]. Табылган мисаллардан Г. Тукай шигырьләрендә һәм Дәрдмәнднең истәлек-парчаларында охшату-чагыштыру мәгънәсе *санки* теркәгече ярдәмендә белдерелә: *Бар күңел хәдсез (чиксез), хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы, Санки күңлең җиргә күктән иңгүче рәхмәт юлы* (Г. Тукай). *Иске чапан белән керле чалма күргәндә, күз чиркәнә, күңел имәнә, санки үлек белән каберлек күргән кебек буласың!* (Дәрдмәнд). «Хәят» шигырендә исә Дәрдмәнд *санкем* теркәгечен куллана: *Санкем угыл-кыз туен итмәктә ул, кызган уен, Йөгрешеп, курчак төшеп менмәктә ак бармагына* (Дәрдмәнд). Күренгәнчә, *санки* һәм *санкем* теркәгечләре, иярчен рәвеш җөмлә барлыкка китереп, аның башында да, уртасында да килергә мөмкиннәр.

Йомгаклап әйткәндә, татар милли әдәби теле формалашу чорында хәзерге әдәби телдә дә актив булган *чөнки, ки, әгәр, гәрчә, гүя* ияртүче теркәгечләре белән беррәттән, аларның күпсанлы архаик вариантлары да кулланыла: *чөн, чөнкем, зира // зирә, мадам ки, кашки // кяшки, гәр, әгәрчә, бәртәкъдир, бәрфараз, мәвадә, санки* һәм *санкем.* Тикшерелгән чор татар әдәби телендә күпчелеге фарсы яки гарәп чыгышлы әлеге теркәгечләрнең зур урын алуы халыкчан тел формалашу процессында гарәп, фарсы һәм госманлы төрек теле элементларының да саклануы һәм көчле йогынтысы белән аңлатыла.

## Әдәбият

*Гаджиева Н.З.* Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков. М.: Наука, 1973. 408 с.

*Гаджиева Н.З.* Синтаксис сложноподчиненного предложения в азербайджанском языке (в историческом освещении). М.: Изд-во АН СССР, 1963. 220 с.

*Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. III. Синтаксис. Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. 576 с.

*Зәкиев М.З.* Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2005. 399 б.

*Кириллова З.Н.* Г. Тукай иҗатында архаик ияртүче теркәгечләр // Габдулла Тукай и тюркский мир: Материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая (25 апреля 2016 г.). Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 238–242.

*Кириллова З.Н.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә ияртүче теркәгечләр // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: Материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 2017. Б. 170–174.

*Кириллова З.Н.* Г. Исхакый әсәрләренең тел үзенчәлеге: ияртүче теркәгечле җөмләләр // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: Материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки. Казань: ИЯЛИ, 2018. Б. 230–234.

*Татар грамматикасы*. Т. III / баш мөх. М.З. Зәкиев. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. 512 б.

***Кириллова Зоя Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***А.Р. Рәхимова***

# КЕШЕНЕ ТАСВИРЛЫЙ ТОРГАН ТӨРКИ-ТАТАР СҮЗЛӘРЕ: КИЛЕП ЧЫГЫШЛАРЫ ҺӘМ МӘГЪНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ (Г. Тукай әсәрләре мисалында)

В настоящей статье анализируются тюркские лексемы *чын* «настоящий», *карак, угры* «вор, разбойник», *чибәр* «хороший», *үксез* «ребенок, лишившийся матери» и *таңчы* «восторженный почитатель», используемые при характеристике человека, встречающиеся в поэтических произведениях великого татарского поэта Габдуллы Тукая (1886–1913). Изучая язык произведений, можно проследить определенные этапы исторического развития лексики. Конечным результатом нашего исследования является определение особенностей формирования и развития лексики литературного татарского языка в первой четверти XX века, в рамках конкретной тематической группы, а именно лексики, характеризующей человека.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, тюркские языки, древнетюркские корни, тематическая лексика, язык Тукая.

This article analyzes the Türkic lexemes *chyn* “real”, *karak, ugry* “thief, robber”, *chibur* “good”, *ksez* “child who has lost his mother” and *tanchy* “enthusiastic admirer”, used in characterizing a person, found in the poetic works of the great Tatar poet Gabdulla Tukay (1886–1913). Certain stages of the historical development of vocabulary can be traced while studying the language of works. The final result of our research is to determine the features of the formation and development of the vocabulary of the literary Tatar language in the first quarter of the XX century, within a specific thematic group, particularly the vocabulary that characterizes a person.

**Keywords:** Tatar literary language, Turkic languages, ancient Turkic roots, thematic vocabulary, Tukay language.

Бу мәкалә Габдулла Тукай әсәрләрендә кешене тасвирлау өчен кулланылган сүзләргә күзәтү ясау нәтиҗәсендә язылды. Чыганак китап булып Ленар Шәех әзерләгән һәм кереш сүз язган шигырьләр җыентыгы хезмәт итте [Тукай, 2013]*.

Г. Тукай әсәрләренең лексикасын өйрәнүебезнең максаты XX гасырның беренче чирегендә татар әдәби теле лексикасының формалашу һәм үсеш үзенчәлекләрен аерым бер тематик лексика – кешене тасвирлый торган сүзләр – мисалында күзәтүдән гыйбарәт. Шагыйрь әсәрләренең сүз байлыгы татар тел галимнәре тарафыннан инде шактый өйрәнелгән. Иң элек, Йолдыз Вәлитованың 1960 елларда язылган хезмәтен күрсәтергә кирәк. Ул Г. Тукай иҗатында кулланылган

* Алда мисаллар китерелгәндә, бу җыентыкның бит саны гына күрсәтеп барылачак (А. Рәхимова).

гарәпчә һәм фарсыча алынмаларны өйрәнүгә багышланган [Валитова, 1966]. Аннан соң да аерым мәкаләләрдә әдипнең фәлсәфи фикерләрен туплаган гыйбарәләр, стиль үзенчәлекләре һ.б. чагылыш тапкан [Хаков, 1970; Мәхмүтов, 1984; Нәбиуллина].

Габдулла Тукай – татар әдәби теле үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Ул үзенең әсәрләрендә аңлаешлы һәм халыкчан тел куллана. Иҗатының баштагы чорында ул шактый чуар тел кулланган, гарәп-фарсы алынмалары да бик күп булган иске татар һәм госманлы төрек телләре йогынтысында иҗат иткән. Й. Вәлитова билгеләп үткәнчә, шагыйрьлек осталыгы һәм халык улы булу хисе арта барган саен, Г. Тукай чит телләр тәэсиреннән, искергән гыйбарәләрдән, китап теле сүзләреннән арынып, телен халык сөйләменең җанлы бизәкләре белән баета барган [Валитова, с. 92].

Әлеге мәкаләдә төрки чыгышлы татар лексемаларын тикшерү максаты куелды. Шагыйрьнең кешене тасвирлауда кулланган сүзләре шактый күпсанлы, аларның һәммәсенә дә ясалган күзәтүне мәкалә кысаларына сыйдыру мөмкин түгел. Шул сәбәпле, араларыннан иң үзенчәлеклеләре, татар әдәби теле сүз байлыгының үсеш-үзгәреш дәверләре чагылыш тапканнары арасыннан берничә сүз сайлап алынды. Тикшерену барышында, сүзләр башка төрки телләрдә, борынгы төрки язма истәлекләр телендә очраган вариантлары белән чагыштырылды, монгол теленең сүзлек байлыгы да исәпкә алынды.

Кешене тасвирлаганда, Г. Тукай бик еш *чын* сүзен кулланган: *Бармыни бездә, гомумән,* ***чын кеше*** *кадерен белү?* [б. 41]; *Юк янымда* ***чын кеше****...* [б. 462]; *Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә / Күп саташтырдык рәзил шәйтанны* ***чын инсан*** *белән* [б. 415]. Бу сүз ‘хаклык, дөреслек; дөрес, дөреслеккә туры килә торган; ясалма булмаган’ кебек мәгънәләрдә күп кенә төрки телләрдә кулланыла: башк. *ысын*, кырг. *чын*, алт. *чын*, хак. *сын*, тув. *шын*, үзб. *чин*, уйг. *чин*. Билгеле булганча, гарәп-фарсы телләренең йогынтысын күрмәгән Себер-Алтай төрки телләрендә күп кенә борынгы сүзләрнең мәгънәләре һәм кулланылыш өлкәләре күпкә киңрәк. Мәсәлән, алтай телендә *чын* сүзенең *чындык* ‘гаделлек, дөреслек’: *чындык учун* ‘дөреслек өчен, гаделлек хакына’, *чын айт-* ‘дөресен әйтү’ («*Чын, чын, чын әйтәм / Чын әйтәмен, аппагым*» дигән халык җыры искә төшә, димәк, татар телендә кайчандыр кулланылышта булып та тарайган) шуңа дәлил булып тора. Комык телендәге *чинк/чинг* ‘иң, иңиң’ сүзе дә килеп чыгышы буенча әлеге *чын* сүзе белән бәйле булырга тиеш. Күзәтүдән күренгәнчә, *чын* сүзе төрки телләрнең угыз төркемендә, шул исәптән төрек телендә дә очрамый. Тик Шәмсетдин Саминең «Камус-и төрки» сүзлегендә аның калыплашкан сүзтезмәдә очравы турында әйтелә: «*çın* ‘sahih, sadık’; *çın sabah* – sabah sadık: yalnız bu tabirde müstameldir», ягъни «*чын* ‘чын, хак, дөрес’; *чын сабах* ‘чын иртә’: бары тик бу гыйбарәдә генә кулланыла» [Sami, 1996, s. 533]. Шул ук угыз төркеменә кергән төрекмән теле исә, бу мәсьәләдә искәрмә тәшкил итә: биредә *чын* ‘хаклык, дөреслек; чын, хак, дөрес’,

*чын сөз* 'дөрес сүз', *чынымы айтсам* 'дөресен әйткәндә', *чын дост* 'чын дус', *чын йүрекден* 'чын йөрәктән' һ.б. рәвешендә кыпчак һәм карлук төркеме телләрендәгечә актив кулланыла. Биредә гаҗәпләнергә урын юк, чөнки төрекмән теле, гомумән, үзендәге угыз-кыпчак шәкелләренең катнашлыгы, борынгы күренешләрнең саклануы белән угыз төркемендә аерым урын биләп тора. Хәзерге монгол телендә *чин* сүзе «нык, какшамас» дигәнне аңлата һәм мәгънәсе буенча төрки теллардәгегә охшаш сүз тезмәләрендә очрый: *чин зүрх* 'какшамас кыюлык' (зүрх 'йөрәк'), *чин зүрхнээс* 'чын йөрәктән', *чин сүсэг* 'ныклы ышану', *чин үнэн* 'чын хакыйкать' һ.б. шундыйлар. «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә бу сүзнең кытай теленнән кергән булуы күрсәтелгән – *чжень/çin* 'дөреслек, хаклык, чын; дөрес, хак; чын' (Мәхмүт Кашгарый сүзлегеннән (XI гасыр), «Котадгу билиг» әсәреннән (XI гасыр), Уйгурча хокук мәсьәләләренә кагылышлы эш кәгазьләре (XII–XIV гасырлар) кебек борынгы язма истәлекләрдән алынуы искәртелгән) [Древнетюркский словарь, с. 148].

Татар теле үз үсешенең төрле чорларында төрле сәбәпләр белән барлыкка килгән парлы сүзләргә бик бай. «Шүрәле» поэмасында очрый торган менә бу сүзне – *Бер дә шикләнмә, җегет син, мин* ***карак-угъры*** *түгел*... [б. 138] – Г. Тукай үзе кульязмасында ни рәвешле язгандыр, безгә билгесез, хәзер исә, менә шулай парлы сүз кебек языла. Әмма мәгънәсе буенча ул парлы сүз түгел, аннан соңгы җөмләдән сүзләрнең саналып кына китүе, ягъни «*карак та түгел, угры да түгел*» икәнлеге аңлашыла: «*Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугры түгел*». *Карак* һәм *угры* сүзләре икесе дә төрки асыллы сүзләр, тик татар телендә *угры* искергән сүз булып санала, диалект һәм сөйләшләрдә генә яши: *ог, ур* (брб.), *оры* (бгрс., кргл.), *уры* (себ. тат.) «вор» [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 501, 506, 684]. *Карак* әдәби тел сүзе булып санала, ләкин фигыльнең үзен кулланырга кирәк булганда, *урлау* дип әйтелә. Сүз ясалышы тәртибе буенча, *урла-* сүзендә *-ла* дигән фигыль ясаучы кушымча һәм борынгы төрки сүз булган (oğrı «карак, талаучы' [Древнетюркский словарь, 1969, с. 363] *угры* сүзе белән генетик бәйләнештәге *ур* тамыры бик ачык күренеп тора. Күп кенә төрки телләрдә бу сүз нәкъ менә 'урлаучы' мәгънәсендә яши: тув. *оор*, хак. *огыр,* каз. *ұры* 'карак, урлаучы'; ком. *уру* 'караклык, урлау'. Ә инде *карак* хәзерге төрки телләрдә күбесенчә 'талаучы' мәгънәсендә кулланыла: башк., нуг. *карак* 'талаучы', кар. *каракцы/карахчы* 'талаучы; юлбасар', *каракла-* 'талау' һ.б. «Борынгы төрки телләр сүзлегендә күрсәтелгәнчә, *qaraqçı* «талаучы, юлбасар', *qaraqla-* 'талау' [Древнетюркский словарь, 1969, с. 425]. Моннан тыш, шул ук тамырдан булуы аңлашылган тагын бер сүз бар: *qarma* 'талау', *qarmala-* 'таларга, юл басарга' [Древнетюркский словарь, 1969, с. 428]. Бу сүзләрне чагыштырып, шуны әйтә алабыз: борынгы *кар-* тамыры 'талау' мәгънәсендәге борынгы сүз булып, *карак* шул тамырдан ясалган булырга тиеш. Шул рәвешле, тел үзенең тарихи үсешендә кызыклы үзгәрешләр кичергән булып чыга: борынгы төп

мәгънәсе ‘талаучы’ булса да, *карак* сүзен ул ‘урлаучы, урлашучан’ кешене атау өчен куллана башлаган, ә фигыль үзе исә, *урлау* рәвешендә кереп урнашкан; талау белән шөгыльләнүчене *юлбасар* кебек ясалма сүз белән атый башлаган. Иң кызыгы: эчтәлектән аңлашылганча, әдип бу ике сүзнең дә мәгънәсен бик ачык белгән. *Угры* сүзенең телдән төшеп калуы һәм ясалма сүз белән алышынуы Г. Тукайдан соңгы чорда булган, дип фаразларга мөмкин.

Әдәби телнең XX гасыр башыннан дәвам итеп киткән үсеш чорында күп кенә сүзләр, шагыйрь кулланган мәгънәдән читләшеп, телдә шактый сизелерлек үзгәреш кичергән. Мәсәлән, *чибәр* сүзенең хәзерге татар әдәби телендәге мәгънәсе – *бик матур, сөйкемле* (кешегә мөнәсәбәтле кулланыла) [Татарско-русский словарь, 2007, II, с. 573], ә ‘яхшы; яхшы холыклы’ мәгънәләре диалектларда гына калган [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 747]. Г. Тукай исә, үз әсәрләрендә *чибәр* сүзен сөйләшләрдә сакланган мәгънәсендә кулланган, ә бүген әдәби телдә яшәгән мәгънәсе анда бөтенләй очрамый. *Бик матур корылмыш иде тормышы / Яхшы иде, бик чибәр көн күрмеше* [б. 44]; *Алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр* [б. 24]; *Кычкырды ул: «Килче монда, чибәр бала… Акыллы син, шул быргыңны сатчы миңа»* [407]. Галим Рифкать Әхмәтьянов, Л.З. Будагов фикеренә дә таянып, *чибәр* сүзен монгол теленнән алынма дип күрсәтә: монг. *чэгэ-бэр* ‘аклык, сафлык’, *чэгэ, чага* ‘ак, саф» [Әхмәтьянов, 2001, б. 234]. Хәзерге монгол телендә *цэвэр* ‘саф; матур; *күч.* кимчелексез’ дигәнне аңлата. Төрле төрки телләрдә бу борынгы алынма якын мәгънәләрдә кулланыла: тув. *шевер* ‘нәфис, оста»; ком. *чебер* ‘нәфис’, кырг. *чевер* ‘оста, эшкә уңган’, каз. *шевер* ‘оста; булдыклы’. *Чибәр* сүзенең йөз матурлыгы турындагы мәгънәсе бары тик татар һәм башкорт телләрендә генә барлыкка килгән.

Билгеле булганча, Г. Тукай – татар әдәби теле оешуга бик зур өлеш керткән шагыйрь. Ул үз әсәрләрендә татар халкының гаҗәеп бай җанлы сөйләм телен кулланган. Талант иясе булган каләм әһеле телнең сүзлек байлыгын да үстерми калмаган, әлбәттә. Биредә мисалга *таңчы* сүзен китерергә мөмкин. *«Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн – мин аларның **таңчысы!**»* [б. 216] – дип, шагыйрь аны ‘сокланучы, баш июче, хөрмәтләүче» мәгънәсендә куллана. *Таңчы* сүзенең тамыры булган *таң* ‘гаҗәеп; соклангыч’ бүгенге телдә, нигездә, *таң калу, таңга калу* кебек гыйбарәләрдә генә яшәп калган. Ләкин кайчандыр ул бик актив кулланылышта йөргән һәм яңа сүзләр ясаган. Мәсәлән, *тансык* сүзенең тамырында да шул ук сүз ята. *Таң* тамыр сүзенең телдән юкка чыгуы, аның урынына гарәпчә *хәйран* сүзенең кереп урнашуы белән бәйле булса кирәк. Гыйбарәләр шагыйрьнең әсәрләрендә үк янәшә кулланыла башлаган: ***Таңга калсын** тиречеләр, итчеләр…* [б. 219]; ***Хәйран булды** әнкәсе, гыйлем булгач бәбкәсе….* [б. 409]. Әдип кулланган *таңчы* мәгънәсендә хәзерге төрек телендә *hayran* ‘хәйран’ сүзенең кулланыла башлавы шулай ук кызыклы күренеш, димәк, мәгънәне бирүче башка сүз табылмаган. Мәсәлән: *Sen*

*kimin hayranısın?* – Г. Тукайча, *Син кемнең таңчысы?* (русчасы: поклонник), булыр иде.

Г. Тукайның иҗатын күзәтеп, аның телне, сүзләрне тоемлавының гаҗәеп югары дәрәҗәдә булганын күрергә мөмкин. Бүгенге көндә, мәсәлән, *ятим*, *үксез* сүзләре синонимнар буларак кулланыла. Шагыйрь исә, әйтик, *үксез* сүзенең төп мәгънәсе ‘әнисез’ икәнлеген белеп кулланган: *Нишләсен? – Бар бер угыл, бер кыз бала; Әнкәсе киткәч, болар* ***үксез*** *кала. (Ничек аерсын... Шул сәбәптән итә алмыйдыр талак)* [б. 49]. Бу сүзнең тамырында бик борынгы *өг/үг/үк* ‘ана’ сүзе ята (борынгы төрки телдә *ög* ‘ана’ [Древнетюрксий словарь, с. 378].

Шул рәвешле, Г. Тукай әсәрләрендә кулланылган *чын*, *карак, угры*, *чибәр*, *таңчы*, *үксез* сүзләре татар теленең тарихи үсешендә, әдәби тел оешуда барган сүз һәм мәгънә үзгәрешләрен ачык күрсәткән үрнәкләр булып торалар. Төре буенча ясалма булган *кар-ак, таң-чы, үк-сез* лексемаларының тамырында борынгы төрки сүзләр ята. Тарихи үсеш-үзгәреш кичергәндә, татар әдәби телендә *карак* сүзе *угры* сүзенең урынын алган, ә *угры* исә, *ур* рәвешендә кыскарып, фигыль тамырында яшәп калган. *Чибәр* сүзенә ясалган семантик анализ нәтиҗәсе Г. Тукай әсәрләрендә аның борынгырак мәгънәдә кулланылганлыгын күрсәтте. *Таңчы* сүзе исә, шагыйрь тарафыннан иҗат ителгән яңа ясалма сүз итеп бәяләнергә хаклы.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.

*Валитова Ю.А.* Иноязычные элементы в поэтических произведениях Г. Тукая (турецко-огузские элементы и арабские масдары): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1966. 23с.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Мәхмүтов Х.* Тукайның канатлы сүзләре // Социалистик Татарстан. Казан. 1984. 17 июль.

*Нәбиуллина Г.Ә.* «Тукай сүзләре» хакында/ http://flatik.ru/tukaj-szlre-hakinda

Татарско-русский словарь: в двух томах. Т. II. Казань: Магариф. 2007. 726 с.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

*Тукай Г.М.* Актык тамчы яшь: шигырьләр / [төзүчесе һәм кереш сүз авторы Л. Шәех]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 495 б.

*Хаков В.* Мәктәптә стилистиканы өйрәнү. (Г. Тукай әсәрләренең теле һәм стиле). Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 127 б.).

*Sami Şemsettin*. Kamus-i Türki. İstanbul: Çağrı Yayınları, 1996. 1574 s.

***Рәхимова Асия Ризван кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Россия кооперация университеты*
*Казан кооперация институтының гуманитар фәннәр*
*һәм чит телләр кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Ф.И. Таһирова***

# ЮРИДИК ЭШЧӘНЛЕКТӘ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛ НОРМАЛАРЫН КУЛЛАНУ ҺӘМ САКЛАУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Статья посвящена освещению отдельных аспектов функционирования татарского языка в качестве государственного, в частности – его применения в юридической практике. В работе автором поднимается вопрос активности использования татарского языка в данной сфере, доступности осуществления права граждан на родной язык на разных уровнях судопроизводства в Республике Татарстан на примере Интернет-ресурсов. в качестве выводов автором отмечается превалирование использования в судебной практике переводных текстов, что неизбежно приводит к нарушению различных норм литературного языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, юридическая практика, языковая норма, функциональная активность языка.

The article deals with some aspects of functioning of the Tatar language as a state language, in particular its application in legal practice. The author tackles the issue of the Tatar language functional activity in this field, the availability of the exercise of the citizens' right to their native language at different levels of legal proceedings in the Republic of Tatarstan using the experience of Internet resources. As a result the prevalence of the use of translated texts in this field is noted, which inevitably leads to a violation of various norms of the literary language.

**Keywords:** Tatar language, legal practice, language norm, language functional activity.

Теләсә кайсы телнең үсеше һәм яшәеше аның төрле тармакларда кулланылуы белән бәйле. Телне куллану даирәсе никадәр киң булса, аның тармак терминогияләре шулкадәр катлаулырак һәм төгәлрәк, гомуми сүзлек байлыгы зуррак, стилистик мөмкинлекләре киңрәк була. 1992 елда «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителү, әлеге законны гамәлгә ашыру Комитеты, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру советы төзелү татар теленең гамәли кулланылышын киңәйтү өчен гомуми бер этәргеч булды. Шуннан соң иҗтимагый тормышның һәм фәннең төрле тармакларында татар теленә игътибар кискен артты. Мондый игътибар, билгеле булганча, XX гасырның 20–30 нчы һәм 50 нче елларында да булып ала, ләкин озакка сузылмый. Аннан соңгы чорда татар теленең куллану даирәсе фән һәм техника өлкәсендә күпчелек очракта мәктәп дәреслекләре дәрәҗәсендә чикләнеп кала. Ә 90 нчы еллардан башлап татар теленең функциональ мөмкинлекләрен тулырак ачу өчен шартлар туа, татар телендә уку-укыту,

иҗтимагый һәм профессиональ эшчәнлек алып бару, газета-журнал бастыру, тәрҗемә эшен үстерү һ.б. лар өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Ихтыяҗ туу нәтиҗәсендә күп санда башта лексик минимумнар дип аталган кече форматлы сүзлекләр, соңрак тулырак, күләмлерәк һәм югарырак сыйфатлы терминологик сүзлекләр, югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм кулланмалар төзелә һ.б. Хокук өлкәсенә килгәндә, 90 нчы елларда ук юристлар, беренчеләрдән булып, махсус сүзлекләр әзерли [Юридик...; Амиров; Финансово-экономические...].

Шул ук елларда төрле дәрәҗәдәге законнар һәм норматив хокукый актлар татар теленә тәрҗемә ителә башлый. Мәсәлән, Россия Федерациясе граждан кодексын тәрҗемә итү һәм күләме, һәм катлаулылыгы, һәм әһәмияте ягыннан бу юлда иң беренче җитди уңышларның берсе булды. Соңрак та бу эшчәнлек эзлекле рәвештә дәвам итте. Хәзерге вакытта, мәсәлән, җинаять кодексы тәрҗемә ителә.

Суд, прокуратура, хокук саклау органнарында эшләрне татар телендә алып бару һәм карау очраклары 90 нчы елларда шактый еш күзәтелә. Тәрҗемәче буларак, үзебезгә дә әлеге органнарда язмача һәм синхрон тәрҗемә итәргә туры килгәне булды.

Татар теленең хәзерге функциональ кулланылу киңлегенә килгәндә, билгеле булганча, вазгыять соңгы елларда үзгәрде. Бу нисбәттән юридик эшчәнлек тармагы да чыгарма түгел. Әлеге эшчәнлектә татар телен куллану дәрәҗәсен ачыклау өчен, берничә критерийга нигезләнеп анализлап карадык. Моның өчен һәр граждан, һәр гадәти кулланучы өчен ачык һәм иң тиз нәтиҗә бирә торган юл булган Интернет челтәренә мөрәҗәгать иттек. Татар телендә мәгълүмат табу, элемтәгә керү мөмкинлеге, документ үрнәкләре һ.б.ны эзләп карап, әлеге мөмкинлекләрне бәяләдек. Мисал өчен, Татарстандагы суд оешмаларының рәсми сайтларында мәгълүмат русча гына бирелгән. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтында исә барлык мәгълүмат өч телдә – татарча, русча һәм инглизчә бирелгән, телне сайлау мөмкинлеге бар. «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» «Рәсми Татарстан» платформасының бер өлеше булып тора һәм ике телдә эшли. Күрүебезчә, татар теле һәр җирдә дә актив рәвештә һәм бертигез кулланыла дип әйтеп булмый. Әле бу гомуми, стандарт мәгълүмат урнаштырылу-урнаштырылмауга, эзләп табу, куллану мөмкинлеге булу-булмауга карап бәяләү генә. Әгәр гамәлдәге суд документларын тоташ анализлау мөмкинлеге булса, татар телендә төзелгән рәсми кәгазьләрнең саны гомуми документлар саны белән чагыштырганда тагын да азрак булуы ачыкланыр иде.

Югарыда әйтеп үтелгәннәрнең барысы да татар теленең гомуми кулланылу активлыгына карый. Бу без күтәргән мәсьәләнең бер ягы гына. Аның икенче ягы исә – куллануның дөреслеге, татар тел нормаларының саклануы. Бу нисбәттән дә вазгыять канәгатьләндерерлек дип әйтеп булмый. Анализ өчен бу очракта шул ук сайтларда урнаштырылган язмача текстлар алынды. Документларда очраган хатакимчелекләрне гомумиләштереп, түбәндәгечә төркемләп булыр иде:

1) татар теленә хас булмаган конструкцияләр төзү, телдә урнашкан варинтлары була торып, аның урынына башка, ялгыш сүз, гыйбарә яки кушымча куллану: *вазыйфаи затлар*; *вазыйфаи үсеш* [http://aktanysh-rt.ru/news/faktyi-i-kommentarii]. «Телне саклау һәм үстерүнең төп принцибы беренче чиратта телнең үз мөмкинлекләреннән файдалануны шарт итеп куя. Чит телнең сүзьясагыч һәм төрләндергеч чараларын куллану бу принципны тупас бозу булып тора. Гарәп яки фарсы теленнән әзер килеш кергән алынма сыйфатларда гына *-и* кушымчасы урынлы, чөнки ул үз җирлегендә – гарәп телендә гарәп кушымчасы белән ясалган: *сихри, милли, җитди* һ.б. Әмма әлеге сүзләрнең дә кайберләре (мәс.: *фикри, хәяти* һ.б.) искергән, башка вариантлар белән алмашынган булуы сәбәпле, хәзерге татар әдәби телендә стилистик кулланылышы чикле. Гомумән, югарыда әйтелгәнчә, өстенлек һәрвакыт татар калыбында ясалган чараларга бирелергә тиеш» [Сабитова, Сафина, Таһирова, б. 95, 96]. Шулай итеп, *вазифаи зат* түгел *билгеле вазифадагы зат, билгеле вазифа башкаручы зат; вазифаи бурычлар* түгел *вазифасына караган бурычлар, вазифасына кергән бурычлар; вазифаи үсеш* түгел *профессиональ үсеш, хезмәт карьерасы. Мәгълүмати, мәгърифәти, мираси, сәнгати, җәмгыяви* һ.б. сүзләр шулай ук ялгыш;

2) ялгыш калып, ялгыш кушымча белән терминнар ясау: *кырыс җавапчылык каралган* (*җаваплылык* булырга тиеш); *зако́нчалык нигезендә* (*закон нигезендә, закон кысаларында, законга нигезләнеп, законлы рәвештә* булырга тиеш);

3) стандарт тел таләпләренә туры килмәгән стилистик вариантлар, диалектизмнар һ.б. куллану: *мәҗбүри түләүләр һәм санкцияләрне юллап алу; хокукы бозылган өчен компенсация юллау* [http://aktanysh-rt.ru/news/faktyi-i-kommentarii]. Әдәби телдә *юллау* «җибәрү – направить» мәгънәсен белдерә, мәсәлән, *рәсми хат юллау.* Бу очракта исә *эзләү, эзләтү, табу, таптыру,* русча *взыскать* булса, *компенсация түләтү* булырга тиеш;

4) семантик төгәлсезлекләр: тиешле сүз урынына аның ялгыш синонимын яки паронимын куллану: *эшне судта акылга ия (разумный) вакытта карау* очрагында вакыт акылга ия булып чыккан (*акылга муафыйк вакытта карау* булырга тиеш); *гражданка Ә.Д. Шәймәрданова шикаятен карауга алудан баш тарту турында. Баш тарту* кешегә карата кулланылырга тиеш, ә шикаять оешмага бирелә, шуңа күрә *Ә.Д. Шәймәрданова шикаяте карауга алынмау / карауга кабул ителмәү / караудан кире кагылу* булырга тиеш; *тәшкил итү* белән *гыйбарәт булуны*, *ия булу* һәм *хуҗа булуны* бутау очраклары шунда ук карый; *әхлак чыгымнары* русча *моральный ущерб* сүзтезмәсен ялгыш тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Әхлак* сүзе «әдәп – нравственность» мәгънәсен белдерә, шуңа күрә аны бу контекстта куллану ялгыш. *Чыгымнар* сүзе шулай ук урынсыз, чөнки ул «сарыф ителгән акча» мәгънәсен белдерә, ә сүз *зыян* турында бара; шулай итеп, дөресе: *бирәүнең*

*шәхесенә китерелгән зыян, берәүнең дәрәҗәсенә китерелгән зыян* булырга тиеш;

5) төрләндерү, сүз тәртибе һ.б. хаталары: *Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы* (*Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы* булырга тиеш); *аттестацияләнүче --- дәүләт граждан хезмәтенең биләп торган вазифаларына туры килә дип танылды* [https://pravo.tatarstan.ru/tat] (*аттестацияләнүче --- дәүләт граждан хезмәтендә биләп торган вазифаларына туры килә дип танылды* булырга тиеш) һ.б.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, гражданнарга юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә норматив-хокукый актлар төзегәндә, суд документларын алып барганда, гомумән, юридик эшчәнлектә татар әдәби тел нормаларын бозу – шактый еш күзәтелә. Моның объектив һәм субъектив сәбәпләре күп: махсус терминологиянең эшләнеп бетмәве, сүзлекләрнең җитмәве, татар телен тиешле дәрәҗәдә белгән тармак белгечләре, компетентлы тәрҗемәчеләр әзерләү һ.б. Гомумән алганда, тел нормаларын бозу – гомуми күренеш. Ул сөйләмнең темасы яки эшчәнлек тармагы белән бәйле түгел. Ягъни ялгыш очраклар юристларда ешрак, төзүчеләрдә сирәгрәк һ.б. була алмый, алар барлык тармакта да бертөсле. Мәсьәләнең иң мөһим ягы шунда ки, хаталы очракларның барысы да диярлек тәрҗемә ителгән текстларга карый, ягъни тәрҗемәче хатасы булып тора. Икенче урында тармакның эшчәнлеген яктырткан журналистлар килә, юристлар исә хәзерге этапта тәрҗемә ителгән әзер текстлардан файдаланучы булып кала. Димәк, җаваплылык тулысынча тәрҗемәчеләр өстендә булып чыга. Татар телен активлаштыру һәм тәрҗемәчеләр әзерләү юлында күп хезмәт куйган профессор, язучы һәм журналист И.М. Низамов, шундый җитди җаваплылыкны күздә тотып, түбәндәге фикерне әйтә: «...тәрҗемәче хезмәте – иҗади хезмәт, ике телне дә бик яхшы белү, татар теленең төрле стиль, катламнарын нечкә тоемлау, бай мөмкинлекләрен текстның төренә – иҗтимагый публицистик, матур, фәнни, рәсми, эпистоляр әдәбият, аларның язма һәм әйтмә төренә карап, һәркайсының бөтен нечкәлекләрен бик яхшы белеп эш итү өчен аңардан тормыш тәҗрибәсе дә, белем, эрудиция, шулай ук сабырлык, тырышлык та таләп ителә» [Низамов, б. 166]. Суд тәрҗемәчеләрен сертификацияләү хәлне кискен рәвештә уңай якка үзгәртәчәк дип уйлыйбыз. Мәсьәләне хәл итүдә шактый зур өлеш теоретик телчеләр җилкәсенә дә төшә, чөнки тел нормаларының үтәлүен тикшереп, анализлап, төзәтеп тору аларның бурычы булып тора. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре бу юнәлештә дә актив эшләп килә. Мәсәлән, без тармак белгечләре белән бергә күп кенә терминологик сүзлекләр төзүдә автор, редактор яки рецензент булып торабыз, законнар тәрҗемә итүдә һ.б. катнашабыз. Бу хезмәттәшлекнең максаты – төрле тармакларга караган текстларның теле чын татарча булуына ирешү, яңа терминнарда ялгыш калыплар булдырмау, кыскасы, татар телен дөрес чагылдыру.

Күптән түгел басылып чыккан «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге» дә тел нормалары сагында тору бурычыбызны үтәүнең бер күрсәткече дип уйлыйм.

Гомумән алганда, татар теленең функциональ мөмкинлекләре, лексик байлыгы чиксез, иҗтимагый тормышның теләсә кайсы өлкәсенең ихтыяҗларын канәгатьләндерә алырлык потенциалы бар. Өстәвенә ул һәрдаим үзгәреп, үсеп тора. Безнең бурычыбыз исә телнең бу мөмкинлекләреннән мөмкин кадәр тулы файдалану, аңа зыян китермичә, алдагы буыннарга җиткерү.

**Әдәбият**

*Амиров К.Ф.* Русско-татарский юридический словарь: ок. 10 тысяч слов <= Русча-татарча юридик сүзлек: 10 мең сүз чамасы> / К.Ф. Амиров; под ред. Ф.А. Ганиева. Казань: Татар. кн. изд-во, 1996. 103 с.

*Низамов И.М.* Кулланучылар даирәсе өчен квалификацияле тәрҗемәчеләр әзерләүдә төп юнәлешләр // Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы: в 2 частях. Ч. I. Казань: Мастер Лайн. 1999. 212 с.

*Сабитова И.И., Сафина И.Р., Таһирова Ф.И.* Татар теленең кыенлыклар сүзлеге. Казан: ТӘһСИ. 2019. 184 б.

Финансово-экономические и юридические термины: Толковый словарь = Финанс-икътисад һәм юридик терминнар: Аңлатмалы сүзлек / Государственныей Комитет Российской Федерации по высшему образованию; Казанский ордена «Знак почета» Финансово-экономический ин-т; сост.: К.М. Гарифуллин, Н.Г. Хайруллин, Ф.Н. Фаткуллин, Н.К. Гарифуллин, А.М. Ганеев, Ф.С. Зиятдинов, З.А. Ахметьянова, Р.А. Бурганова, М.Х. Ханнанов; [под науч. рук. К.М. Гарифуллина]. Казань: Изд-во Казан. фин.-экон. ин-та. 1996. 220 с.

Юридик атамаларның татарча сүзлеге = Словарь юридических терминов татарского языка / Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгы; Татарстан Руспубликасы Югары Суды; мөх.: Х.Г. Шәрипов, М.М. Мәүлетшин, Ф.А. Ганиев, Ф.Г. Хөснетдинов. Казан: [Б.и.]. 1994. 48 б.

Прокуратура Актанышского района: http://aktanysh-rt.ru/news/faktyi-i-kommentarii (дата обращения: 10.11.2020).

Официальный портал правовой информации Республики Татарстан: https://pravo.tatarstan.ru/tat(дата обращения: 10.11.2020).

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы: https://minjust.tatarstan.ru/tat/ (дата обращения: 10.11.2020).

***Таһирова Фәридә Инсановна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.1

***Р.Ф. Мирхәев***

# ИДЕЛ БУЕ ҺӘМ УРАЛ ТӨБӘГЕ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ИНТЕРАКТИВ КАРТАСЫ (татар, башкорт һәм чуваш телләре)

В статье освещаются результаты реализации проекта «Интерактивная карта тюркских языков Поволжья и Урала (татарский, башкирский и чувашский языки)». Он представляет собой интернет-ресурс, содержащей доступную для широкой общественности научно-популярную информацию об ареале распространения, истории развития и современном состоянии, особенностях фонетической системы, грамматической структуры и основном лексическом фонде тюркских языков Поволжья и Урала, а именно татарского, башкирского и чувашского языков.

**Ключевые слова:** интерактивная карта, тюркские языки Поволжья и Урала, татарский язык, башкирский язык, чувашский язык, ареал распространения, фонетическая система, грамматическая структура, лексический фонд.

The article highlights the results of the implementation of the project "Interactive map of the Turkic languages of the Volga region and the Urals (Tatar, Bashkir and Chuvash languages)". It is an Internet resource containing popular scientific information available to the general public about the distribution area, history of development and the current state, features of the phonetic system, grammatical structure and the main lexical fund of the Turkic languages of the Volga region and the Urals, particularly the Tatar, Bashkir and Chuvash languages.

**Keywords:** interactive map, Turkic languages of the Volga region and the Urals, Tatar language, Bashkir language, Chuvash language, distribution area, phonetic system, grammatical structure, lexical fund.

Идел буе һәм Урал төбәге элек-электән төрки халыкларның тарихи ватаны саналган. Борынгы төрки кабиләләр бу җирләргә б.э.к. I – б.э.ның VIII гасырларында үтеп керә башлаганнар [Фасеев, 1966, с. 809; Языки мира..., 1997, с. 47, 481]. Алга таба алар нигезендә хәзерге татар, башкорт һәм чуваш халыклары формалашкан. Бүгенге көндә бу халыкларның тарихы, теле, мәдәнияте фәндә җентекле өйрәнелгән, әмма шул ук вакытта әлеге өлкәдә гади кешегә аңлаешлы телдә язылган фәнни-популяр әдәбиятның, аерым алганда, электрон ресурсларның җитәрлек булмавы күренә. «Идел буе һәм Урал төбәге төрки телләренең интерактив картасы (татар, башкорт һәм чуваш телләре)» проектының әһәмияте нәкъ менә әлеге момент белән билгеләнә. Аның максат итеп «Интернет» челтәрендә Идел буе һәм Урал төбәге төрки телләре, аерым алганда, татар, башкорт һәм чуваш телләре турында киң җәмәгатьчелек өчен аңлаешлы фәнни-популяр мәгълүматны үз эченә алган электрон ресурс булдыру куелды.

Проект «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының «Татар филологиясе һәм тел белеме өлкәсендә дисциплинаара инновацион фәнни-гамәли тикшеренүләргә, татар теленең функциональ үсешенә һәм тел сәясәтен халыкара лингвистик парадигма контекстында тормышка ашыруга булышлык итү» чарасы кысаларында эшләнде. Үзенең структурасы буенча Идел буе һәм Урал төбәге төрки телләренең интерактив картасы (https://turkicmap.antat.ru) телләрнең таралыш ареалын чагылдырган картаны һәм аларның тарихы, хәзерге торышы, фонетик, морфологик һәм лексик үзенчәлекләре турында фәнни-популяр мәкаләләрдән торган бүлекне үз эченә ала.

Электрон ресурны ачып караган кеше теге яки бу телнең реаль таралыш чикләрен визуаль рәвештә күз алдына китерә алсын өчен, картада аерым төсләрдәге (татар теле өчен яшел, башкорт теле өчен зәңгәр, чуваш теле өчен кызыл) махсус тамгалар белән аларда сөйләшкән кешеләр яшәгән торак пунктлар билгеләнде. Торак пунктта ике яки өч телдә сөйләшүчеләр яшәгән очракта, тамгалар әлеге телләрнең төсләрендәге өлешләрдән торган түгәрәк формасында бирелде һәм аның үзәгендә әлеге торак пунктта кулланылган телләрнең саны күрсәтелде.

Татар, башкорт һәм чуваш телләрнең Идел буе һәм Урал төбәгендә таралыш ареалын ачыклау максатында уздырылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә, әлеге телләрнең һәрберсе аерым-аерым кулланылган бер телле районнар булу белән бергә, гомумрегион масштабында аларның таралыш ареалларының үзара керешеп китүе ачыкланды. Бу күренеш төбәктә гасырлар дәвамында формалашкан этнолингвистик системаның иң мөһим үзенчәлеген тәшкил итә һәм ул үткәндәге катлаулы тарихи процессларның нәтиҗәсе булып тора.

Мәкаләләргә килгәндә, биредә һәр тел буенча биш мәкалә эшләнде. Беренче мәкаләдә татар, башкорт һәм чуваш телләренең килеп чыгышы һәм тарихи үсеше яктыртылды. Моңа кадәр уздырылган фәнни тикшеренүләрдән күренгәнчә, алар үзләренең килеп чыгышы буенча борынгы төрки кабиләләрнең телләренә барып тоташалар һәм үзләренең үсеше барышында берничә этапны узалар. Мәсәлән, татар теле тарихында гомуми планда түбәндәге чорларны аерып чыгарырга мөмкин:

1. Борынгы төрки кабиләләрнең Идел буе һәм Урал төбәгенә үтеп керүе һәм аларның биредәге башка телле халыклар (борынгы иран телле кабиләләр һәм угро-финнар) белән катнашуы (б.э.к. I – б.э.ның VIII гасырлар).

2. Болгар кабиләләренең (болгарлар, суварлар, бортаслар һ.б.) Идел буе һәм Урал төбәгенә үтеп керүе һәм җирле халык (башкортлар, печенеглар, угызлар, хәзәрләр, славяннар һәм угро-финнар) белән катнашуы (VIII–X гасырлар).

3. Идел болгарлары дәүләтенең оешуы һәм көчәюе, җирле сөйләмә койне (телнең, бер яки берничә диалект нигезендә барлыкка

килеп, әлеге диалектлар вәкилләренең үзара аралашуы өчен хезмәт итә торган яшәеш формасы) һәм язма әдәби телнең формалашуы (X–XIII гасырлар).

4. Алтын Урда чоры (болгар, кыпчак, угыз һәм башка кабиләләрнең монголлар тарафыннан яулап алынуы, яңа төрки-татар кабиләләренең җирле халык белән катнашуы, сөйләмә койне һәм язма әдәби телнең яңа сәяси һәм мәдәни шартларда үсеше) (XIII–XV гасырлар).

5. Казан ханлыгы чоры (XV–XVI гасырлар) (татар халкы, аның йомышлы татарлар һәм Казан татарлары дип аталган этнографик төркемнәренең, алар нигезендә гомумхалык теле, аның язма әдәби формасы, көнбатыш һәм урта диалектларының формалаша башлавы).

6. Казан ханлыгының Мәскәү тарафыннан яулап алынуы һәм Урта Идел буе җирләренең рус дәүләте составына кушылуы (XVI – XVII гасырлар) (йомышлы һәм Казан татарларының көнчыгышка яңа җирләргә күченеп утыра, әлеге нигездә татар теленең көнбатыш һәм урта диалектларының бер-берсенә тәэсир итешә башлавы).

7. Россия составына Урал, Себер һәм казакъ җирләрен кушу (XVII–XVIII гасырлар) (йомышлы һәм Казан татарларының яңа җирләрдә таралып урнашуы, андагы җирле халыклар белән аралашып яши башлавы).

8. Хәзерге татар милләте һәм гомуммилли теленең формалашуы (XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы).

Хәзерге вакытта татар, башкорт, чуваш телләренең функциональ үсеше дәрәҗәсенә килгәндә (ул икенче мәкаләдә яктыртыла), аларның өчесе дә үз республикаларында рус теле белән беррәттән дәүләт телләре дип игълан ителгән. Шул нигездә әлеге телләр билгеле бер дәрәҗәдә дәүләт идарәсендә һәм мәгариф системасында кулланыла, аларда уку-укыту, сәнгатьле, публицистик һәм фәнни әдәбият бастырыла, газета-журналлар чыга, радио һәм телевизион тапшырулар алып барыла, театрлар эшли. Ләкин соңгы елларда федераль дәрәҗәдә закон чыгару өлкәсендә барган үзгәрешләр бу телләрнең функциональ үсеш дәрәҗәсенә тискәре йогынты ясый башлады.

Интерактив картада тәкъдим ителгән «Фонетик строй», «Морфологик структура» һәм «Төп лексик фонд» исемле мәкаләләр электрон ресурсны кулланучыларда татар, башкорт, чуваш телләренең аваз үзенчәлекләре, грамматик төзелеше һәм сүзлек байлыгы турында чагыштырма планда күзаллау булдырырга ярдәм итүгә юнәлтелгән. Әлеге бурычны хәл итү юнәлешендә, мәсәлән, телләрнең сузык авазлар системасы аларның барысы өчен дә уртак булган һәм гомумтөрки тел белемендә кабул ителгән түбәндәге критерийләр нигезендә тасвирланды:

1) телнең горизонталь хәрәкәте буенча – арткы рәт (калын) һәм алгы рәт (нечкә) сузыклар;

2) телнең вертикаль хәрәкәте буенча – түбән күтәрелешле, урта күтәрелешле һәм югары күтәрелешле сузыклар;

3) иренләшү (лабиальләшү) һәм иренләшмәү (лабиальләшмәү) буенча – иренләшкән һәм иренләшмәгән сузыклар.

Әлеге принцип алга таба телләрнең грамматик төзелешен һәм төп сүзлек байлыгын тасвирлаганда да кулланылды, ягъни бу очракларда да нигез итеп өч телдә дә чагылыш тапкан грамматик категорияләрнең формалары һәм сүзләрнең тематик төркемнәре алынды. Мәсәлән, исем сүз төркеменең сан, тартым, килеш һәм хәбәрлек, фигыль сүз төркеменең наклонение, сан, зат, юнәлеш, юклык һәм модальлек категорияләре, сыйфат һәм рәвешләрнең дәрәҗәләре, сан һәм алмашлыкларның төркемчәләре турында мәгълүмат бирелде. Төп лексик фонд түбәндәге тематик төркемнәр буенча тасвирланды:

1. Күк җисемнәре һәм күк сферасы: татар телендә *кояш, күк, йолдыз;* башкорт телендә *кояш, күк, йондоҙ;* чуваш телендә *хӗвел, тӳпе, ҫăлтăр* һ.б.

2. Метеорологик күренешләр: татар телендә *җил, буран, аяз күк;* башкорт телендә *ел, буран, аяҙ күк;* чуваш телендә *ҫил, ҫил-тăвăн, янкăр тӳпе* һ.б.

3. Ландшафт һәм су мохите: татар телендә *җир, урман, елга;* башкорт телендә *ер, урман, йылға;* чуваш телендә *ҫӗр, вăрман, шыв* һ.б.

4. Кыргый һәм йорт хайваннары: татар телендә *бүре, төлке, аю;* башкорт телендә *бүре, төлкө, айыу;* чуваш телендә *кашкăр, тилӗ, упа* һ.б.

5. Кыргый һәм йорт кошлары: татар телендә *кош, бөркет, сандугач;* башкорт телендә *ҡош, бөркөт, һандуғас;* чуваш телендә *кайăк, ăмăрт кайăк, шăпчăк һ.*б.

6. Агачлар, куаклар, үләннәр, чәчәкләр: татар телендә *агач, имән, каен;* башкорт телендә *ағас, имән, ҡайын;* чуваш телендә *йывăҫ, юман, хурăн* һ.б.

7. Культуралы үсемлекләр һәм кыяклылар: татар телендә *тары, бодай, арпа;* башкорт телендә *тары, бойҙай, арпа;* чуваш телендә *вир, тулă, урпа* һ.б.

8. Хуҗалык эшчәнлеге: татар телендә *сабан, чалгы, көрәк;* башкорт телендә *һабан, салғы, көрәк;* чуваш телендә *плуг, ҫава, кӗреҫе* һ.б.

9. Юл, транспорт: татар телендә *юл, арба, көймә;* башкорт телендә *юл, арба, кәмә;* чуваш телендә *ҫул, урапа, кимӗ* һ.б.

10. Торак, йорт, мебель, кухня кирәк-яраклары: татар телендә *өй, капка, казан;* башкорт телендә *өй, ҡапҡа, ҡаҙан;* чуваш телендә *пӳрт, хапха, хусан* һ.б.

11. Ризык, ризык әзерләү: татар телендә *ит, май, сөт;* башкорт телендә *ит, май, һөт*; чуваш телендә *аш, ҫу, сӗт* һ.б.

12. Кием-салым, бизәнү әйберләре: татар телендә *кием, каеш, күлмәк;* башкорт телендә *кейем, ҡайыш, күлдәк;* чуваш телендә *тум, чӗн, кӗпе* һ.б.

13. Тән әгъзалары: татар телендә *баш, бит, борын;* башкорт телендә *баш, бит, танау;* чуваш телендә *пуҫ, пит, сăмса* һ.б.

14. Туганлык мөнәсәбәтләре субъектлары: татар телендә *әти, әни, кияү, килен;* башкорт телендә *атай, әсәй, кейәү, килен;* чуваш телендә *атте, анне, кӗрӳ, кин* һ.б.

Йомгаклап әйткәндә, төрки телләр гаиләсенә караган татар, башкорт һәм чуваш телләре, һәм географик планда, һәм эчке структур дәрәҗәдә үзара керешеп, Идел буе һәм Урал төбәгенең үзенчәлекле этнолингвистик системасын формалаштыралар.

**Әдәбият**

Интерактивная карта тюркских языков Поволжья и Урала (татарский, башкирский и чувашский языки) [Электрон ресурс]. Керү режимы: https://turkicmap.antat.ru.

*Фасеев Ф.С.* Краткий грамматический справочник татарского языка // Татарско-русский словарь. М.: Сов. Энциклопедия, 1966. 863 с.

Языки мира: Тюркские языки. М.: Индрик, 1997. 542 с.

*Мәкаләне әзерләү һәм бастыру «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 4.1.3. чарасы кысаларында гамәлгә ашырылды*

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты гомуми лингвистика бүлеге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 7.046.3+82-141

*А.Ә. Хасавнех*

# СУФИ ШАГЫЙРЬ ӘБЕЛМӘНИХ КАРГАЛЫЙ ИҖАТЫНДА СӘБА ШӘҺӘРЕ КЕШЕЛӘРЕ ТУРЫНДА КОРЪӘН СЮЖЕТЫ

В статье дается литературный анализ поэтического произведения поэта-суфия А. Каргалый о жителях города Саба, сюжет которого взят из одноименной коранической суры «Саба». Автор вносит в свое сочинение ярко выраженную авторскую интерпретацию, ряд фантастических элементов в виде «двенадцати особенностей», данных по милости Аллаха, «райских садов» и т.д. В повествовании о жителях города Саба упоминаются вавилонский царь Нимрод, легендарный образ «саламандры», включены и отдельные эпизоды из коранических историй о пророке Мусе. Автор успешно применяет числовые и разного рода иные гиперболы. В отступлениях от основной сюжетной линии татарский поэт призывает читателей почерпнуть для себя уроки, приводит высказывания Дж. Руми и Суфи Аллаяра.

**Ключевые слова**: Абульманих Каргалый, поэт-суфий, коранический сюжет, авторская интерпретация, числовые гиперболы, фантастические детали.

The article provides a literary analysis of the poetic work by the Sufi poet Abulmanikh Qarghaly “Hikayat ath-thalith” (“The Third Story”) based on the Qur`anic chapter “Saba”. Introducing additional aspects of narrative, visionary details as twelve features of Saba city given by Allah`s grace into the story, Qarghaly offers a vivid interpretation to it. He makes reference to Nimrod, King of Babylon, a legendary image of the salamander as well as to some episodes in Qur`anic stories about the Prophet Musa. The use of plenty of various details, images and story lines in “Hikayat ath-thalith” by the Tatar poet adds ethnic colour to it. Hyperboles suggested by Qarghaly make it unique and emotionally expressive. At the same time “Hikayat ath-thalith” presents a utopia, an ideally perfect place common people dream about. Qarghaly focuses attention on ethical problems and in the excursuses urges readers to learn a lesson from the edifying stories.

**Keywords:** Abulmanikh Qarghaly, Sufi poet, Quranic Stories, the author`s interpretation, hyperboles, visionary details.

Иделе-Урал регионы суфи шагыйре Әбелмәних Каргалыйның (1782–1833 тән соң) «Хикәйәт әс-салис» (Өченче хикәят) әсәре, – мөгаен, иң күләмле һәм иң шигъри әсәрләрдәндер; ул 235 бәетне үз эченә ала. Бу әсәр үзе өч цикл хикәятләрдән (хикәяләрдән) тора (алар безнең тарафтан шартлы рәвештә исемләнде): 1) Сәба шәһәре кешеләре турындагы хикәятләр (шартлы исем безнең тарафтан бирелде. – *А.Х.*) – 128 бәет; 2) Шагыйрь сәяхәтнамәсе – 49 бәет; 3) Мәгърифәт һәм сабырлык хакында мөнәҗәтләр. Бу хикәят татар шагыйренең «Тәрҗемәи хажи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» җыентыгына – шагыйрьнең бүгенге көнгә кадәр сакланып калган сирәк китапларының берсенә кертелгән. Китап мөселман изгеләре тормышына



Ә. Каргалыйның «Тәрҗемә-и хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» җыентыгының беренче бите

багышланган борынгы гарәп риваятьләренең шигъри тәрҗемәсеннән гыйбарәт ун хикәяне үз эченә ала.

Ә. Каргалыйның «Хикәйәт әс-салис» (Өченче хикәят) әсәрендә Сәба шәһәре һәм анда яшәүчеләр турында сөйләнелә. Мәгълүм булганча, Сәба, ягъни Сәба патшалыгы – бүгенге көндә Мәгъриб дип атала торган территориягә керә торган, Йәмәннең көнчыгышына урнашкан һәм борынгы мәдәниятькә ия дәүләт. Б.э.к. X гасырда бу дәүләт мәдәниятнең иң югары үсеш дәрәҗәсенә һәм чәчәк атуына ирешкән. Әсәрнең йомгаклау өлешендә автор үзе бу хикәяне «Тәфсире кәбир»дән алуын һәм бер ай дәвамында төрки телгә шигъри тәрҗемә итүен әйтә. Хикәянең сюжеты турыдан-туры Коръәннең «Сәба» дип аталган 33 нче сүрәсеннән алынган.

Мөселманнарның изге китабы әллә ничә буын төрки шагыйрьләр өчен, Ә. Каргалыйның «Хикәйәт әс-салис»ы кебек, шигъри яңгырашы һәм милли колорит белән кабатланмас бик күп әдәби әсәрләр бар итүдә илһам чыганагы булып хезмәт иткән. XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьяр иҗатына багышланган мәкаләсендә Хатыйп Миңнегулов болай ди: «Коръән, дини кануннар нигезендә дөньяга караштa, рухи мираста чагыштырмача уртаклыклар, охшашлыклар туа. Әдип, ул нинди телдә язуына карамастан, бу гомуми хәзинәгә еш мөрәҗәгать итә, үзенең уй-кичерешләрен гәүдәләндерүдә аны теге яки бу дәрәҗәдә файдалана» [Миңнегулов, 1997, б. 6]. Галим фикере буенча, шулай ук «Мөселман дине аеруча әдәбиятта тирән эз калдырган. Күп кенә сюжетлар, мотивлар, образлар “Коръән”нән алынган. Без моны Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Тукай һ.б. бик күп әдипләрнең



Ә.Каргалыйның «Тәрҗемә-и хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» җыентыгының «Өченче хикәят»е («Хикәйәт әс-салис»)

әсәрләрендә ачык күрәбез. Коръән, андагы идея-эстетик байлык татар язучыларын илһамландырган, иҗатларында төп юнәлешне билгеләгән, кешене, тормыш күренешләрен яктыртуда, бәяләүдә идеал, үзенә күрә бер өлге булып хезмәт иткән» [Миңнегулов, 1998, б. 112].

Коръәндә телгә алынган «Сәба» атамасына килгәндә, ул хәзерге Йәмәннең башкаласына карый торган исем, башкала төрле гасырларда төрлечә аталып йөртелгән: «Бәхетле Гарәбстан», «Гарәп Тибеты», «Фатиха алган Көнчыгыш», «Патшабикә Савская җире». Элек уңайлы табигать шартлары белән аерылып торганга, рәхмәтле бу җирләр ел әйләнәсе мул уңыш биргән, кешеләр салкыннан да, эсседән дә, су җитмәүдән дә җәфа чикмәгәннәр, шуңа күрә, әлеге территориянең халкы һәм патшалары һәрвакыт уңышлы һәм житеш тормышта яшәгәннәр.

Коръәннең «Сәба» сүрәсендә телгә алынган ике бакча Ә. Каргалый бәянында «җәннәт бакчасы» дигән исем белән атала; автор аларны җентекле тасвирлый, шунда ук бу бакчалар Гадән бакчалары белән чагыштырыла: *Ике бостан дәхи аның сулыдан, Әйләмешде мисале җәннәт Гадән / Төрлү әсмар илә дулу һәр бере, Бисте чар фәрсәх иде һәм озыны* (6–7 километрга туры килә. – *А.Х.*) [Каргалый, 1889, б. 10].

Шигырьдә сүз бара торган Гадән – Йәмәннең эре диңгез порты. Гадән яисә Асән дигән исемдәге шәһәр әле Борынгы Греция заманнарыннан ук билгеле. Бу шәһәр озак еллар Гарәп ярымутравының беренче санлы базарларыннан саналган, күпләгән сәяхәтчеләр аның байлыгы һәм зиннәтләре хакында сөйләгән.

Суфи шагыйрьнең «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних...»ына кергән беренче хикәяләрендәге кебек үк, әсәргә бик күп уйдырма, фантастик детальләр кертелгән. Автор Коръән сюжетын үстерә кебек; бу идеаль шәһәргә унике үзенчәлек хас. Әйтик, анда яшәүчеләр авырулардан, эсседән, салкыннан берничек җәфа чикмиләр, шәһәрнең һавасы ук шифалы һәм хәтта табиблар дәвалый алмаган бөтен чирләрдән дәвалый; хатыннар бала тапканда йокыга талалар да бернинди авырту сизмиләр; кешеләргә кием тумыштан бирелә һәм гәүдә үскәнгә бәрабәр аның размеры да зурая һ.б.: *Улмаз иде анда һич мош вә чайан, Борча вә чикердә вә бүре, йелан. / Һәм икенче, йук иде анда мәраз, Һәм, өченче, килсә бер сахибе гараз. / Тапмайуб дәрденә дару бер табиб, Йагъни керсә аңа бер хәстә гариб. / Улур ирде шул заманда сыйххати, Уңкар лорды һәм кадими гыйлләти* [Каргалый, 1889, б. 10–11].

Әлеге унике үзенчәлекне санаганнан соң, автор сюжет сызыгыннан читкәрәк китә. Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, ул җир тормышындагы барлык рәхәтлекнең Аллаһ рәхиме һәм шәфкате булуы һәм шушы рәхәтлекләр өчен кешеләр Раббы биргәннең кадерен белергә, Аллаһка рәхмәтле булырга тиешлеге турында фикерләр әйтә. Бу мәгънәдә шагыйрь Урта гасыр төрки әдәбиятыннан ук килә торган традицияләргә тугры кала. Ә. Ясәви (1103–1166), С. Бакыргани (1091–1186), Ө. Камал (XIV гасыр ахыры–1475), М. Колый (XVII гасырның икенче яртысы), Т. Ялчыгол (1768–1838), Ә. Тубыли (1825–1890 нан соң), Ш. Зәки (1825–1865), Һ. Салихов (1794–1867) һ.б. кебек суфи шагыйрьләр Коръән этикасы һәм эстетикасы рухы белән сугарылган әсәрләрендә кеше язмышындагы катлаулы борылышлар турында яздылар. Алар, җирдә барган һәр вакыйга – Аллаһ әмере, дигән фикерне җиткереп, бәхет һәм кайгы, шатлык һәм сагыш, яшәү һәм үлем кебек антитезаларны «Аллаһ язмышы» мотивы белән тыгыз бәйләнештә карадылар.

Ә. Каргалый да бу дөньяда бөтен нәрсәнең Аллаһы Тәгаләгә буйсынганлыгы хакында сүз алып бара, шуңа өстәп Аллаһ белән көрәшүче һәм аңа каршы торучы, гади халыкны исә изүче тиран *Нәмруд* образын кертә. Безнең көннәргә килеп җиткән риваять һәм легендаларның күбесеннән билгеле булганча, Нәмруд (Нимрод, Немрод, Немврод) тиран һәм Югарыгы көч белән көрәшүче Вавилон патшасы буларак гәүдәләнә, Вавилон манарасы аның кушуы буенча төзелә, Нәмруд артык нык кырыслыгы, тәкәбберлеге, потка табынуы белән аерылып тора, Ибраһим пәйгамбәр белән дошманлыкта була. Нәмруд патша турында мәгълүматлар Коръәндә дә бар, анда аның Ибраһим пәйгамбәр белән диалогы хакында сөйләнелә (2: 258) һәм (21: 69). Нәмруд образы белән бергә хикәядә җир-су хайваны саламандра телгә алына, биредә шунысы игътибарга лаек: Ә.Каргалый әсәрендә хайван кош сурәтендәге аллегорик образда гәүдәләндерелгән. Салкын кош саламандрага багышланган риваять борынгы грекларның Урта гасырларда бөтен дөньяда киң таралган хайваннар һәм кыйммәтле

ташлар турында мәкаләләр һәм мәгълүматлар җыентыгы «Физиологус»та да бар. Бик нык популярлашып, «Физиологус» мөселман Шәрыгы әдәбиятына, шул исәптән татар әдәбиятына да, зур йогынты ясаган. Борынгы грек җыентыгына кертелгән риваятькә караганда, янмый торган саламандра кошы Этна вулканында яши. Саламандра – шулай ук христиан символы да, монда ул әхлаклылыкны, пакьлекне яисә җир ләззәтләренә алданмаучы тәкъва кешене гәүдәләндерә. Ә. Каргалый әсәрендә тиран һәм изүче Нәмруд тарафыннан тирә-як дөньяны уратып кабызылган утны Аллаһ чәчәктә утыра торган бакчага әверелдерә, ә утны аннан зыян күрми торган саламандра кошына ашата: *Нитә Нәмруд галәме нар әйләде, Хак Тәгалә аны гөлзар әйләде. / Әйләмешдер хәзрәте Раббел-гыйбад, Ул сәмәндәр тыйренә атәшне зад* [Каргалый, 1889, б. 12].

Мәгълүм булганча, мөселманнарның изге китабында кайчандыр бик алга киткән тормышта яшәгән, әмма гайре табигый гөнаһлары һәм аларны вәгазьләргә дип җибәрелгән пәйгамбәрләрне тыңламаганнары өчен Аллаһ тарафыннан һәлакәткә дучар ителгән һәм Җир йөзеннән юкка чыгарылган кавемнәр турында сөйли торган күпләгән хикәятләр китерелгән. Нух, Гад, Салих һ.б. кавеме шундый язмышка дучар була. Ә.Каргалый хикәясендә Сәба шәһәре кешеләренә дә пәйгамбәр җибәрелә, ул үз халкына Аллаһ кушканнарны җиткерә, алар исламның төп биш баганасы рәвешендә китерелә: бер Аллаһыга ышану, намаз уку, зәкят түләү, ураза тоту, хаҗ кылу. Болар Коръәндәге «Сәба» сүрәсендә шушы рәвешле бирелмәгән, ягъни пәйгамбәрнең андый күрсәтмәләр бирүе хакында сөйләнми, димәк, хикәядә бу сюжет сызыгы Ә. Каргалый тарафыннан махсус үстерелгән. Аллаһ рәхмәте белән бирелгән, әсәрдә санап чыгылган барлык нигъмәтләр хакында язып, автор шәһәрдә яшәүчеләрнең тәкъдире турында Аллаһ сүзләрен җиткерә, сайлап алыр өчен аларга ике юл барлыгын күрсәтә: *Шөкер идәрсәңез бәңа сезләр әгәр, Артдырурым нигъмәтеме сәрбәсәр. / Сездән әгәр улса көфране нигамъ, Гафел үлемең каты тәгъзибе идәм* [Каргалый, 1889, б. 13].

Әмма Коръәндә сөйләнелгән адашкан башка кавемнәр кебек үк, Сәба шәһәре кешеләре дә пәйгамбәрләренең үтемле сүзләрен санга сукмыйлар, Аллаһ кушканны үтәүдән баш тарталар. Имансызлар турында сүз чыкканда, әсәрнең эмоциональ тоны көчәя; текстта аларга түбәндәге тискәре характеристикалар бирелә: кирелек, кире беткәнлек, Аллаһ кушканнарны санга сукмау, азгынлык; гөнаһлы булу; бозыклык; алар ашказаннарын тутыруны гына кайгырта торган дуңгызлар (*Һәрберсе дуңгыз шикелле ашауда булды*), үлем алды ачысы белән кычкыра торган ишәкләр (*Ишәк кебек акыра-бакыра Бу дөньядан киттеләр*) белән чагыштырыла һ. б.

Шунысы әһәмиятле: «Хикәйәт-әс-салис»ның авторы сюжетка Коръән тарихында Муса пәйгабәр турында булган кайбер детальләрне кертә («әл-Әгъраф», «әл-Кәсас», «Та һа» сүрәләре һ.б.). Мәсәлән, Муса пәйгамбәр һәм Мисыр фиргавене турында сүз бара

торган «Пәрдә» сүрәсендә болай дип язылган: «Аларга су баскынын, саранча, бет, бакаларны һәм кан җибәрдек, боларны аерым-аерым ачык галәмәтләр итеп җибәрдек. Бу галәмәтләрне күргәннең соңында да тәкәбберләнеп, азган кяфер кавеме булдылар» (7: 133). Сәбада яшәүчеләргә җәза, Муса тарихына багышланган күпчелек сүрәләрдәге кебек, этаплап килә: башта шәһәргә бихисап санда эт зурлыгындагы, тешләре тимер тарак тешләрен хәтерләтә торган саранча һәм күсе җибәрелә. Пәйгамбәр кабат кешеләрне аңга килергә, гөнаһтан тәүбә итәргә һәм дөрес юлга басарга чакырып, Хакка аларның йөрәкләрен ачарга омтыла, әмма аның бөтен тырышлыгы имансызлык диварына килеп төртелә. Шуннан соң шәһәрдә яшәүчеләргә, Аллаһ ихтыяры белән, саранча һәм күсе явы килә. Бу юлы да кешеләр каршы торуларын туктатмыйлар. Һавалылык һәм тәкәбберлек күрсәтеп, корткычлар үтеп керүдән саклану максаты белән, тимер һәм бакыр эремәсеннән шәһәр тирәли биек, нык дивар, корыч коймалар күтәрергә карар итәләр. Бу эшкә тимерчеләрдән тыш ирләр, хатын-кызлар, карты-яше – барысы кушыла. Аллаһ аларга башлаган эшләрен тәмамларга җитәрлек бер ел вакыт бирә. Шуннан соң, инде өченче тапкырында, Аллаһ аларга туфан җибәреп, боларны җир йөзеннән бөтенләй себереп түгә. Су стихиясеннән биек тау башына качып котылып, кырык кеше генә исән кала. Сынауның чираттагы этабы турыдан-туры аларга юнәлтелә, әмма болар килеп чыккан хәлләрдән сабак алырга сәләтсез. Киресенчә, исән калуларына һәм бар байлыкның аларга гына калуына сөенеп, болай дип әйтәләр: *Диделәр: үлде үләчәкләр тәмам, Улдылар туле әмәл лә шаз вә гәм. / Багъ, бостан, монча нигъмәт, монча мал Безә калды, диделәр ул кауме залл* [Каргалый, 1889, б. 15].

Аллаһ аларны элек булган тормыш рәхәтлекләреннән мәхрүм итеп, ачы сынаулар җибәрә. Ләкин бу очракта да алар, элеккечә, имансызлык һәм бозыклык халәтендә калалар. Хикәя шушы кырык кешенең дәвалап булмый торган тән авыруыннан бик нык газапланып үлү белән тәмамлана.

Сәбада яшәүчеләр тарихындагы төрле күренешләрне сурәтләгәндә автор саннар белән бәйле һ.б. төрле гиперболалар куллана. Мәсәлән, шәһәрне уратып алган диварлар төзелеше турында сүз чыкканда, ул фантастик зур цифрлар белән эш итә: *Дәю аһәннярләре җәмгъ итделәр Кем гадәддә йөз бең ир ирде болар. / Һәри беренең хадиме һәм сад иде, Гайре ярдәм идәче би хәдд иде* [Каргалый, 1889, б. 14].

Ә. Каргалый әсәрендә дә саранча, күсе һәм җәза итеп җибәрелгән башка төрле хәшәрәтләр шулай ук гадәттән тыш зур итеп күрсәтелгән: *Хак Тәгалә анларның бостанына Йулләды чикердәне сычкан илә. / Һәр бере җөссәдә ирде сәк мисал, Каһәри аййаный Ходай Зөлҗәлал. / Һәр бери әзрас вә әснандар иде, Санасын дәмүр тарак дәндандe* [Каргалый, 1889, б. 14].

Бу кансыз һәм туймас тамак җан ияләре әсәрдә шулкадәр куәтле итеп күрсәтелгән, алар хәтта тимер диварларны да кимереп тишеп

чыгалар, тимер диварлар башта иләккә охшап кала, аннан дивардагы тишекләр ишек кадәр булып киңәя: *Мушлара әмр итде анларлә бәһәм, Кальганы әйләмәгә сәкыб вә ныкам. / Әмре Хакга әйләйебән имтисал, Кальгайа йапушдылар каплан мисал* [Каргалый, 1889, б. 13].

Күргәнебезчә, Ә. Каргалый «Сәба» сүрәсен Коръәндәге формада җиткерү бурычын куймаган. Сәба шәһәре кешеләре турындагы хикәянең сюжетында башка сүрәләрдән алып кертелгән детальләр, җирнең әлеге оҗмах почмагында яшәүчеләргә Аллаһ мәрхәмәте белән бирелгән унике хасият рәвешендәге фантастик детальләр күп. Шулардан: шәһәрдә кыргый хайваннар (бүреләр, еланнар һ.б.) булмау; ашлык җыйганда, Аллаһның җилгә боерык бирүе, шуның ярдәмендә бөртекләрнең үзеннән-үзе башактан коелып төшүе; шәһәрдә яшәүчеләр салкынның һәм эссенең ни икәнен белмиләр, чөнки биредә мәңгелек яз хөкем сөрә; кешеләргә бәлаләр кимерүче, саранча ише хәшәрәтләр өере кыяфәтендә җибәрелә һ.б.

Сәба шәһәре кешеләренә багышланган бу хикәядә бер бәет аша чын-чынлап мөһим фикер җиткерелә, бу фикер әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла: бөтен рәхмәтләр – Аллаһтан; әгәр кешеләр явызлык, бәла-каза, бәхетсезлек белән очрашкан икән, алары да Аллаһ ихтыяры белән бирелгән, әмма барлык бәлаләрнең сәбәбе – кеше үзе. Ә. Каргалый коллык халәте (үзеңне һәм башкаларны коллык халәтенә җиткерү) кешенең үзеннән чыга дигән фикер әйтә: *Һәм мосауввир һәм мөхәүвилмен, белең, Коллык итмәк – эше дорыр бәндәнең* [Каргалый, 1889, б. 12]. Коръәндә бу: «Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһыдан. Әгәр казадан бер кайгы ирешсә, бу кайгы үзеңнең кимчелегеңнәндер» (4:79) – диелә. *«Әйт: «Әгәр мин адашсам,үз зарарыма адашкан булырмын. Әгәр хак юлга күнсәм, әлбәттә, Раббым вәхи иткән Коръән белән туры юлны табармын»* (34: 50). Шагыйрь искәртүенчә, Сәба шәһәре кешеләре очрагында алар үз һәлакәтләренә үзләренең динсезлекләре һәм тәкәбберлекләре сәбәпле җитәләр.

Әсәрнең соңгы егерме сигез бәетендә автор, йомгак ясап, укучыларны әлеге гыйбрәтле хикәя турында уйланырга һәм үзләре өчен сабак алырга өндәп, чигенеш ясый. Җирдәге байлык һәм кешеләрнең көче – узгынчы, ә Аллаһның көче һәм хакыйкате мәңгелек; Кыямәт көнендә һәрбер кеше үзенең җирдәге гамәлләре өчен җавап бирәчәк – әлеге фикерләр хикәянең сюжет сызыгында нигез хезмәтен үтиләр. Шуннан автор гомуми нәтиҗә ясый: Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен кире кагучылар рухи яктан да, физик яктан да, шиксез, һәлакәткә дучар ителәчәкләр: *Ошбу кыйссадан, әйә ихване дин, Хосса ухуз әйләя һәр мөслимин. / Хак эшә инкяр идән ирмеш йаман, Каһре Хакдан улмаз ирмешләр әман.* Алга таба автор Аллаһка ышанмаучы мөртәтләрдән иң-иңнәрен санап китә: болар – Аллаһы Тәгалә ихтыярына буйсынмыйча, аның мәрхәмәтен югалткан һәм меңләгән еллар Аллаһка табынуы һәм аңа хезмәт итүе әрәм булып җилгә очкан

Шайтан[1]; Мисыр фиргавене; әдитләр[2] улы – Нәмруд; Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең төп дошманнары – Әбү Җәһил һәм Әбү Ләхаб. Ә. Каргалый сүзләре буенча, болар барысы да бер-берсенә тиң, соң дәрәҗәдәге имансызлык үрнәге булып торалар, алар ике дөньяның берсендә дә уңышка ирешә алмаячак. Дәһрилеккә каршы автор югары әхлакта һәм әдәплелектә чагыла торган иманны куя. Гомумән, суфилар һәрвакыт дини-мистик тәгълиматта әхлакый аспектка зур игътибар биргәннәр һәм еш кына бу төшенчәне нур сүзе белән бәйләгәннәр.

Мөгаен, «нурлылык», «нур» – суфилар символының иң әһәмиятлеләреннән берседер. «Чама белән XI гасырдан гарәп телле фәлсәфәдә, бигрәк тә мөселман неоплатонизмында, «Илаһи яктылык» *(ишрак)* монистик теориясе ныгый. Бу теория буенча, Аллаһ яктылык бирүче энергияне башта Дөнья Акылына, аның аша Дөнья Җанына һәм соңыннан табигать белән башка әйберләргә тапшыра» [Ганиева, 2000, б. 79]. Белгәнебезчә, Нур ул – Аллаһның гүзәл исемнәренең берсе, Аның тышкы атрибутының чагылышы.

Мөселман традицияләренә ияреп, Ә. Каргалый да нур һәм әдәп терминнарын бергә тоташтыра: нур һәм әдәп бергә; суфи автор фикере буенча, әдәп аркасында фәрештәләр чисталыкка ия булалар: *Улды нур аны әдәбдин нә фәләк, Бу әдәблә улды пакъ җөмлә мәләк* [Каргалый, 1889, б. 15].

Үз фикерләрен раслау өчен, шагыйрь Җ. Руми һәм Суфи Аллаһиярның түбәндәге мөнәсәбәттә әйтелгән сүзләрен китерә: әшәке һәм оятсыз кешеләрне Аллаһ аларның бу сыйфатлары ачыла торган юлга куя, ахырда алар фаш ителәләр, аннан соң тәмуг газапларына дучар булалар. Ә. Каргалыйның тәнкыйтьләү ракурсына төрле теологик бәхәсләрдә күп катнашкан, мөселман мәктәбенең спекулятив дини тәгълимат вәкилләре – кәлам әһелләре (*кал әһеле*) дә эләгә. Җ. Руми, М. Газәли хезмәтләре белән беррәттән, татарлар арасында бик нык таралган һәм танылган китап авторы Суфи Аллаһияр сүзләре аша Ә. Каргалый кәлам әһелләрен ярканатлар белән чагыштыра һәм, чиксез теләкләрен тәнкыйтьләп, аларны «сукырлар» дип атый: *Мәгънәдә кур улдыкындан әһле кал, Бонларның хакында әйләр кыйл вә кал. / Мисал хоффаш күримезләр әзгами, Фәркъ вардыр ирадә би монтәһи* [Каргалый, 1889, б. 15]. Әсәр, кешене хак белемгә алып бара торган суфичылык (*саликун; салик*) юлына бастырганы өчен, Ә. Каргалыйның, Аллаһка рәхмәт әйтеп, меңләгән дога кылуы белән тәмамлана.

Шулай итеп, автор Коръән риваятьләренең төзелешен саклап, сюжетны оригиналь рәвештә интерпретацияли, өстәмә фантастик

[1] Әсәр текстында Шайтанның икенче исеме Газазил дә телгә алына. Бу исем Коръәндә дә, хәдисләрдә дә очрамый, кайбер ислам чыганакларында исә чагылыш тапкан; аларда әйтелгәнчә, Газазил – Шайтанның баштагы исеме. Бу исем ислам әдәбиятына борынгы яһүд текстлары аша кергән дигән версия дә бар.

[2] Әдитләр – Коръәндә телгә алынган борынгы халык, гөнаһка батулары сәбәпле Аллаһ ихтыяры белән юкка чыгарылганнар.

сюжетлар кертә. Нәтиҗәдә, Сәба шәһәре турындагы хикәя Коръән сюжетларын да үз эченә ала, икенче яктан, шул ук фантастик элементлар ярдәмендә ул утопияне – гади халыкның идеаль һәм гадел тормыш төзү турында мәңгелек хыялын да күрсәтә. Мөселманлык фикеренең бәһаләп бетергесез хәзинәләреннән файдаланып, хикәя авторы укучыларны бу гыйбрәтле хикәядән үзләренә сабак алырга һәм тәкәбберлек, рәхмәтсезлек, комсызлык, бозыклык, азгынлык кебек кимчелекләрдән сакланырга өнди. Әсәр ахырында ул гомуми нәтиҗәгә килә: Аллаһы Тәгаләнең боерыкларына буйсынмау кеше өчен җәзасыз узмый; никадәр бай булса да, Аллаһ кушканнан читкә тайпылучы иртәме-соңмы һәлакәткә дучар ителә. Коръәннең «Сәба» сүрәсендә моның турында: «И кяферләр, сезнең балаларыгыз да һәм малларыгыз да сезне Безгә якын итмәс, мәгәр иман китереп изге гамәлләр кылмасагыз», – дип әйтелә (34:37).

Ш.А. Садретдинов сүзләренә караганда, «Хикәя сюжетының узган гасырлардан алынуына карамастан, шагыйрь төп идеяне үз чоры белән бәйли һәм турыдан-туры замандашларына мөрәҗәгать итә» [Миңнегулов, Садретдинов, 1982, б. 103]. Сәба шәһәрендә яшәүчеләр турындагы хикәядә күтәрелгән проблемалар, мөгаен, һәр чор өчен көн кадагында булдылар һәм бүген дә актуальлекләрен югалтмыйлар.

**Әдәбият**

*Ганиева Р.К.* Философско-эстетические основы тюркских литератур Средневековья // Научный Татарстан. 2000. № 1. С. 79 – 85.

*Каргалый Ә.* Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. Казан: Казан ун-ның табгыханәсе, 1889. 34 б.

*Миңнегулов Х.* Мәрданәләр дик билеңне баглагыл // Мирас. № 6. 1997. Б. 6 – 8.

*Миңнегулов Х., Садретдинов Ш.* XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1982. 142 б.

*Миңнегулов Х.* Татарларда ислам дине // Мирас. № 4. 1998. Б. 112 – 115.

***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ә.М. Закирҗанов***

# М. ҖӘЛИЛНЕ ӨЙРӘНҮ ФӘНЕ: ХӘЗЕРГЕ ТОРЫШЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАР

В статье рассматривается современное состояние джалиловедения и задачи дальнейших исследований. Изучению творчества героя-патриота М. Джалиля посвящено множество книг и научных статей. Достаточно глубоко изучены жизненный путь поэта, борьба с фашизмом в плену, этапы и особенности творчества. В то же время возникла необходимость изучения творчества М. Джалиля исходя из современных реалий на новых методологических принципах. Перспективным является изучение духовного наследия поэта на основе генетических связей с тюрко-татарской и Восточной литературами, а также выявление типологических общностей с русско-европейскими литературами.

**Ключевые слова:** татарская литература, Муса Джалиль, поэзия, литературоведение, опыт, задачи.

The article deals with the current state of Jalil studies and the tasks of further research. Many books and scientific articles are devoted to the study of the work of the patriotic hero M. Jalil. The poet's life, the struggle against fascism in captivity, the stages and features of creativity have been thoroughly studied. At the same time, it became necessary to study M. Jalil's creativity based on modern realities and new methodological principles. The study of the poet's spiritual heritage on the basis of genetic ties with the Turkic-Tatar and Eastern literatures, as well as the identification of typological similarities with Russian-European literature is apromising direction of the research.

**Keywords:** Tatar literature, Musa Jalil, poetry, literary studies, experience, tasks.

Әдәбият-сәнгать өлкәсендә хезмәт итеп, мираслары кардәш халыклар арасында танылу алган Кол Гали һәм Мөхәммәдьяр, Тукай һәм Исхакый, Такташ һәм Җәлил, С. Хәким һәм Х. Туфан, А. Гыйләҗев һәм Т. Миңнуллин һ.б. белән татар халкы хаклы рәвештә горурлана ала. Алар арасында Муса Җәлил үзгә урын алып тора. Җәлил иҗаты һәм батырлыгы, милли чикләрне үтеп, кешелек дөньясында гуманизм өчен көрәштә үлеме белән үлемсезлек яулап алган шәхесләрнең берсе буларак бәяләнеп килә. Шагыйрь – иҗаты һәм батырлыгы белән милләтнең йөз аклыгы символына әверелеп, татар халкын бөтен дөньяга танытуга иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе. Шуңа да Җәлил шәхесен һәм иҗатын өйрәнү, батырлыкның тамырларын ачу белән бергә, аның иҗат серләрен, үзенчәлекләрен, бүгенгебез һәм киләчәгебез өчен әһәмиятен билгеләү изге бурыч булып тора.

Җәлил иҗатын өйрәнү ул – һәр яңа буынга шагыйрь шәхесен, иҗатын таныту, гыйбрәтле үрнәк итеп күрсәтү, күңелләренә Җәлил яклаган идеалларны сеңдерү, гомумән, үз халкың мәнфәгатьләре белән яшәүнең асылын ачу, милли үзаң һәм гомумкешелек

кыйммәтләрен яклау һәм саклау, шуларга нигезләнеп яшәү һәм хезмәт итү идеяләрен җиткерү дигән сүз. М. Җәлилнең кеше һәм гражданин буларак күрсәткән эш-гамәле кешелек тарихына гомере бәрабәренә явызлыкка каршы көрәш символы булып кереп калды. Ә инде үлем көтеп ятканда язган шигырьләре тупланган «Моабит дәфтәрләре»нең һәр строфасы, һәр тезмәсе шагыйрьнең күңел халәтен чагылдырып, җан авазы булып яңгырый. Аларда батыр рухлы, олы йөрәкле, кешелек идеалларына тугры калган көрәшче шагыйрьнең мәһабәт образы калка.

М. Җәлил бай мирас калдырган кебек, аның тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча да зур эш башкарылган. Теге яисә бу автор иҗатын өйрәнү фәне тикшеренү объектын һәм предметын төгәл билгеләүне, фәнни-теоретик һәм методологик базага нигезләнүне таләп итә [Закирзянов, 2019, с. 81–82]. Нәкъ менә методологик яктан карагандa Җәлил иҗатын тикшерүдә шактый төрлелек һәм чуарлык күзгә ташлана. Бу, бер яктан, Җәлил иҗатының гаять катлаулы һәм каршылыклы юллар үтеп илгә кайтуы, икенче яктан, яшәп килгән система таләпләре, чор идеологиясе йогынтысы белән аңлатыла. Җәлилне өйрәнүдә таяныч, этәрелеп китү ноктасы булып аның турындагы хезмәтләрнең библиографик күрсәткече тора. Бу өлкәдә төрле елларда җитди эш башкарылган. Ә. Кәримуллин 1961 елда «Муса Җәлил: библиография (1919–1961)» хезмәтен чыгара. 1976 елда КДУ фәнни китапханәсе хезмәткәрләре тырышлыгы белән «Муса Җәлил: библиографик күрсәткеч (1919–1973)» хезмәте басыла, аның дәвамы буларак, 1987 елда «Муса Җәлил: әдәбият күрсәткече (1974–1984)» ике телдә чыга. Ә. Кәримуллин тарафыннан эшләнгән татар филологиясе буенча авторефератлар һәм диссертацияләр (1998 елга кадәр) күрсәткече дә бу мәсьәләне тулыландыра [Каримуллин, 2000]. М. Җәлил иҗаты буенча 11 диссертация яклана: Р. Бикмөхәммәтов (1955), Н. Юзиев (1956), Г. Кашшаф (1960), В. Воздвиженский (1968), И. Зәбиров (1971), Р. Мостафин (1971), Й. Исәнбәт (1970), Ә. Мәхмүдов (1980), С. Арсланова (1982), К. Бадыйков (1982). Г. Кашшаф һәм Р. Мостафин иҗатлары буенча диссертация язган Л. Бәдретдинова, А. Мостафина хезмәтләрендә дә М. Җәлил иҗатына кагылышлы байтак материал урын алган.

Билгеле булганча, Җәлил иҗатын өйрәнүдә берничә этап аерып чыгарыла. Беренчесе – сугышка кадәрге чор белән бәйле. Җәлил иҗаты 1919 елда башлана, ә инде 1922 елда Казанга килгәч, ул актив рәвештә мәдәни тормышка кереп китә. 1920–1930 елларда «Барабыз», «Орденлы миллионнар» җыентыклары, шулай ук «Авыру комсомолец», «Хат ташучы», «Сагыну», «Алтынчәч» кебек әсәрләре җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Алар буенча байтак мәкаләләр язылса да, гомуми күзәтү һәм бәяләү өстенлек итә, әдипнең стиль үзенчәлекләренә тирән керү урын алмый диярлек. Әдип иҗатын өйрәнүдә икенче этап 1953 елның 25 апрелендә «Литературная газета»да шигырьләре басылып чыгу белән башлана һәм ул 1980 еллар-

га кадәр дәвам итә. Бу елларда Җәлил исемен һәм иҗатын халыкка кайтару, таныту, әһәмиятен ачу буенча гаҗәеп зур эш башкарыла. Зур хөрмәт һәм тирән ихтирам белән Г. Кашшаф, Р. Мостафин исемнәрен аерып атау дөрес булыр. Р. Мостафин остазы Г. Кашшафның урынын Җәлил фәненә нигез салучы буларак бәяләп билгеләсә [Мустафин, 2006, с. 16], үзе Җәлилнең шәхесен, көрәшен, иҗатын ил һәм дөньякүләм танытуга бөтен гомерен багышлый [Мостафин, 1982; Мустафин, 2004]. Әлеге икенче этапта Җәлил иҗатын өйрәнүгә өлеш кертүчеләрнең барысын да атап чыгу мөмкин түгел, шулай да җитди табышларга, яңа башлангычларга юл ачкан шәхесләрнең исемен күрсәтеп үтик: Р. Бикмөхәммәтов, М. Гайнуллин, Н. Юзиев, Ә. Кәримуллин, Ш. Хамматов, В. Хаков, В. Воздвиженский, Т. Галиуллин, С. Сафуанов, Ә. Мәхмүдов, К. Бадыйков һ.б. Тикшеренүчеләрнең игътибар үзәгендә Җәлил мирасын барлау һәм аны төрле телләргә тәрҗемә итү, халыкка таныту тора. Шагыйрьнең әсирлектәге тормышы озак вакыт билгесез булып кала. Шуңа да хезмәтләрдә Җәлилне көрәшче шагыйрь, патриот буларак ачуга киң урын бирелә. Аларда публицистик башлангыч киң урын алу да аңлашыла. Иҗатының кыйммәтен һәм әдәбият тарихындагы урынын ачуда ил-ватан өчен көрәшүе, интернационализм идеяләренә тугры калуы, фашизмга каршы көрәше белән үлемсезлек яулап алуы кебек җитди мәсьәләләр алгы планга чыгарып тикшерелә. Югарыда атап кителгән фәнни диссертацияләрнең нәкъ менә 1960–1980 еллар аралыгында язылуы да игътибарга лаек.

Бу елларда әдип турында күп санда фәнни-популяр китаплар, истәлек язмалары дөнья күрә. Ю. Корольков, В. Альтов, Ш. Рахманкулов, Ә. Исхак, К. Барская, Л. Небенцаль һәм башкаларның татар һәм рус телләрендәге хезмәтләрендә автобиографик фактлар, төрле истәлекләр һәм авторларның иҗат фантазияләре бергә кушылып китә. Мондый китапларның Җәлил шәхесенә игътибарны җәлеп итү, төрле буында, бигрәк тә балаларда кызыксыну тудыруда әһәмияте зур була.

1950–1980 елларда Р. Ишморат, Н. Исәнбәт, С. Агиш, Ә. Давыдов, Ш. Маннур, Ә. Гаффар, С. Хәким, Г. Хуҗиев, И. Юзиев, Р. Харис, Т. Миңнуллин, Р. Вәлиева һ.б. әсәрләре Җәлилнең әдәби образын чагылдыру ягыннан зур яңгыраш ала. Билгеле, фәнни-популяр һәм әдәби әсәрләрдә Җәлил образы реаль җир кешесе буларак сурәтләнү белән бергә, еш кына мифлаштырыла, идеаллаштырыла, җир тормышыннан күтәрелеп сурәтләнә. Бу аны, милли символ буларак, һәртөр тәнкыйтьтән өстен итеп кабул итү чагылышы була.

Җәлил иҗатын өйрәнүдә 1980–2000 еллар аралыгы үзгә урын алып тора. Билгеле өйрәнү процессы туктап калмый, әдипнең юбилейлары үткәрелә, туган көне яисә вафат булу датасы уңаеннан даими язмалар чыгып килә. Шулай да 1990 еллар башында үткән мираска ревизия ясап, Җәлил иҗатына да кара мөһер сугу, әһәмиятен шик астына алу омтылышы була. Әмма андый фикерләрне татар җәмәгатьчелеге кабул итми.

XXI гасыр башы Җәлил иҗатын өйрәнүдә яңа этап булып тора. Ул бертөрле генә түгел. Бу елларда әдип иҗаты, аннан да бигрәк шәхесе җитди бәхәсләр уртасында кала. Матбугатта Ф. Бәйрәмованың «Азатлык» радиосы редакторы булып эшләгән Гариф Солтан белән очрашуы һәм аның «Идел-Урал» легионына, җәлилчеләрнең көрәшенә, үтерелүенә шактый үзгә карашы турында язма чыга. Милли герой буларак бәяләнеп килгән шәхеснең батырлыгын шик астына алу әдәби җәмәгатьчелекне кузгатып җибәрә. Шактый язмалар дөнья күреп, Җәлилне татардан бигрәк коммунистлар илен яклап көрәшүче сыйфатында гына күрсәтүчеләр дә була. Татар җәмәгатьчелеге, шул исәптән язучыларның күпчелеге һәртөрле фараз кылуларны кире кагып, Җәлилне яклап чыга. Аеруча Р. Мостафинның дәлилле, фәнни һәм документаль нигезле мәкаләләре киң яклау таба. Аның «Җәлил эзләре буйлап...» («По следам поэта-героя») китабының кабаттан басылып чыгуы һәм 2006 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булуы, бу мәсьәләдә Татарстан җитәкчелегенең һәм киң катлау халыкның фикерләре уртак булуның бер чагылышы иде. Әлеге катлаулы сорауларга ачыклык кертүдә тарихчы И. Гыйләҗевнең «Идел-Урал» легионына бәйле Германия архивларында сакланган материалларга нигезләнгән хезмәтләре гаять зур роль уйный [Гилязов, 2005]. Мәскүдә яшәп иҗат итүче тарихчы галим Габделхан Әхтәмҗанның Җәлил эшчәнлеген фашизмга каршы Каршылык хәрәкәте кысаларында өйрәнүе дә Җәлил фәнендә җитди бер сәхифә булып тора [Ахтамзян, 2006]. «Идел-Урал» легионерларыннан оешкан 825 батальонның белорус партизаннарына кушылу вакыйгаларын өйрәнеп, яңа документлар тапкан Рөстәм Гайнетдинов хезмәтләре әлеге мәсьәләне фактик материаллар белән баета [Гайнутдинов, 2009].

Җәлил иҗатын өйрәнүгә, аннан да бигрәк яшь буынны тәрбияләүгә М. Җәлилнең туган җире – Оренбург өлкәсенең Мостафа авылындагы музее (мөдире Нәфисә Гобәйдуллина), Казандагы музее (мөдире Нәзирә Фәттахова), Минзәләдәге музее (мөдире Алсу Григорьева), шулай ук ТР Милли музее һәм башка төбәкләрдәге, мәктәпләрдәге музейлар да билгеле бер өлеш кертә.

Соңгы 10–15 елда әдип турында язмалар, аның китаплары басылу бермә-бер кими, әмма юбилейларына бәйле үткәрелгән фәнни конференцияләрдә, матбугатта басылган мәкаләләрдә җитди сыйфат үзгәреше күзәтелә. Әдипнең милли җирлектә формалашуын, сәнгати фикерләвенең төрле иҗат юнәлешләренә нисбәтле чагылышын методологик нигез итеп алу әсәрләрен һәм шәхесен милли тарих, милли мәдәниятКә нисбәтле һәм дөнья әдәбиятының бер өлеше буларак тикшеренүгә китерә. Бигрәк тә 2006, 2016 елларда КФУ һәм Җәлил музее, ТР Милли музее тарафыннан үткәрелгән фәнни конференция материалларында әлеге эзләнүләрнең башлангычы урын алган [Муса Джалиль, 2006; Муса Джалиль, 2016]. Мисалга кайбер тикшеренүләрнең проблемаларын гына әйтеп үтәм: Р. Мостафин һәм А. Әхтәмҗан

язмаларында Җәлил фәненең концептуаль проблемалары күтәрелә, Т. Галиуллин шагыйрь иҗатын поэзия тарихына нисбәтле тикшереп, әдәби-эстетик һәм фәлсәфи кыйммәтен ачу юлларын сыза, Р. Харис моңа кадәр читтә калып килгән мәсьәләне – Җәлил батырлыгының психологик нигезләрен өйрәнү зарурлыгын яклап чыга, Ф. Галимуллин исә М. Җәлилнең поэтик һәм гражданлык батырлыгының халыкчан нигезләрен тикшерә, Х. Миңнегулов шагыйрь әсәрләрен татар әдәбияты традицияләренә нисбәтле өйрәнә, Д. Заһидуллина шагыйрь иҗатының бер үзенчәлеген халык мифологиясе белән тыгыз бәйләнештә күрә, немец галимнәре Марк Кирхнер һәм Хотопп-Рике Мисте язмалары да яңа эзләнүләргә нигез булып тора. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында Г.М. Дәүләтшин һәм Ә.М. Сабирова тарафыннан Муса Җәлил кулъязмалары тасвирлануны да М. Җәлилне өйрәнүдә әһәмиятле гамәл дип бәяләргә кирәк [Давлетшин].

М. Җәлил шәхесен һәм иҗатын Россиянең төрле төбәкләрендә өйрәнү дәвам итү дә шатлыклы күренеш. Соңгы елларда фәнни конференцияләрнең Оренбургта, Екатеринбургта, Чиләбедә, С.-Петербург өлкәсендәге Тоснода һ.б. шәһәрләрдә үтүен күрәбез. Интернет челтәрләреннән билгеле булганча, Җәлил әсәрләренә нигезләнгән «Батырлык дәресләре» илнең төрле мәктәпләрендә үтә. Иң мөһиме, бу өстән кушу буенча түгел, бәлки укытучыларның, җәмәгатьчелекнең үз теләге буенча эшләнә. Читтәге конференцияләрнең әһәмияте тагын шунда: алар татар әдибе иҗатының башка милләт вәкилләренә дә якын булуын дәлилли һәм яңа якларын ачуга китерә.

Шул рәвешле, М. Җәлил иҗаты шактый тирән өйрәнелсә дә, соңгы вакытта бу өлкәдә эшләүчеләрнең саны кимүен күрәбез. Әйтелгәнчә, әдип иҗаты буенча соңгы диссертация 1982 елда якланган, әдәбиятчылар арасында Җәлил иҗатын төп юнәлеш итеп алып, максатчан өйрәнүче юк. Җәлилне өйрәнү фәне алдында торган бурычлар турында фәнни конференцияләрдә, очрашуларда даими әйтелеп киленә, аларны, гомумиләштереп, түбәндәгечә төркемләп булыр иде.

1. Җәлил иҗатын яңа методологик принципларда тикшерүне дәвам итү:

– яшьләрне кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре кысасындагы эзләнүләргә тарту;

– әдип әсәрләрен традицияләр дәвамчанлыгында, генетик һәм типологик планда татар, төрки һәм башка халыклар әдәбияты белән чагыштырып, үзара бәйләнештә өйрәнү;

– шагыйрь тормышын һәм иҗатын, аерым алганда 1920–1930 еллардагы әсәрләрен тулы һәм объектив, һәртөрле мифтан арындырып тикшерү бурыч булып кала;

– Җәлилнең Шәрык әдипләре иҗаты белән кызыксынуы, аларны өйрәнүе билгеле, шуңа да мирасын күпгасырлык Көнчыгыш әдәбияты традицияләре, ислам тәгълиматы белән бәйләнештә тикшерү сорала;

– немец фашистлары тарафыннан үлемгә хөкем ителгән әдип шул халыкның Маркс, Гете, Гейне, Шиллер кебек бөек шәхесләрен, аларны үстергән милләтне югары бәяли алган. Димәк, әдип иҗатын милли яшәеш, милли психология һәм гомумкешелек кыйммәтләре чагылышы ноктасыннан өйрәнү мәсьәләсе калка;

– Җәлилнең гражданин һәм әдип буларак батырлыгының нигезләрен иҗат психологиясе аспектында ачу да бурыч булып кала.

2. Икенче зур бер тармак булып әдәбиятта һәм сәнгатьтә М. Җәлил образын иҗат итү тора:

– әдәбиятта, музыкада, сынлы һәм рәсем сәнгатендә яңа эзләнүләр кирәклеге бәхәс уятмый. Күптән түгел Р. Корбанның «Ватан» романы дөнья күрү – матур күренеш. Язучы герой-шагыйрьнең фашизмга каршы көрәш һәм иҗат сәхифәләре аша гыйбрәтле әдәби образын иҗат итә, «Идел-Урал» легионындагы эшчәнлегенең яңа якларына килеп чыга, бу мәсьәләдә безнең күзаллауны бермә-бер баета. Шул ук вакытта әсәрнең сәнгати эшләнешен камилләштерү сорала (публицистикага тартымлыгы ачык сизелә), язучы Җәлил образының яңа якларын ачуга да җитди яңалык алып килми. Әмма аның шәхесенә игътибарны җәлеп итүе, кызыксыну уятуы белән хуплауга лаек;

– Җәлил образын кино сәнгатендә чагылдыру да заман таләбе булып кала. Дөрес, яңа документаль фильмнар эшләү процессы турында хәбәрләр бар, бу сөендерә.

3. Россия һәм чит ил архивларында эшләүне дәвам итү мөмкинлеген табу. Р. Мостафин ачыклаганча, Төркия гражданины Казыйм Миршан саклап калган кульязманың табылу ихтималы да бар бит әле.

4. Җәлилнең Сайланма әсәрләре 3 том булып 1955–1956 елларда, 4 том булып 1975–1976 елларда, 5 том булып 2006 елда дөнья күрә. Әсәрләренең факсимиле басмасы 2000 һәм 2005 елларда басыла. ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулу уңаеннан үткәрелгән түгәрәк өстәлдә, шуларга нигезләнеп, Җәлил энциклопедиясен эшләү мәсьәләсе күтәрелде.

Әдипнең дөньякүләм танылу алуы язучы хезмәтенең мөмкинлекләрен күрсәтә. Китап, театр һәм кино, опера һәм балет буыннан буынга күчеп бара, тарихта калып, һәр яңа буын тарафыннан яңача бәяләнә. Шуңа да мәдәният аша республиканы, татар халкын киңрәк таныту бурычы алга чыга. М. Җәлил үлем куркынычы астында киләчәккә омтылыш, якты идеал, гуманистик кыйммәтләр турында яза алуы белән һәрвакыт һәм төрле буыннар өчен гыйбрәтле үрнәк булып кала. Шуның белән ул татар халкына гына түгел, бәлки кешелек дөньясына да хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Ахтамзян А.А.* Муса Джалиль и его соратники в Сопротивлении фашизму. Казань: Идел-Пресс, 2006. 157 с.

*Гайнутдинов Р.* Новые документы о переходе 825-го батальона Волго-татарского легиона на сторону партизан // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2009. № 1. С. 58–72.

*Гилязов И.А.* Легион «Идель-Урал». Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха». Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 383 с.

*Давлетшин Г.М.* Описание рукописей Мусы Джалиля: (Фонд поэта в ИЯЛИ) / Г.М. Давлетшин, А.М. Сабирова. Казань, 2005. 356 с.

*Закирзянов А.М.* Современное татарское литературоведение: достижения, проблемы и перспективы развития // Национальные литературы на современном этапе: научные концепции и гипотезы: Сборник материалов круглого стола, посвященного 80-летию создания Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (11 сентября 2019 г., г. Казань) / сост.: А.Ф. Ганиева, Ф.Х. Миннуллина, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 80–87.

*Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш.А.* Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год. Казань, 2000. 160 с.

*Мустафин Р.* Научная публикация о жизни и творчестве Мусы Джалиля (Джалиловедение как наука) // Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века / сост. Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова. Казань: Казан. гос. ун-т, 2006. С. 15–20.

*Мостафин Р.Ә.* Өзелгән җыр эзеннән: документаль повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 464 б.

Муса Джалиль: жизнь и творчество через призму ценностей XXI века: Материалы Международной научной конференции «Джалиловские чтения» (15–16 февраля 2016 года) / М-во культ. РТ, Нац. музей РТ; КФУ, Ин-т филологии и межкульт. коммуникации им. Л. Толстого; Музей-квартира Мусы Джалиля; [отв. ред. С.Ю. Измайлова]. Казань: Фолиант, 2016. 447 с.

Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века: Материалы Междунар. науч. конф. (КГУ, 21 фев. 2006 г.) и юбил. торжеств, посвящ. 100-летию со дня рожд. поэта-героя / КГУ им.В.И. Ульянова-Ленина; М-во культуры РТ; [сост.: Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова]. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2006. 152 с.

*Мустафин Р.* Очередная попытка принизить подвиг Мусы Джалиля и его товарищей: Ф. Байрамова пытается возвысить дело Г. Султана – предателя Родины. Имя М. Джалиля хотят очернить // Татарстан. 2009. № 1. С. 42–45.

*Мустафин Р.А.* По следам оборванной песни. Изд. перераб. и доп. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 399 с.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы***,
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

УДК 821.161.1

***И.Ә. Еникеев***

## ТАТАРСТАНДА РУС ТЕЛЛЕ ӘДӘБИЯТНЫҢ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье систематизированы художественные поиски русскоязычных писателей-татар исходя из проблемы формирования новой национальной идентичности. Впервые выделены два направления данного феномена – московское и казанское. Автор провел анализ тематики, хронотопа, жанровых особенностей текстов в аспекте их соответствия национальному менталитету и особенностям татарской культуры.

**Ключевые слова:** русскоязычная литература, национальный менталитет, татарская культура, тематика, хронотоп, И. Абузяров, Г. Яхина, А. Хаиров, Ш. Идиатуллин.

The article systematizes the artistic search of Russian-speaking Tatar writers based on the problem of forming a new national identity. For the first time, two directions of this phenomenon have been identified – Moscow and Kazan. The author analyzed the subject matter, chronotope, genre features of the texts in terms of their compliance with the national mentality and the peculiarities of the Tatar culture.

**Keywords:** Russian-language literature, national mentality, Tatar culture, subject, chronotope, I. Abuzyarov, G. Yakhina, A. Khairov, Sh. Idiyatullin.

Татарстанның 2000–2020 еллар аралыгындагы рус телле әдәбияты үзенчәлекле сыйфатларга ия, шуның белән ул элгәреге чорлардан аерылып тора да. Әдәбиятка яңа яшь буын килә һәм ул элеккеге идеологик, милли-сәяси, эстетик системаларның җимерелүе һәм җәмгыятьнең этик кыйммәтләрен яңадан карау белән характерланган торгынлык чорының (1985–2000 еллар) азагында пәйда була. 1960–1970 елларда формалашкан язучылар шул заман геройларының инде табылган әзер образларын куллануда дәвам итеп, аларны яңа заман чынбарлыгына күчерәләр. Әмма яшь язучылар яңа заман геройларын күрсәтергә, үз генерациясе кыйммәтләрен һәм кичерешләрен аңларга тырышалар. Бу күренеш турында Казан язучысы Лилия Газизова болай ди: «Хәзер мин үз буыным турында язам. Ул ике чор арасындагы болгавыр заманда бераз югалыбрак калды. Без яза башлаганда, социализм чоры тәмамланып килә, яшь язучыларны комсомол, партия һәм хөкүмәт үз канаты астына алган иде. Аннары – унбиш елга сузылган торгынлык һәм зәвыксызлык чоры. Талантлы кешеләрнең бик күбесе бизнес белән шөгыльләнә башлады, эчкечелеккә бирелде, эмиграциягә китте. Өлкән буын язучылар шул ук геройны язуларын дәвам иттеләр, вазгыятьне генә үзгәрттеләр. Аның я үз бизнесы бар, я тормышы рәткә салынмаган. Минем үзен күрсәтергә, әдәбиятта үз урынын табарга, ныклап каләм тибрәтергә дә өлгермәгән үз буынымны

аңлыйсым килде» [Газизова, 2007, б. 3]. Әгәр Л. Газизова һәм Н. Ахунованы әле формаль рәвештә милли әдәбиятның совет чоры белән бәйләп карарга мөмкин булса, алар артыннан ук килүче шагыйрәләр А. Кәримова һәм А. Әпсәләмованың карашлары киләчәккә төбәлгән. Поэзия белән чагыштырганда, рус телле прозада элеккеге идея-эстетик кыйммәтләрне җимерү һәм яңа милли кыйблалар эзләү тагын да радикальрәк төс ала.

Соңгы искәрмә Татарстандагы әдәби процессны аңлау өчен аеруча мөһим. Җирле әдәби мәктәп, рус телле язучыларның тәрҗемә һәм иҗади аралашуы аша татар мәдәнияте белән бәйләнеше – болар барысы да Н. Ахунова, Л. Газизова, А. Кәримова, Н. Ишмөхәммәтов, А. Хәиров, С. Юзиевнең иҗади дөньясын формалаштыруга зур йогынты ясый. Әмма Татарстан мохитендә әдәби тамыр җибәрмәгән язучылар төркеме – Р. Беккин, Ш. Идиятуллин, И. Әбүзәров, Г. Яхина – мисалында Мәскәүдәге рус язучылары эстетикасын күчереп алу авторларны татар дөньясыннан бөтенләй башка координаталар системасына алып китү ихтималын күрсәтә. Әмма бу – язучы шәхесенең тышкы якларының берсе генә, икенчесе, тагын да әһәмиятлерәге, казанлылар һәм иске шәһәр, мәхәббәт һәм ялгызлык, тормышның мәгънәсен һәм үз-үзеңне эзләү турындагы тарихлар белән бәйләнгән. Мәсәлән, язучы Адель Хәиров күптөрле – лирик, романтик, сагышлы, драматик, мистик, сюрреалистик сюжетлар тудыра. «Адель Хәиров күп еллар дәвамында авыл һәм шәһәрләрдә йөргәндә очраткан кызыклы характерларны блокнотына терки бара һәм аларны хикәяләренә Татарстан җиренең сирәк бизәге буларак саклап калу өчен кертә» [Хаиров, 2019, б. 2]. Бер интервьюсында язучы бу турыда үзе болай дигән: «Мин монда яшәүче һәм рус телендә сөйләшүче башка халыклар өчен татар дөньясын ачам. Минем хикәяләрем Казан нуры белән сугарылган. Диалогларга татар сүзләре һәм фразалары килеп керә. Мин туган җирнең токларын тоям, мин үзебезнең кояш астында үстем!» [Давлетшина, 2018, б. 84]. Л. Газизова кебек үк, язучы А. Хәиров та – аналитик һәм тәнкыйди акылга ия, әдәби процессның трендларын һәм тенденцияләрен аерырга сәләтле язучы.

Казан язучысының текстыннан аның җирле этнографияне һәм гореф-гадәтләрне яхшы белүе, Татарстан җирендә яшәүче төрле милләт кешеләрен тирәнтен төшенүе сизелеп тора. Биредә И. Әбүзәров һәм Г. Яхина әсәрләрендәге кебек милли, дини символлар белән рациональ-хиссез һәм коммерциячел уеннар юк. Әгәр Р. Беккин әдәби-гыйбрәтле һәм фольклор-анекдот сюжетлары (алар хәзерге заман Хуҗа Насретдины – исламлаштырылган рус Евгение образы белән ныгытылган) контекстында ирония һәм сарказм белән рефлексияләсә, А. Хәиров Казан мифологемаларын тасвирлау аша төрле ментальлекләр һәм төрле этник кыйммәтләр арасында сак арадашчы сыйфатында чыгыш ясый. Дөрес, тикшеренүче Э. Шафранская А. Хәировны гомумроссия контекстына кертә һәм «рус әдәбиятында XX–XXI гасырларда феномен – чит этномәдәни текст барлыкка

килде» [Шафранская, 2014, б. 96 ], – дип яза. Бу текст руслар өчен башка халык, мәдәният, дөнья турында күзаллау тудыра һәм бу куышның язучылары билингваль тирәлектә төрле этник кыйммәтләр һәм ментальлекләр арасында чит этномәдәни тәрҗемәчеләр булып торалар. Алар өчен күп мәдәниятләрдә виртуальлекне тою хас. Моннан төрле мәдәният элементларын сайлау һәм катнаштыру теләге туа, аларны ул үз автопортретына яки милләт портретына әверелдерә һәм авторның башбаштаклыгы белән нигезсез этник конструкцияләү тормышка ашырыла һәм кешеләрнең кәефенә тия. Татар колоритын торгызу өчен, А. Хәиров ориентализмның традицион алымнарыннан файдалана: экзотик артефактлар, милли кухня, сүз каламбурлары. Аларда ике мәдәниятнең аерып булмаслык дәрәҗәдә кушылуы турында тарихи-мәдәни подтекстны күреп була. А. Хәиров башка рус әдәбияты – аның чит этномәдәни тексты традицияләрен дәвам итә, шуңа күрә гибрид тиңдәшлек проблемасы аның иҗатында лейтмотивларның берсенә әверелә.

Л. Газизова, А. Хәиров, Р. Беккин иҗатында 1990–2000 еллардагы яңа буын героен эзләү тенденциясе күзәтелә. Аларның әдәби трендлары И. Әбүзәров, Ш. Идиятуллин, Г. Яхина кебек Казан әдәби мәктәбен үтмәгән күренекле язучыларның иҗат стратегиясендә үзенчәлекле чагылыш таба. Рус телле әдәбиятта беренче тапкыр эре жанр формасы – моңарчы Д. Вәлиев тарафыннан гына кулланылган роман барлыкка килә. Әлеге авторларның Казан язучыларыннан принципиаль аермасы жанр формасында гына түгел. Алар татар дөньясына башка мәдәният даирәсеннән карый. Г. Яхина өчен татар менталитеты – Идел буе немецлары мәдәнияте кебек үк анатомик өйрәнү объекты ул («Дети мои» («Балаларым») романы). И. Әбүзәров өчен фин-угор («Финское солнце» («Фин кояшы») романы) һәм поляк («Курбан-роман») мәдәниятләре, шулай ук Ш. Идиятуллин өчен төрки фольклор («Убыр» романы) шундый ук рефлексия объекты булып тора. Аларда татар традицияләренә эмоциональ бәйлелек һәм аларның изгелеген тою хисе юк. Казан язучылары өчен татар мәдәнияте тумыштан якын һәм күпләр өчен әлеге хисси бәйләнеш саклана. 2000 еллар башында М. Эпштейн, К. Солтанов, М. Тлостанова кебек авторларның постсовет киңлегендә яңа милли охшашлыклар барлыкка килү турында фәнни тикшеренүләре пәйда була. Аларда бәян ителгән методологик эшләнмәләр 2003 елдан соң әдәбиятка килгән яңа буын язучыларның иҗади бурычларына тулысынча туры килә. И. Әбүзәров, Ш. Идиятуллин һәм Г. Яхинаның бер-берсенә охшамаган әсәрләрендәге иҗат кыйблалары уртаклыгының сере, мөгаен, шунда яшеренгән. «Чингиз-роман»да И. Әбүзәров болай дип яза: «Без – шигъри провинция гопниклары, без бөтен эре редакцияләр һәм театрларны сугышып алдык. Аптырашта калган мәдәният баганаларының йөзләренә төкерделәр. Нәфрәт тудыргыч дөнья цивилизациясенең җимешләрен рәхәтләнеп җимерделәр» [Абузяров, 2004, б. 66–67] Бу – метафора гына түгел, язучыларның каләмен кузгаткан

омтылышның сәбәбе дә. А. Хәиров дөрес яза: әдәби текстта авторның яшерен теләкләре ачык чагыла. Эш хәтта шәһәрләрдә бер-беренә дошман яшьләр төркемнәре темасының И. Әбүзәров һәм Ш. Идиятуллин иҗатында лейтмотив булып узуында да түгел. Проблема шунда ки, өчесенең дә, шул исәптән Г. Яхинаның да, иҗаты гомуми семантик үзәк – ир-ат һәм хатын-кыз абруена зыян китерүче гештальт-образ һәм аны компенсацияләү ысуллары тирәсендә корыла. Шәхси һәм милли җәберләнү комплексын җиңеп чыгуны бу язучылар үз-үзеңне варварларча тоту стратегияләрендә, бернинди кыйммәтләр белән дә чикләнмәгән көчләүдә һәм кеше тәне культында чагылыш тапкан ниндидер неомәҗүсилектә күрәләр. Зөләйха Игнатовны тышкы параметрлары һәм исе буенча сайлый, ә соңрак ыру хәтерен кабатлап, корал тота белүче аучыга әйләнә. Әлеге концепция акыл һәм гыйлемне, динне (исламның сөнни мәзһәбен) һәм әхлакны беренче урынга куйган татар менталитеты координаталары системасына берничек тә туры килми.

Ш. Идиятуллин беренчеләрдән булып сәнгати киңлек моделен эшли һәм куллана, анда татар дискурсы түбәндәге дошман дөньясында – үзенә күрә тартарда урнаша, һәм ул хәзерге шәһәр кешеләре тормышына убыр һәм албастылар аша үтеп керә. 2012 елда «Азбука» нәшриятында Наил Измайлов тәхәллүсе астында «Убы́р» исемле мистик триллер дөнья күрә, ул шул ук елны Владислав Крапивин исемендәге Халыкара балалар әдәби премиясенә лаек була, ә «Мир фантастики» журналы китапны «Мистика и хоррор» номинациясендә билгеләп үтә. Язучының әсәрләре еш кына фантастик юнәлешкә карыйлар, чөнки аларда вакыйгалар шартлы, язучы тарафыннан уйлап чыгарылган (әмма реаль чынбарлык белән беркадәр охшаш) дөньяда бара. Жанр төгәл билгеләнмәскә дә мөмкин, чөнки Ш. Идиятуллин бер әсәрдә еш кына төрле жанр системаларының үзлекләрен тоташтыра. Шуннан чыгып ул «Убыр» дилогиясендә, рухлар белән тулы дошман киңлекләре буларак, татар авыллары хронотобын төзи. Әбүзәров белән беррәттән, ул баш геройның хәрби инициация йоласын сюжетның нигезенә салган: шәһәрдә туган яшүсмер татар Наил убыр этенә (убырны үтерүчегә) әйләнгәндә, ә «Город Брежнев» романындагы Артур бер сугуда амбалларны бәреп аударучы, бередәге яшьләрне куркытып бетергән татар милиционеры Хәмәдишинны үтерүдә катнашучы текә гопникка әверелә. Артур Вазыйхов – катнаш татар-рус гаиләсеннән, үз-үзен идентификацияләү проблемасын аеручa нык тоя: «Туганнан бирле кемнеке булуым хакында уйланмадым. Мин үзебезнеке. Ягъни бераз әти-әнинеке, беркадәр кырык алтыныкы, азрак кына мәктәпнеке, тик болар инде детальләр генә. Шул ук вакытта комплекста да, мәктәптә дә аерым контора юк, ә ниндидер чит-ят нәрсәгә килеп кушылырга мин кайчан да өлгерермен... Минем үз Ватаным – әнием, әтием, һәм тагын кемдер, туарга өлгермәгәннәр, әмма алар инде минем яратканнарым <...> Минем йортым, минем комплексым, малайлар, Танька, минем Брежнев шәһәрем. Мин аларга

ничек хезмәт итәргә икәнен белмим, ләкин аларны саклаячагымны-яклаячагымны беләм. Ничек булса да, кемнән булса да» [Идиатуллин, 2012, б. 422]. И. Әбүзәров инициация йоласын тән һәм чиксез җәбер-золым культы белән бәйли, ерткыч көчмәләр («Чингиз-роман») һәм хәзерге дөньяда үз-үзеңне аямау («Курбан-роман» диптихы) темалары өстендә эшли. Гәрчә кыска проза Әбүзәров иҗатының төп жанры булып калса да, аның поэтикасы гаҗәеп төрле. Хәер, «әдип төзегән сәнгати дөньялар тагын бер уртак сыйфатка ия: принципиаль рәвештә антимиметик булып, алар барысы да эчке дөньяларның психореалистик тикшеренүе буларак чыгыш ясыйлар [Далин, Абузяров 2009]. Әбүзәров иҗатында өстенлек итүче эчке монологлар аңлы импульска буйсынган (сексуальлек, социаль травматизация, мистик яки фантастик спиритуальлек). Латин Америкасының тылсымлы реализмы аңа илһам чыганагы булып хезмәт итә» [Уффельман, 2017]. Бүгенге көндә И. Әбүзәров – рус, Көнбатыш Европа һәм Шәрык мәдәниятләре парадигмасында әсәрләр иҗат итүче рус телле язучы.

Идиятуллин кебек үк, Г. Яхина да «Зөләйха күзләрен ача» романында (2016) хикәяләү нигезе итеп гаилә сюжетын сайлый, шул рәвешле укучыларның шәхси язмыш белән кызыксынуын чагылдыра. Язучы И. Әбүзәровның шул ук вәхшиләрчә сюжет стратегияләрен һәм хәтта соңгы «Дети мои» романында аның тылсымлы реализм алымнарын куллана. «Зөләйха күзләрен ача» романында аның Игнатовтан алган беренче тәэсире «кызылурдачы» («красноордынец») сүзе белән билгеләнә. Ул аны татар убырлары (каенанасы Убырлы карчык, беренче ире) дөньясыннан азат итүче гибрид сугышчы сыйфатында кабул итә. Игнатов белән төнге очрашудан соң, Зөләйха кар өстендә Убырлы карчыкның зәңгәр эзләрен күреп: «Бу минем тормышым, син миңа бүтән указ түгел! Кит моннан! Кит моннан!» [Яхина, 2015, б. 445] – дип аны каргый.

Интертекстуаль уеннар И. Әбүзәровның гына түгел, Ш. Идиятуллин һәм Г. Яхина иҗатының да эстетик принцибына әверелә дип әйтергә мөмкин. Аларның төп алымы – цивилизациянең мәдәни кодларын деконструкцияләү яки, гади итеп әйткәндә, каноник сюжетларга интеллектуаль пародияләр, үзенә күрә ремейклар эшләү. Мәсәлән, «Курбан-роман»да Каин һәм Авельнең бертуганын үтерүе яки Г. Яхина китабында Зөләйха турындагы яңадан кодлаштырылган миф. Әбүзәров әсәрләренең геройлары хәзерге чынбарлык шартларында мифологик персонажлар ролен үзләрендә тикшереп карыйлар һәм, үзбилгеләнү баскычларын узып, беренчел сюжетлардан читкә тайпылалар. Ш. Идиятуллин һәм Г. Яхина әлеге традицияне татар этнографик материалында үстерәләр. Әлеге язучылар төркеменең текстларына лингвистик анализ аларның җөмләләрендә сүзләр саны һәм диалогларның күләме уртачадан шактый түбән булуын күрсәтә. Бу, мәдәни терминнарны күп кулланyга карамастан, синтаксисның аксавы һәм әдәби телнең ярлылыгы турында сөйли. Аларның (бигрәк тә

Мәскәүдә сценарий факультетын тәмамлаган Яхинаның) җөмләләре сюжетның визуаль-мәгълүмати рәтенә кыска текстларны хәтерләтә. Шуңа күрә кайбер тәнкыйтьчеләр күрсәтелгән авторлар китапларының кинематографик характерда булуы турында сөйли башлады. Алар күбрәк фильмнарның сценарийларын хәтерләтәләр кебек. Чыннан да, 2014 елда татар режиссеры һәм язучы Салават Юзиев И. Әбүзәровның «Курбан-роман»ы буенча фильм төшерде, Ш. Идиятуллинның «Город Брежнев»ы һәм Г. Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре экраннарга чыкты. Шуңа бәйле рәвештә аларның иҗаты чын мәгънәсендә матур әдәбият әсәре булып торамы, дигән сорауны бирәсе килә. Ул вакытта, аларның текстлары «популяр мәдәниятнең дискурсив гамәлияте продуктын тәшкил итүен» [Павлова, 2018, б. 56] исәпкә алсак, ул вакытта болар – күбрәк укучылар аудиториясенең интеллектуаль, социаль хәленә һәм яшенә юнәлдерелгән массачыл коммерцияле әдәбият. 2000–2020 еллар чоры Татарстанның рус телле әдәбияты тарихында кайбер үзенчәлекләр белән билгеләнә. Анда рус классик һәм совет әдәбияты традицияләре белән бәйле булмаган яңа әдәби геройны эзләү бара. Язучыларның яңа буыны элеккеге кыйммәтләр системасы җимерелү һәм яңа эстетика һәм идеология барлыкка килү чорында яшәүче кешенең эчке дөньясын тасвирларга омтыла. Казан әдәби мәктәбе белән бәйле язучыларның бер өлеше үз тәҗрибәсенә һәм тормыш чынбарлыгыннан алган тәэсирләренә таяна (Н. Ахунова, А. Кәримова, Л. Газизова, А. Хәиров). Россиянең мәдәни башкалалары – Мәскәү һәм Санкт-Петербург белән бәйле авторларның башка бер төркеме үткәнгә мөрәҗәгать итә һәм этностереотиплар һәм мәдәни кыйммәтләргә ревизия ясау белән шөгыльләнә. Үткәннәрне тергезү һәм реабилитацияләү, томанлы хисләр һәм инстинктлар дөньясына чуму алар эстетик концепциясенең нигезенә әйләнә. Әгәр Казан язучыларының бер өлеше классик сәнгать формаларына тугрылыгын саклаcard, «башкала мәктәбе» үзләрен кинематографның визуаль өлкәсенә якынайтучы массачыл мәдәният формаларын куллануга юнәлеш тота. Казан язучылары, мөмкин кадәр, татар мәдәнияте һәм милли менталитет проблемаларын аңларга тырышалар. Мәскәүлеләр – И. Әбүзәров, Ш. Идиятуллин, Г. Яхина – этник проблематиканы укучылар өчен кызыклы мәйданчык сыйфатында гына файдаланалар һәм анда үзләренең интертекстуаль уен һәм сюжетларын җәелдерәләр.

**Әдәбият**

*Абузяров И.А.* Чингиз-роман // Знамя. 2004. № 1. С. 66–67.

*Газизова Л.* «Жила-была Газизова-Красивая, капризная...»: [Беседа с казан. поэтессой, накануне традицион. осеннего бала поэзии] / беседовала П. Федорова // Казанские ведомости. 2007. 19 окт. С. 3.

*Давлетшина А.* Бойтесь писателей, они вас заберут в свой рассказ и там зарежут!: [А. Хаиров стал победителем Литературной премии журнала «Татарстан». Беседа с писателем] // Татарстан. 2018. № 1. С. 84.

*Идиатуллин Ш.* Город Брежнев. СПб.: Азбука-Аттикус, 2012. 698 с.

*Павлова Н.И.* Поэтика визуальности в романе Г. Яхиной «Дети мои»: к вопросу о феномене литературного успеха. Культура и текст. 2018. № 3 (34). http://www.ct.uni-altai.ru/. С. 55–56.

*Уффельман Д.* Игра в номадизм, или Постколониальность как прием (случай Ильдара Абузярова) [Электронный ресурс] / пер. с англ. Н. Ставрогиной // Новое литературное обозрение. 2017. № 2. URL: http://www.nlobooks.ru/node/8411 (дата обращения: 01.06.2017).

*Хаиров А.Р.* Играй, не знай печали. Казань: Татар. кн. изд-во. 2019. 239 с.

*Шафранская Э.Ф.* Мифология Казани в прозе Аделя Хаирова. // Вестник Северного (Арктического) федерального университета им. М.В. Ломоносова. 2014. № 1. С. 96–99.

*Яхина Г.* Зулейха открывает глаза. М.: Изд-во Елены Шубиной, 2015. 512 с.

***Еникеев Илдар Әхнәф улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 135 ЕЛ

Быелгы язда татар мәдәниятенең күренекле иҗатчысы Тукаебыз туунның янә бер күренекле датасы – бөек шагыйрьнең 135 еллыгы билгеләп үтелә. Татарлар исемен дөньяга ишеттерүдә, милләтебезне танытуда Габдулла Тукай эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Бүген без бөтен татарларның рухи кыйбласы булган Тукайның үз халкына калдырган олы мирасын өйрәнү, шәрехләү тарихы үзе дә гасырдан арткан чорда яшибез. Заманалар барышында илебез тормышында нинди генә кискен иҗтимагый үзгәрешләр булса да, Тукай шәхесен һәм иҗатын гыйльми өйрәнүгә алар тискәре йогынты ясады дип әйтеп булмый, Тукайны өйрәнү әле һаман саен тирәнәя генә бара. Бөек шагыйребез мирасын һәрьяклап игътибар үзәгенә алу бүгенге татар гуманитар фәненең иң мөһим тармакларының берсен тәшкил итә.

Күп дистә еллардан бирле шулай килә: Тукайга багышланган фундаменталь тикшеренүләрнең, әлеге шәхесне төрле яклап тагын да киңрәк ачуны күздә тоткан чараларны координацияләүнең үзәгендә, нигездә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тора, бу гамәлләрне тормышка ашыруда өлкән буынны яшьрәкләре алыштыра килә.

Шушы уңай традицияләрне дәвам иткән соңгы биш елда гына да Габдулла Тукайның тормышын һәм иҗатын фәнни җәһәттән өйрәнү эшләрен югары дәрәҗәдә башкарылган гамәлләр дип бәяләсәк, арттыру булмас. Шагыйребез әсәрләренең заман сулышын исәпкә алып төзелгән алты томлык академик басмасы дөнья күргәннән алып, аны тарату, презентацияләү, таныту кебек эшләрнең туктаганы юк. Шулай ук Габдулла Тукайның Институт тарафыннан шактый еллар дәвамында әзерләнгән, бүгенге ихтыяҗдан чыгып башкарылган персональ энциклопедиясенең дә, ниһаять, 2016 елда дөнья күрүе бөтен төрки дөньяда зур вакыйга булуын искәртеп китми мөмкин түгел, әлеге уникаль энциклопедияне таныту-күрсәтү эше дә – Институт галимнәре тарафыннан Тукайны өйрәнүгә керткән зур өлеш. Бөек татар милләтенең зур шәхесләре шактый күп, персональ энциклопедиягә лаек затларыбыз эшчәнлеге бүгенге көндә Институт галимнәре – текстологлар, әдәбиятчы һәм телчеләр өчен гаять актуаль мәсьәлә булып кала бирә.

Бөтен татар дөньясы бөек шагыйребезнең юбилеен каршылап, шигърият дөньясына зур әһәмият биргән бу көннәрдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Тукай мирасын

фәнни конференция кысаларында дөньяга чыгаруны максат итте һәм «XX–XXI гасыр мәдәни мохитендә Габдулла Тукай» дип аталган, тематикасына Г. Тукай шәхесен һәм иҗади мирасын күрсәтелгән чор тарихи-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси контекстында киңкырлы тикшерү-өйрәнүне сыйдырган Халыкара фәнни-гамәли конференция уздыру гамәлгә куелды. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган әлеге чарада республиканың төрле фәнни оешмалары, югары уку йортлары галимнәре белән берлектә Россиянең башка төбәкләреннән һәм чит илләрдән дә катнашучылар җәлеп ителгән. Тукайга багышланган мондый конференциянең һәр биш ел саен традицион төстә уздырыла килүе үзе дә зур мәгънәгә ия.

Г. Тукайга багышлап уздырыла торган конференциянең быелгысы Институт тарафыннан һәм аның катнашында оештырыла торган Тукай атналыгын ачып җибәрәчәк зур чара буларак та үзенчәлекле. 23 апрельдә үткәреләчәк әлеге конференциядән тыш, Тукай атналыгы Татарстанда Г. Тукай әдәби музеенда узачак кызыклы чараларны, юбилей мөнәсәбәтле Арча педагогика көллиятендә, Казан мәктәп һәм гимназияләрендә тукайчы галимнәр белән очрашуларны, чит илләр, әйтик, Азәрбайҗан Фәннәр академиясендә Тукайга багышланган монография әзерләнү уңаеннан онлайн чараларны һ.б. ны үз эченә алачак дип планлаштырыла.

«Фәнни Татарстан» журналының әлеге рубрикасын махсус Габдулла Тукайга багышлауның максаты – шагыйрьнең иҗаты һәм шәхесе турында галимнәребезнең соңгы еллардагы табышларын үзәккә куюда. Алар милли әдәбиятта, сәнгатьтә, тәрҗемә һәм шәрехләүдә, социо-мәдәни контекстта Тукайны өйрәнүдә ирешелгән казанышларны тулыландыру җәһәтеннән әһәмиятле. Тукай иҗаты – татар милләтенең үткәнен, бүгенгесен, һәм киләчәген бәйләп торуы белән халкыбызны берләштерүгә, татар тарихи хәтерен яшәтүгә зур йогынты ясый торган маяк, шуңа да милли-сәяси мәсьәләләр аеруча кискенләшкән бүгенге чор өчен аның шәхесен һәм эшчәнлеген күтәрү гаять дәрәҗәдә актуаль. Төп юнәлеше милләтебез киләчәге өчен татар фәнен үстерүгә үз өлешен кертүдән гыйбарәт «Фәнни Татарстан» журналының бөек шагыйребез Тукайга биргән игътибары алга таба да милләтебез язмышына бәйле игелекле эшләр кылуга рухландырыр дип өметләнәбез.

УДК 821.512.145

***Л.Р. Надыршина***

# «ИНДЕ ЭШЛИК САФ, АЧЫК КҮЗЛӘР БЕЛӘН – ЧЫН “АҢ” БЕЛӘН...» («Аң» журналында Г. Тукай эшчәнлеге һәм аңа бәйле язмалар)

В статье представлен обзор деятельности Габдуллы Тукая, связанной с журналом «Аң». Издаваемый Ахмедгареем Хасани, современником и единомышленником Тукая, этот журнал занимал особое место в национальной печати начала XX века. Первый номер журнала (15 декабря 1912 года) открывался стихотворением Тукая «Аң», и до последних дней жизни поэта в каждом номере печатались его произведения. На основе фактических материалов автор раскрывает роль Тукая в создании журнала, также анализируются многочисленные статьи, воспоминания, стихи и фотоматериалы, посвященные биографическим фактам и творчеству поэта, опубликованные после его ухода из жизни.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, журнал «Аң», Ахмедгарей Хасани, татарская периодика, татарская литература.

The article presents an overview of Gabdulla Tukay's activities, related to the magazine “An”. Published by Ahmedgarey Khasani, Tukay’s contemporary and like-minded person, this magazine occupied a special place in the national press of the early 20th century. The first issue of the magazine (December 15, 1912) began with Tukay's poem “An”, and until the last days of the poet's life, his works were being published in each issue. On the basis of factual materials, the author reveals the role of Tukay in the creation of the magazine, as well as analyzes numerous articles, memoirs, poems and photographs devoted to biographical facts and the work of the poet, published after his death.

**Key words:** Gabdulla Tukay, the magazine “An”, Ahmedgarey Hasani, Tatar periodicals, Tatar literature.

Егерменче йөз башында татар әдәби-мәдәни яшәешендә яңа, үзгә юнәлештә булуы белән аерылып торган «иң киң программалы әдәби, фәнни, сәяси, иҗтимагый рәсемле» «Аң» журналы милли җанлы, алдынгы карашлы, татар мәдәни традицияләре белән бергә рус һәм Европа сәнгате казанышларыннан хәбәрдар зыялы Әхмәтгәрәй Хәсәни – «Гасыр» нәшриятын оештыручы, Тукай даирәсендә зур урын алып торган шәхес тырышлыгы белән нәшер ителә. Милли матбагачылык эшен үстерү омтылышы белән яшәгән, моннан тыш, «Шәрык клубы»н оештыручыларның берсе буларак, алдынгы карашлы татар яшьләре белән киң аралашкан, дөнья мәдәнияте казанышларын үзләштерергә омтылган әдәби-сәнгати мохиттә кайнаган Әхмәтгәрәй Хәсәни махсус әдәби журнал булдыру теләген шактый еллар күңелендә йөртә. Үзенең фикердәшләре – милли тәрәккыять идеясе белән янучы әдипләр, «Гасыр»ның даими авторлары белән

киңәшләшә, әлбәттә, алар арасында Тукай да була. Гомумән, «Гасыр» басмаханәсе урнашкан зур булмаган бүлмә – XX йөз башында яңалыкка сусаган хөр фикерле милли зыялыларны берләштергән үзенчәлекле әдәби салон булып китә. Бирегә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Н. Хәлфин, Г. Гобәйдуллин, Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов һ.б. еш була. 1912 елның 26 июлендә узган җыелыш-фикерләшүләрнең берсендә булачак журналның эчтәлеге, төзелеше, юнәлеше билгеләнә, әлеге җыелышта катнашучы зыялыларның төгәл исемнәре жандармерия агенты җиткергән мәгълүматта сакланган. Бу хакта Г. Мансуровның «Татар провокаторлары» (1927) дигән хезмәтендә әйтеп үтелә: *«Татар әдәбият түгәрәге июльнең 26-сында Евангелистовский урамда Хәсәнев йортында җыелды. Җыелыш тиз көннән калын рус журналлары шикелле бер әдәби, сәяси журнал чыгарырга карар бирде. Бу журнал яшь татар милләтчеләрен берләштерергә тиеш булачак. Җыелышта булган кешеләр: Гәрәй, Барый Хәсәневләр, Фуат Туктаров, Габдулла Гыйсмәтуллин, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, учитель Гафур Коләхмәтов, Исмәгыйль Аитов, Гыйльметдин Шәрәф, Гыйльметдин Ибраһимов, Габдеррахман Кәрам»* [Мансуров, б. 51]. Шулай ук мондый очрашуларның Хәсәниләрнең хәзер Васильево бистәсендә урнашкан дачаларында булуы да мәгълүм. Мәсәлән, Ф. Әмирхан истәлегеннән күренгәнчә, 1912 елда алар Тукай белән бергә, «Аң» журналының эш юнәлешен билгеләү өчен, Хәсәниләрнең дачаларына бара [Әмирхан, б. 161–162]. Бу очрашу турында Зәйнәп Хәсәния хатирәләрендә дә [Хәсәния, б. 16], Әхмәтгәрәй Хәсәнинең энесе Габделбарый истәлегендә дә[1] искә алына.

Шушы очрашулардан соң, 1912 елның 12 сентябрендә Әхмәтгәрәй Хәсәни губернаторга үтенеч язуы белән мөрәҗәгать итә[2], анда нәшер ителәчәк журналның егерме пунктны үз эченә алган программасы күрсәтелә, һәм бу программа бик киң: журналда, әдәбият-сәнгать, фән-тарих, дин-әхлак, мәгариф мәсьәләләреннән тыш, хакимият карарларын һәм боерыкларын, сәяси-иҗтимагый һәм икътисади мәсьәләләрне, хәтта медицина һәм гигиена, авыл хуҗалыгы кебек өлкәләрне дә яктырту күздә тотылган. Үтенеч язуында «Аң» журналының җаваплы мөхәррире итеп Әхмәтгәрәй Хәсәни үзе билгеләнәчәге әйтелә. Үтенеч язуы нигезендә рөхсәт белешмәсе 7 ноябрьдә алына.

1912 елның 15 декабрендә дөнья күргән беренче санында журналның юнәлеш-мәсләге кыскача болай дип яктыртып кителә:

***«Аң»**да милли әдәбиятымыздан шигырьләр, хикәяләр вә романлар дәрҗ ителеп (кертелеп), рус әдәбиятына вә чит мәмләкәт әдәбиятына да тиешлесенчә урын бирeләчәкдер.*

---

[1] «Шагыйрь Габдулла Тукаев турында кечкенә генә истәлек» дип аталган бу кулъязма Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (9 ф., 4 тасв., 146 эш).

[2] Үтенеч язуы тексты ТР Дәүләт архивында саклана (1 ф., 4 тасв., 3575 эш), беренче тапкыр киң катлау укучыларга Әбрар Кәримуллинның «Книги и люди» (1985) хезмәтендә тәкъдим ителә.

***«Аң»**да әдәбияттан башка тәнкыйди, сәяси-иҗтимагый, икътисадый, фәнни, сәнәгый, тыйби (медицина) вә әхлакый мәкаләләргә дә урын бирелеп, көлке вә һәҗүви кыйсем (сатирик бүлек) дә кертеләчәктер.*

***«Аң»**да каләм илә ярдәмләшер өчен атаклы шагыйрьләр, мөхәррирләр һәркайсы чакырылдылар. Анларны журналда берләшдерергә вә шунларның язган әсәрләре белән укучыларны таныштырырга тырышылачакдыр.*

***«Аң»**да мөхәррирләрнең һәм мәшһүр кешеләрнең рәсемләре, мәшһүр рус вә чит мәмләкәт рәссамларының мөселман вә башка халык тереклекенә даир (бәйле) рәсемләре һәм мәнзарәләре (күренешләре) басылып, урыны белән шунларга даир мәгълүмат биреләчәкдер.*

***«Аң»** ачык татар телендә, яхшы кәгазьдә, нәфис зурлыкта, яңа чыгарылган матур хәрефләр белән басылачакдыр. «Аң»ның матди җәһәттән дәвамы тәэмин ителмешдер* (1912, № 1).

Журналның нашире һәм җаваплы мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни үзе басманың бөтен эшчәнлеген оештырып алып бара. Аның бу эштә төп ярдәмчесе, фикердәше, киңәшчесе – тормыш иптәше Зәйнәп Хәсәния була. Аның белән аралашкан Мөхәммәт Мәһдиев Зәйнәп ханым сөйләгәннәр нигезендә болай дип язып калдыра: *«Ул авторлар белән эшли, корректура укый, һәр санның планын төзи. Ире Әхмәтгәрәй Хәсәни кәгазь, буяу, шрифт, машина мәсьәләләре буенча ерак шәһәрләргә йөри, “Гасыр” нәшриятенең китапларын сатуны оештыра. “Аң” журналының язмышы еш кына бер Зәйнәп кулына бәйле булып кала»* [Мәһдиев]. Ә. Кәримуллин билгеләвенчә, инкыйлабка кадәр татар матбагачылыгы тарихында журналистлык һәм мөхәррирлек эше белән шөгыльләнгән хатын-кызлардан Зәйнәп Хәсәния беренче була [Каримуллин, с. 158].

«Аң» журналы чын мәгънәсендә яңа әдәбият туу мәйданына әверелә, иҗади эзләнүләр, тәҗрибәләр, әдәби һәм фәнни проблемалар буенча бәхәсләр аның аерылгысыз өлеше булып китә, XX йөз башы татар милли сүз сәнгатендә тамырланган модернистик үрнәкләр дә нәкъ менә «Аң» битләрендә укучыга тәкъдим ителә, фәлсәфи-психологик эчтәлекле язмалар милли яшәешне камилләштерү юлларын эзләү омтылышы белән бәйле була. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «Аң» битләрендә милләтнең иртәгесе, киләчәге турында сөйләшү бара, иҗтимагый-мәдәни яңарышның милли үсеш-үзгәреш ихтыяҗына буйсындырылырга тиешлеге ачыклана. Моның теоретик нигезләре күзаллана [Заһидуллина, б. 18]. Ә. Кәримуллин билгеләвенчә, XX йөз башы татар вакытлы матбугатында милли әдәбият үсешенә керткән өлеше ягыннан «Аң»га тиңнәр юк [Каримуллин, с. 165].

«Аң» журналының концепциясен эшләүдә Тукайның роле зур булуы мәгълүм, журналның исемен дә нәкъ менә ул тәкъдим иткән, бу хакта Әхмәтгәрәй Хәсәни үзенең шагыйрьгә багышланган истәлегендә ассызыклый: *«Габдулла әфәнде Тукаев белән минем бу күрешүем актык мәртәбә булды. Шул кичне мин китеп, өч чирек сәгать*

*үтүгә, Габдулла әфәнде вафат итте. "Аң" журналы үзенең исем кушучысын* (ассызык безнеке. – *Л.Н.*), *мөәссисләреннән (нигез салучыларыннан) берсен, иң эшлекле мөхәррирен вә бөтен татарларның мактанычы булган иң кадерле шагыйрен һич кайтмаска югалтты...»* [Хәсәни, б. 177].

Басманың 1912 елның 15 декабрендә дөнья күргән беренче саны да Тукайның «Аң» шигыре белән ачыла. XX йөз башы татар сүз сәнгатендә өстенлек иткән уяну, таң мотивларын 1905 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә ирешелгән алгарыш белән турыдан-туры бәйләнештә күргән шагыйрь аннан соңгы елларда милләтнең әле йокылы-уяулы халәттә яшәвен ассызыклый, татарны алгарышка алып барачак «Аң» журналына зур өметләр баглый:

*Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул;*
*Инде эшлим саф, ачык күзләр белән – чын «Аң» белән.*
[Тукай, 2 т., б. 230]

Шуннан соң гомеренең соңгы көннәренәчә Тукай журнал белән тыгыз хезмәттәшлектә була: вафатына кадәр һәр номер диярлек аның шигырьләре белән ачыла, әҗәленә санаулы сәгатьләр калганда да хастаханәгә хәлен белешергә килгән Әхмәтгәрәй Хәсәнидән 8 нче санга бирелгән өч шигыренең корректурасы турында сорашуы шагыйрьнең журналга үзгә мөнәсәбәтен күрсәтүче фактор булып торадыр.

Журналда Тукайның, беренче номердагы «Аң» шигыреннән тыш тагын 12 шигыре дөнья күрә: «Йокы алдыннан» (1913, № 2), «Хәстә хәле», «Шиһаб хәзрәт» (1913, № 3), «Толстой сүзе» («Зур бәхет инсанга...»), «Даһигә» (1913, № 4), «Кыйтга» («Көчләремне мин...»), «Шөһрәт» (1913, № 6), «Тәфсирме? Тәрҗемәме?», «Толстой сүзе» («Кирәк анчак...») (1913, № 7), «Толстой сүзләре», «Буш вакыт», «Мәктәп» (1913, № 8[1]). Әхмәтгәрәй Хәсәнигә Клячкин шифаханәсеннән язган хатыннан Тукай «Аң»га үзе иң камил дип тапкан шигырьләрен генә җибәрүе турындагы фикер аңлашыла: *«"Бер мөхәрриргә" шигыремдә "Аң"га лаек дәрәҗәдә үк нәфасәт (кыйммәт) күрмәгәнемә күрә, "Мәктәб" журналына бирдем. Анда да ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем. Ахырда вә незаметныйрак җирдә китәчәк. 7 нче санда минем шигырь бик аз вә кешегә сизелерлек аз кергән. Өстәп йибәрергә бер нәрсәм бар иде. Инде, әлбәттә, соңдыр. Иншалла, 8 нчедән дә гафил калмам (абайламый калмам). Бер шәй (нәрсә) язармын*» [Тукай, 5 т., б. 239].

Шагыйрьнең шуннан соң бер атна вакыт үткәч, шифаханәдән язылган соңгы хаты Зәйнәп Хәсәниягә аталган, бу хатында да Тукай

[1] Журналның бу саны шагыйрь вафатыннан соң дөнья күрә, «Мәрхүм Габдулла Тукаевның иң соңгы шигырьләре» дип шәрехләнә, ахырга «1913 сәнә, 28 март. Шифаханә» дип языла. Үләренә берәр сәгать вакыт калганда, шагыйрь нәкъ менә шушы өч шигыренең корректурасы турында белешә. Журналның бу санында Тукайның 1912 елның 26 июлендә төшкән фотосурәте дә урнаштырыла һәм шагыйрьнең вафаты хакындагы хәбәр җиткерелә, матәм телеграммалары бирелә.

журналга керәчәк шигырьләренең язмышын кайгырта: *«Мөхтәрәмә Зәйнәб ханым! 8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче карриктуpын үземә күрсәтсәңез икән. Аннан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер нумирга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, “Толстой сүзләре”нең бер-икесен цензор бозар кеби сизәм. Ул вакыт һәммәсенең басылуы мәҗбүри үк булыр»* [шунда ук, б. 241].

Тукайның «Аң» журналын оештыруга керткән фидакяр хезмәте чордашлары тарафыннан һәрвакыт югары бәяләнә, аның вафатыннан соң да журнал битләрендә шагыйрь шәхесе һәм иҗаты турындагы җылы-сагышлы язмалар урын ала. 1913 елның 9 нчы санында, мәсәлән, Вакыйф Җәләлнең «Тукаев вафаты илә» шигыре бирелә. Тулысы белән сентименталь-экзистенциаль укылышта иҗат ителгән бу әсәрдә шагыйрь үлеме табигать кичерешләре фонында ачыла, лирик геройның хәсрәтле-сыктаулы күңел халәте традицион образлар ярдәмендә җиткерелә:

*Ялтырап тормый кояш та, күк йөзендә нурланып,*
*Нурлары сүнгән, тора хәсрәтләнеп һәм моңланып,*
*Балкыган ай берлә йолдызлар да моңланган кебек,*
*Бу кара йир өстенә күз яшьләре тамган кебек.*

[Җәләл, б. 146]

Журналның шушы ук санында Фатих Әмирханның «Тукай турысында искә төшкәннәр» һәм Ягъкуб Байбуринның «Габдулла Тукаев хатирәсе» дип аталган истәлекләре (анда ул шагыйрь белән Ташаяк ярминкәсендә йөргән чакларын искә төшерә) китерелә, Гали Рәхимнең «Тукаев – халык шагыйре» дигән мәкаләсе урын ала. Фатих Әмирхан мәкаләсендә әдипнең Тукай белән беренче күрешүләре, «Әлгасрелҗәдит» газетасындагы хезмәттәшлекләре, дуслашып китүләре, шагыйрьнең балаларга, хатын-кызларга мөнәсәбәте турында бәян ителә. Язманың азагында «дәвамы бар» дип куелса да, «Аң»ның башка саннарында бу мәкалә урын алмый.

Тукай иҗатына фәнни-тәнкыйди бәя шәкелендә иҗат ителгән мәкаләсендә Гали Рәхим, «Тукаев шикелле аз гына вакыт эшләп, шулкадәр зур шөһрәт казанган мөхәррир яки шагыйрь бик аз булыр» дип белдереп, Тукайның шөһрәтен аның иҗатының халыкчанлыгы белән бәйләп аңлата. Тукайның дөньяга карашлары халыкныкына охшаш булуын да Гали Рәхим аның халык шагыйре булып китүендә зур роль уйный дип күрсәтә: *«Тукаев әсәрләрендәге бөтен мәгънә – халык аңларлык мәгънәләр генә. Анда әллә нинди рухани куәтләре гади кешеләрнекенә караганда югарырак булган кешеләр генә аңларлык нечкә хисләр, әйтелеп бетмәгән сүзләрдән аңлануы тиешле булган назик мәгънәләр күп табылмый. Аның гамәлгә, тормышка, дингә карашлары халыкның шуларга карашыннан күп аерылмый»* [Рәхим, б. 152]. Шуңа бәйле рәвештә, Гали Рәхим «халык шагыйре» Тукай һәм «индивидуалист» Сәгыйть Рәмиев иҗатын каршы куя.

«Аң»ның 1913 елгы 10 нчы санында Тукайның Клячкин шифаханәсендә төшкән соңгы фотосы («Шагыйрь Габдулла Тукаев вафатындан бер көн элек» дигән исем белән) һәм «Казанда мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукаевны дәфен көне» дигән баш астында җеназа мәрасименнән өч фотосурәт урын ала. «Аң» журналының нәкъ менә шушы санында Әхмәтгәрәй Хәсәнинең дусты, фикердәше Тукайның соңгы көне турындагы хатирәсе урын ала. «Тукаев үлем көткәндә» дип аталган истәлегендә Хәсәни Тукайның соңгы көне, сәгатьләре турында хатирәләрен яза. Эмоциональ кичерешләр дулкынында язылган бу мәкалә Тукайның аянычлы, фаҗигале язмышын аңлаудан туган үкенечле хәсрәт хисе белән сугарылган. Әхмәтгәрәй Хәсәни мәкаләсеннән соң «Казанда Тукаевны җирләү көне» дигән язма китерелә, ул «Аңчы» тәхәллүсе белән тамгаланган. «Бөтен татар дөньясы өчен иң кайгылы көн» – Тукайны мәңгелеккә озаткан көн турындагы бу мәкалә, шагыйрь вафатына шактый вакыт үтсә дә, аның «Казанда җирләнү көне тугрысында язып китүне “Аң”үзенең үтәргә тиеш бурычы дип саный». Әлеге мәкалә Тукай мәрасиме көнен хронологик төгәллек, җентеклелек белән торгыза, халыкның шагыйрьгә хөрмәтенең никадәр зурлыгын, аның вафатының милләт өчен нинди зур югалту булуын раслый.

Шагыйрьнең үлеменә бер ел тулгач, 1914 елның апрелендә дөнья күргән номер тулысы белән Тукайның якты истәлегенә багышлана. Журналның титул битендә янәдән шагыйрьнең 1912 елгы фотосы китерелә, шулай ук Тукайның икенче бер фотосы, вафатыннан соң алган маскасының фотосурәте, җеназасыннан күренеш тә урын ала. Бу сан Габдулла Харисның «Тукай рухына» шигыре белән ачыла. Шагыйрьнең вакытсыз үлеменә халык җанының рәнҗүен ассызыклап, автор Тукай исеменең халык хәтерендә мәңге яшәячәген шигырьнең төп идеясе итеп формалаштыра:

*Мәңге онытылмас намең – халкың һаман сагнып сөйләр,*
*Җырларыңны милли саз берлән кушып, моңлап көйләр.*

*Бел, шагыйрь, шул моңлы җырларың илдә яңгырар,*
*Зур җаныңнан соңгы былбыллар да еш илһам сорар.*
[Харис, б. 130].

Шушы номерда Тукай рухына багышланган тагын бер шигырь – Рокыя Ибраһимиянең «Китте шагыйрь!» әсәре китерелә. Бәеткә тартым өслүбтә иҗат ителгән бу шигырь «Ханымнар хамисе (яклаучысы. – *Л.Н.*) мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукаевка ядкярән» язылган булуы искәртелә, шигырь дәвамында «милләтнең чын шагыйре» Тукайны зурлау, данлау идеясе белән бөтен татар халкы кичерешләрен бәян итүче лирик геройның ачыну-үкенечле сагышлы күңел халәте бергә үрелеп бара. Шигырь авторы, Тукай шәхесен бәяләүдә эпитет, чагыштыруларга мул мөрәҗәгать итә *(«милләтемнең ландышы син, йә миләүшәсе идең», «алмасы бик татлы булган бер алмагач идең син», «бакчамызда сайрый торган бик матур*

*былбыл идең»* һ.б.), шагыйрь әсәрләрендәге образларга җан өреп, хәсрәт дәрәҗәсен көчәйтә. Мәдхия-мактауга бай шигырьнең бетеме традицион шәкелдә:

*Һич тә чыкмас исемездән, Тукаев, исмең синең,*
*Керсә дә кара җиргә вакытсыз җисмең синең*
[Ибраһимия, б. 133].

Журналның бу санында Тукай турында истәлекләрдән Габдулла Кариевнең «Тукай Мәкәрҗәдә» (б. 134–135), Гыйльметдин Шәрәфнең «Тукай тугрысында истә калганнар» (б. 136–142) язмалары кителгән. Беренче мәкаләдә 1908 елгы Мәкәрҗә ярминкәсендә Галиәсгар Камал белән Тукай төшкән «Двухцветная» гостиницасында бер төркем зыялыларның җыелышып гәпләшүләре, көндезләрен сәхнәдә милли шигырьләр, җырлар яңгыратулары турында кызыклы истәлекләр бәян ителсә, Гыйльметдин Шәрәф мәкаләсендә Тукайның беренче шигырь мәҗмугаларын төзү, аның Казанга килүе, Казан яшьләре хакындагы фикерләре, «Яшен»дәге эшчәнлеге, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасының иҗат ителү һәм халыкка таралу тарихы турында аерым хатирәләр урын ала, шулай ук Тукайның беренче чорда чуар тел белән язылган шигырьләренә үзенең мөнәсәбәте дә ачыклап үтелә. «Калганы киләчәктә» дип искәртелсә дә, мәкаләнең дәвамы очрамады.

Әлеге санда дөнья күргән тәнкыйть мәкаләләрендә шагыйрьнең иҗат стиле мәсьәләләре игътибарга алына. Аерым алганда, «Габдулла Тукаев» мәкаләсендә (авторы – Г. Кәрам) шагыйрь иҗатының халыкчанлыгы тел-стиль белән мөнәсәбәттә карала. *«Тукаев шикелле халык арасыннан чыккан вә 6–7 ел эчендә шулкадәр күп язган вә ул нисбәттә шөһрәт казанган шагыйрь, бездә генә түгел, башка милләтләрдә дә сирәк табылыр»,* – дигән фикерне җиткереп, мәкалә авторы: *«Тукаев шигырьләренең бу дәрәҗәдә шөһрәтенә, минем белүемчә, ике сәбәп булырга кирәк: берсе – аның теле халис (саф) татарча булуы, икенчесе – ифадә вә өслүбенең җиңеллегедер»,* – дип күрсәтә. Г. Кәрам Г. Ибраһимовның «Тукай шагыйрьме? Түгелме?» дип куйган бәхәсле соравын кискен кире кага, *«кирәк кем, кирәк ни язсын – Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр»*, – дигән нәтиҗә ясый [Кәрам, б. 132].

Гали Рәфикыйның «Тукайны тәхаттыр (хәтерләү)» язмасында да Тукай иҗатының халыкчанлыгы турындагы фикер әйдәп бара: *«Тукайның язган әсәрләре – безем хәятыбызның эчен һәм тышын ачык күрсәтүче якты көзгеләр. Тукай тормышыбызның төрле табәкасыннан (катлауларыннан) мәузуглар (тема, проблема, сюжет) алып, һәрберсен арттырмый, яшерми, вакыйгада ничек булса, шулай язды. Ул муллаларны да, шәкертләрне дә, гавамны да, яшьләрне дә – барын да язды. Хатын-кыз турында аз язды. Ләкин нечкә хис белән аларның аяныч хәлләренә сызланды. Ул үзебезнең халык теле белән, халык рухында язды»* [Рәфикый, б. 143].

Журналның 1914 елгы 11 нче санының тышлыгында исә Исхак Бәхитовның «Тукай рәсеменә карап» дигән шигыре урын ала. Шагыйрьнең яшьли үлеменә хәсрәтләнү, ачыну хисләре иңләп узган бу әсәр Тукайның халык күңелендә мәңге яшәячәген раслау *(Җисмең күз алдыннан югалса да, / Мәңге калыр исмең югалмый!..)*, язмышка буйсыну *(Инде сиңа Хода билгеләсен / Матур-матур гөлле җәннәтен)* мотивлары белән тулыландырыла [Бәхитов, б. 201].

«Аң» журналының 1916 елгы 6 нчы санында Мәрьям Мөхетдиниянең «Габдулла Тукаев әдәбияты (Вафатына өч ел тулу мөнәсәбәте илә)» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Бу язмада *«тормышның бер генә ягын көйләүләре белән хәят агымыннан аерылган»* шагыйрьләргә каршы куелган (Мәрьям Мөхетдиния рус шагыйрьләреннән Тютчев, Фет, Надсон, Лермонтовларны шушы рәттә атый) Тукайның *«шигырьләрендә җырланмыйча калган нәрсә, аның күңелендә искә төшермичә үткәрелгән хәятнең һичбер тармагы юк; ул кышларны, җәйләрне көйли, шәһәр вә авылларны, иске мәктәп вә мәдрәсәләрне искә төшерә; дус вә дошманнарны, кайгы вә хәсрәтне, гашыйк вә мәгъшукларны берсен дә калдырмый шигырьләрендә яд итә»* [Мөхетдиния, б. 104] дип билгеләнә.

1917 елның берләштерелгән 3–4 нче саннарында, Тукай рухын яд итеп, редакция тарафыннан аның журналның тәүге номерын ачкан «Аң» шигыре яңадан бастырып чыгарыла. Бу вариантта инде беренче басмада цензура төшереп калдырган дүртенче строфа да өстәп бирелә:

*Кем бу гафләттән итә файда, шуны күрдек торып,*
*Шундый төнге аучыларның өстенә йөрдек торып,*
*Галибанә качырдык, барчасын сөрдек торып,*
*Чөн дә Чыңгызча сугышка башладык дошман белән.*

Шигырьгә редакция тарафыннан түбәндәге аңлатма бирелә: *«Бу шигырь мәрхүм шагыйремез Г. Тукаев тарафыннан «Аң»га багышланып, журналымызның беренче елгы 1 нче санында дәрҗ ителгән иде. Ләкин ул шигырьнең икенче мисрагыннан* (строфасыннан) *дүрт юлы, шул вакытларда матбугатымызны борындыклап алып, үзләренең каты хөкемнәрен йөрткән мәрхәмәтсез цензорлар тарафыннан журналымызда басарга манигъ ителеп* (тыелып), *төшерелеп калдырылган иде. Инде без мәзкүр* (югарыда әйтелгән) *шигырьне, хәзерге көннәрнең рухына бик якын тапканлыгымыздан, тулы бер мәгънәне аңлатсын өчен, бөтенләен берьюлы, шагыйрьнең идарәмездә сакланган мәсәүвәдәсеннән гайнән* (үзгәртмичә) *күчереп, «Аң»га тәкрар* (кабат) *дәрҗ итәмез. Цензор төшереп калдырган дүрт юл калын хәрефләр белән басылды. Идарә»*.

Гомумән, «Аң» журналының һәрдаим күзәтү астында булганлыгы архив документлары, Зәйнәп Хәсәния истәлекләреннән яхшы мәгълүм. «Гасыр» һәм «Аң» эшчәнлеге җентекле цензура үткән, Әхмәтгәрәй Хәсәни үзе дә полициянең яшерен контролен тоеп яшәгән,

шушы шартларда да ул гаҗәеп киң эчтәлекле, затлы, заманча журнал чыгаруга ирешкән. «Аң»ның соңгы номеры 1918 елның мартында дөнья күрә. Шул ук елда «Аң» типографиясе хөкүмәткә арендага бирелә, 1919 елда хуҗалары Әхмәтгәрәй Хәсәни белән Габдрахман Рәхмәтуллин аны рәсми рәвештә дәүләткә тапшыралар. Шул рәвешле, XX йөз башы милли матбугат тарихында иң әһәмиятле урыннарның берсен алып торган, гаҗәеп зур әдәби-мәдәни мирас булып калган «Аң» журналы заман давыллары эчендә югала.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

*Бәхитов И.* Тукай рәсеменә карап // Аң. 1914. № 11. Б. 201.

*Җәләл В.* Тукай вафаты илә ... //Аң. 1913. № 9. Б. 146.

*Ибраһимия Р.* Китте шагыйрь! // Аң. 1914. № 7. Б. 133.

*Каримуллин А.Г.* Книги и люди. Исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 304 с.

*Кәрам Г.* Габдулла Тукаев // Аң. 1914. № 7. Б. 130–133.

*Мансуров Г.* Татар провокаторлары. М., 1927. 76 б.

*Мәһдиев М.* Мөхтәрәмә Зәйнәп ханым... // Социалистик Татарстан. 1987. 8 август.

*Мөхетдиния М.* Габдулла Тукаев әдәбияты // Аң. 1916. № 6. Б. 104–106.

*Рәфикый Г.* Тукайны тәхаттыр // Аң. 1914. № 4. Б. 142–144.

*Рәхим Г.* Тукаев – халык шагыйре // Аң. 1913. № 9. Б. 149–152.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.

*Харис Г.* Тукай рухына // Аң. 1914. Б. 130.

*Хәсәни Ә.* Тукаев үлем көткәндә // Аң. 1913. № 10. Б. 176–177.

*Хәсәния З.* Хәтер түрендә // Азат хатын. 1967. № 4. Б. 16–17.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Н.М. Юсупова***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЛИРИК ГЕРОЙ: ҮСЕШ-ҮЗГӘРЕШЕ ҺӘМ СӘНГАТИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Статья посвящена изучению эволюции и художественной специфики лирического героя в поэзии Габдуллы Тукая, анализу поэтических средств выражения внутреннего мира лирического субъекта на различных этапах его творчества. В ней выявляются основные тенденции литературного процесса, нравственные, просветительские, общественно-философские проблемы как первопричины эволюции и трансформации лирического героя.

В ходе изучения доказывается, что лирический герой Г. Тукая эволюционирует от обоснованного просветительской традицией образа-просветителя в ранней лирике к философски мотивированному лирическому герою. В гражданской лирике он выступает личностью, посвятившей себя служению народу – «национальным хадимом», певцом народной жизни. Лирический герой поздней поэзии, продиктованной усилением экзистенциальных настроений поэта, строится на мотивах отчуждения и одиночества.

**Ключевые слова**: Габдулла Тукай; лирический герой; эволюция; трансформация; художественная специфика; поэтические средства.

The article is devoted to the study of the evolution and artistic specificity of the lyric hero in the poetry of Gabdulla Tukay, the analysis of the poetic means of expressing the inner world of the lyric subject (a hero of a poem) at various stages of the poet’s work. It reveals the main tendencies of the literary process, moral, educational, socio-philosophical problems as the primary reasons of the evolution and transformation of a lyric hero.

In the course of the study, it is proved that the lyric hero of G. Tukay evolves from the image-enlightener in the early lyrics, grounded in the educational tradition, to the philosophically motivated lyric hero. In civic poetry, he, the hero, appears as a person who has dedicated himself to serving the people – a “national khadim”, a singer of folk life. The lyrical hero of late poetry, influenced by the intensification of the poet's exisitational moods, is characterized by the motives of alienation and loneliness.

**Keywords**: Gabdulla Tukay; lyrical hero; evolution; transformation; artistic specificity; poetic means.

XX йөз башында татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере тирән үзгәрешләр чорына аяк баса, гасыр башындагы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар мәдәни барышта үзгәрешләр, борылышлар ясарлык мөмкинлекләр, шартлар тудыра. Милли азатлык, иҗтимагый гаделлек, милли алгарыш идеяләре татар укымышлыларының, җәмгыять эшлеклеләренең, милләтпәрвәр сүз осталарының аңын билгели, «милли проблемалар, демократик үзгәрешләр, гомумкешелек кыйммәтләре татар халкының яшәү мәгънәсенә әверелә» [Очерки истории татарской общественной мысли, 2000, б. 116]. XX йөз башы

татар җирлегендә «иҗтимагый яңарыш һәм үсеш идеяләре әдәбият, мәдәният, мәгариф өлкәләрендә үзгәреш, яңача сулыш кирәклеген аңлау белән бергә үрелә» [Заһидуллина, 2005, б. 194] һәм бу көчеш, яңарыш, яңа әдәби модель формалашу татар шигъриятеннән башлана. Аны үзгә фикерле, татар сүз сәнгатен Европа әдәбиятлары югарылыгына күтәрергә, борылыш ясарга омтылган, ташкын булып килеп кереп, һәркайсы үзе бер әдәби мәктәпнең лидерына, әйдаманына әверелгән шагыйрьләр нигезли. Г. Тукай шушы чорда әдәби мәйданга килеп, татар шигърияттен бик күп яңа сыйфат үзгәрешләре белән баета, күп кенә яңа тенденцияләр аның әсәрләрендә юл ала.

Тукай иҗатындагы яңарыш процессы шәхес концепциясенең, лирик геройның үсеш-үзгәреше белән янәшә бара. Иҗатында урын алган шәхес концепциясе шагыйрьгә яңа идея-фикерләр үткәрергә, үзгә дөнья сурәтен формалаштырырга мөмкинлек бирә: ул мәгърифәтче геройдан башлап, гражданин лирик герой, «милләт хадиме» аша фәлсәфи геройга кадәрге аралыкта үсеш-үзгәреш кичерә.

Г. Тукайның беренче чор иҗаты мәгърифәтчелек тенденцияләренең көчле булуы белән билгеләнә: мәгърифәтчел дөнья сурәте, мотивлар алгы планда тора, әхлакый кыйммәтләр, акыл, гыйлем алдында баш игән камил кеше югары күтәрелә. Еш кына гаруз шигырь системасы, шәркый жанр формалары кысаларында язылган шигырьләрне дидактик башлангычка омтылган, аң-белемне югары күтәргән мәгърифәтче лирик герой бер бәйләмгә туплый. Шул ук вакытта Г. Тукайның *«Син мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән; / Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем»* [Тукай, 2006, б. 47] дип белдергән лирик герое моңа кадәр иҗат ителгән мәгърифәтчелек әсәрләрендәге шәхес концепциясеннән аерыла. Шагыйрь иҗатындагы лирик герой мәгърифәт һәм мәдәни алгарышның милләт мәнфәгатьләре өчен булырга тиешлеген әйтеп мәйданга чыга һәм үзен милләтнең бер вәкиле буларак тәкъдим итә. Бу яктан Г. Тукай беренче чор иҗатында ук әдәби барышта формалашкан шәхес концепциясенә үзгәреш алып килә.

Аерым шигырьләрдә лирик герой шәхсиләшкән характердагы тәнкыйтьне кеше бәхетсезлегенә мөнәсәбәтле белдерә. Мисал өчен, «Татар кызларына» (1906), «Хатыннар хөррияте» (1906), «Государственная Думага» (1906), «Китмибез!» (1907), «Алтынга каршы» (1907), «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907) кебек шигырьләрендә лирик геройның мәгърифәтчел карашларга бәйләп тәнкыйтькә йөз тотуы күренә:

*Максуд җитәр: бара торгач – юл кыскарыр;*
*Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр;*
*Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,*
*Тәңрем фәйзы минем күңелгә эз салыр* [Тукай, 2006, б. 78].

Лирик герой фикерләре риторик эндәш алымы аша җиткерелә, аның кичерешләре метафорик сурәтлелек аша чагылып, мәгърифәтчел

дөнья сурәтенә хас бинар оппозицияләр аша гәүдәләнә. Мәсәлән, «Голүмең бакчасында» (1905), «Шигырь» (1905), «Дустларга бер сүз» (1905), «Алла гыйшкына» (1905), «И, каләм» (1905) кебек шигъри әсәрләрдә мәгърифәтле / надан, тәрәккыят / артталык оппозициясе мәгърифәтчел дөнья сурәтен билгели, лирик герой милләтне аң-белемле булырга өндәүче, тирән йокыдан уятырга омтылучы булып күзаллана. Әлеге герой мәгърифәтчелек һәм халыкның мәгърифәт, аң-белемгә омтылышын, мәдәниятен алга җибәрү («Голүмең бакчасында» (1905), «Шигырь» (1905) һ.б.) омтылышы белән яна, татар җәмгыятен җәдиди, иҗтимагый үзгәрешләргә өнди («Хөррият хакында» (1905), «Дустларга бер сүз» (1905), «Иттифакъ хакында» (1905) һ.б.).

Мондый тип лирик герой Тукайның шагыйрь һәм шагыйрьлек миссиясе темасына мөнәсәбәтле шигырьләрендә дә тотрыклы үстерелә. Ул шагыйрьлек эшен милли азатлык, ирек һәм халык өчен көрәш белән бәйләп аңлата, аны Алладан килә торган миссия дип раслый. Шуңа бәйле Тукай иҗатында пәйгамбәр-шагыйрь образы урын ала. Бу чорда пәйгамбәр-шагыйрь образы шагыйрь һәм шагыйрьлек темаларының поэтик гәүдәләнеше кебек кабул ителә. Аның төп мәгънәсе – шагыйрьлекне җир өстенә кешеләр арасында якты мөнәсәбәтләр урнаштыру, изге теләкләр тарату өчен җибәрелгән гуманистик максат итеп раслаудан [Татар әдәбияты тарихы, 1986, б. 100] һәм шәхеснең әхлакый кыйммәтен ачудан гыйбарәт. Шигърияткә гуманистик караш дәвам итә, аңа кешеләр арасында мәрхәмәт, кешелекле мөнәсәбәт урнаштыру максаты йөкләнә. Шагыйрь исә шул миссияне үтәргә килүче буларак күзаллана. Шушы фонда шигърияттә Аллага мөрәҗәгать каләмгә, шагыйранә сүзгә мөрәҗәгать белән алышына. Шагыйрьлекне пәйгамбәр миссиясе белән тиңләп карау тенденциясе пантеистик юнәлештәге суфичылык әдәбиятыннан ук килә. XVIII гасыр рус әдәбиятында да поэзия, шигъри сүзнең илаһи текстларга алмашка килүе һәм аларның функцияләрен үзләштерүе, илаһи сүзне халыкка җиткерүче пәйгамбәрнең шагыйрь шәхесе белән «урын алышуы» күренә [Лотман, 1997, б. 122]. Татар җирлегендә дә әдәби-эстетик фикер шундый секуляризация, сыйфат үзгәреше кичерә. Г. Ибраһимовның «Альбом мөнәсәбәте илә» (1915) мәкаләсендәге «Сәнгать – яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр ул диннең пәйгамбәрләредер», дигән фикере шуны раслый. Пәйгамбәр-шагыйрь образы Тукай иҗатында билгеле урын тота, мәсәлән, иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Пушкинә» (1906), «И, каләм» (1906), «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907) шигырьләрендә пәйгамбәр образы аша белдерелгән шагыйрь туры сүзе, таланты, иҗаты белән халкына хезмәт итәргә, яктылык, матурлыкка ышаныч уятырга, милләт идеаллары өчен көрәшергә тиеш дигән идея-фикер уздырыла.

Шагыйрь иҗатында бу тип лирик герой 1910 еллардан соң язылган шигырьләрдә дә дәвам итә. «Ике юл» (1909), «Даһига» (1913),

«Мөхәрриргә» (1913) һ.б. шигырьләрдә дә ул бәхетне мәгърифәткә бәйләп аңлата, аң-белемне милләтне, халыкны алга илтүче чара буларак ача. Мәсәлән, «Мөхәрриргә» (1913) шигыре Исхакыйны «пакь вә чын» сүз иясе, сурәт ясаучы, олы дан иясе, милләтпәрвәр шәхес итеп күтәрә. Шагыйрь аны 1905–1907 еллардагы инкыйлаб чорында демократик идеаллар белән рухланып йөреп тә, соңыннан шул юлдан читләшеп, үзара ызгышып яшәүгә күчкән «зыялылар» белән контрастлыкта сурәтли һәм үз идеяләренә тугрылыклы калган, «бер карашы иң шома ялганчыны сүздән тыйган» әдипне татар халкының рухи юлбашчысы дәрәҗәсенә күтәрә. Күренгәнчә, шигырьдә мәгърифәтле кешеләр генә милләтне алга җибәрә ала дигән фикер дәвам итә.

Тәнкыйтьнең аерым кеше шәхесенә бәйле этаптан җәмгыятьне тәнкыйтьләү баскычына күтәрелүе Тукай иҗатында тәнкыйди реализм агымының формалашуы хакында хәбәр итә. Мондый шигырьләрдә фикер яңарышының гыйлем, мәгърифәт, тәрбия һәм әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый, сәяси, аеруча милли проблемаларга йөз белән борылуы күренә. Тукайның тәнкыйть уты, иң беренче чиратта, «йокыга талган» татар җәмгыятенә юнәлтелә, шәхескә иҗтимагый тирәлекнең йогынтысы мәсьәләсе беренче планга чыгарыла, алар яшәп килүче тәртипләрне инкяр итү, барыннан да элек татар җәмгыятендәге иске тәртипләрнең юкка чыгарга тиешлеген раслау булып яңгырый. Бу сыйфат үзгәреше яңа тип лирик геройның мәйданга чыгуы белән янәшә бара. Аң-белемгә өндәгән, шул юлда халыкны бәхетле итәргә омтылган лирик геройга алмашка милли карашлы, тәнкыйди рухлы лирик герой килә, шагыйрь аны сурәтләүнең яңа юлларын, алымнарын эзли башлый.

Т. Гыйлаҗев бу вакытта иҗат иткән татар шагыйрьләренең каләм, шагыйрь, милләт, халык, тоткын... кебек мотивлар тирәсендә туплануын билгели [Гыйлаҗев, 2002, б. 95]. Гомумән, XX йөз башында иҗтимагый-фәлсәфи фикер татарларның милләт буларак оешып җитүе, милли буржуазия формалашу, җәдитчелек хәрәкәтенең яңа юнәлеш алуы кебек конкрет-тарихи шартлар тәэсирендә зур үзгәреш кичерә. Шулар тәэсирендә милли-мәдәни мәсьәләләргә игътибар көчәя, «милләтнең ... өметле юлы... дин тәэсире астыннан чыгып, милләт тәэсире астына керә» [Шәрәф, 1914, б. 41]. Татарларда милли күтәрелеш көчәю белән, милли үзаң формалашу, иҗтимагый фикердә татар милләтенең бүгенгесе, киләчәге кебек мәсьәләләрнең үзәккә куелуы, аның үсешен тәэмин итүче шартларның билгеләнүе, милли үсеш, тәрәккыят өчен милли бердәмлек, азатлык, шәхси ирек, сүз ирегенең, үз милләтең файдасына «чит милләтләрдән яхшыны алу» [Гобәйдуллин, 1913, б. 397] кебек сыйфатларның көчәюе шигъриятта милли проблематиканың тирәнәюенә китерә.

Шуңа мөнәсәбәттә миллилек һәм халыкчылык идеяләре шәхес концепциясенең характерын билгеләүче төп критерийларның берсенә әверелә. Шигърияттәге миллилекне бу чорда милли әхлак кагыйдәләрен күз алдында тотып язуда, милләт язмышына бәйле

идея-фикер үткәрүдә күрәләр. Әлеге үзгәрешләр тәэсирендә шигъри мәйданга халыкка игелек күрсәтүче, аңа риясыз хезмәт итүче, милләтне үстерүдә көчен кызганмаган, тормыш бәхетен милләткә хезмәттә тапкан, милләт үсеше, халык бәхете, хаклык өчен көрәшүче, кешенең фикри-рухи азатлыгын таләп итүче лирик герой, Й. Акчура сүзләре белән әйтсәк, «милләт хадиме» чыга, миллилек лирик геройга бәя бирүнең төп сыйфатына әйләнә. Халыкчылык төшенчәсе «идея байлыгы, идеалы күпчелекне эченә алган халык мәнфәгатенә хезмәт итү» [Исхакый, 1992, б. 83], «гавам мәнфәгатен алга кую, фәнне, сәнгатьне гавамлаштырырга хезмәт итү» [Вәлиди, 1915] буларак аңлана. «Ачы хакыйкать» (1909), «Сайфия» (1911), «Читен хәл» (1911), «Золым» (1911), «Тәмсил» (1911), «Көзге җилләр» (1911), «Дошманнар» (1912), «Авыл халкына ни җитми» (1912) һ.б. тәнкыйди реализм кысаларында язылган шигъри әсәрләрендә милли проблематика көчле яңгыраш ала, лирик герой татар җәмгыятенә хас проблемаларны калкытып куеп, аны үзгәртергә теләү омтылышы белән яшәүче булып күзаллана.

«Сәрләүхәсез» (1909) шигырендә дә шушы фикерләр алга чыга, лирик герой сүз остасының, милләт, халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга, «хәсрәт көен» көйләргә тиешлеген ассызыклый:

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әйбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен* [Тукай, 2006, б. 165].

Шигырьнең алдагы строфасында лирик герой шушы хәсрәт көенең сәбәпләрен ачыклап, кеше гомеренең, гомумән, хәсрәткә дучар ителүен аңлау ноктасына килә, кеше гомерен «караңгы, күңелсез» дип билгеләп, һәр кешенең «җәрәхәтле күкрәгендә» кайгы булуын җиткерә:

*Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,*
*Һич кайгысыз кеше булса – адәм түгел!* [Тукай, 2006, б. 165]

Г. Тукайның романтик рухлы, фәлсәфи эчтәлекле әсәрләре кешелек яшәеше, гомернең чикләнгәнлегенә борчылу, үлемнең котылгысызлыгын аңлау кебек экзистенциаль фикерләр белән сугарыла. Мондый әсәрләрдә сентименталь романтик лирик герой беренче планга чыгып, кеше һәм яшәеш проблемасы алга куела, яшәү мәгънәсен эзләү, гомумән, яшәешне яхшырту юлларын барлау игътибарга алына. Мондый шигырьләрдә Тукайның лирик герое эчкерсез саф мәхәббәткә, аның кодрәтенә, хатын-кыз гүзәллегенә дан җырлый, суфичылык символларына мөрәҗәгать аша аны илаһилаштыра [Йосыпова, 2016, б. 215] («Гыйшык бу, йа?..» (1906), «Алла гыйшкына» (1906), «Ифтирак соңында» (1906), «Мәхү идәрмисән?» (1906), «Сөеклемнең кабер ташында» (1906), «Хур кызына» (1906), «Син булмасаң!» (1907), «Мәхәббәт» (1908), «Бер рәсемгә» (1908), «Гашыйк» (1909) һ.б.).

Мәсәлән, «Гыйшык бу, йа» (1906) шигыренә күз салсак, гүзәл кыз, матур йөз, күбәләк, ут, шәраб кебек суфичыл символларның күпмәгънәлелеге шигырь тукымасында дини-суфичыл һәм шәркый мәдәни катламнарны тергезеп, аларны дини-суфичыл һәм дөньяви контекстларда «уку» мөмкинлеген калдыра. Шигырь тукымасында күбәләк – ут парлы символларына, исерү һәм әйләнү мотивларына мөрәҗәгать ителә. Шәм образы турыдан-туры чагылыш тапмаса да, әсәрдә әлеге образ ут символикасы аша шәрехләнә:

*Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;*
*Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем...*

*И гүзәл, кил каршыма, кил, елмайчы рәхим итеп,*
*Мин дә синең әйләнәңдә әйләнием, әйләнием...*

*Синнән исергәнемнән үлгәнче котыла алмам;*
*Күз һәм кашыңнан синең айланыем, айланыем* [Тукай, 1985, б. 68–69].

Суфиларда янып торучы шәм һәм шуның тирәсендә әйләнеп, утта эреп югалучы күбәләк сурәте актив кулланыла; әйләнү мотивының көчле булуы да билгеле, әйләнә-әйләнә транс халәтенә керү, Аллаһ белән кушылырга омтылу мәүләви тарикатендә көчле. Шигырьдәге әлеге сурәтләр суфичыл контекстта Аллаһ белән кушылырга омтылу мизгелен тасвирлый, лирик герой Илаһи гыйшык баскычында торучы кебек кабул ителә. Шушы яссылыкта шигырьдә Аллага мәхәббәт гармониягә китерә, дигән идея аерылып чыга.

Символларның икепланлылыгы әсәрне дөньяви эстетика кысаларында шәрехләү мөмкинлеген дә бирә. Бу вариантта күбәләк гашыйк җанны белдереп, ут символикасы мәхәббәтне аңлатуга күчә, әйләнү, исерү мотивлары да дөньяви мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Лирик герой җир кызына мәхәббәт тотучыга әверелә. Шуларга нисбәтән шигырьнең идеясе дә үзгәрә: мәхәббәт кеше күңеленә «үлгәнче тирбәнерлек» рәхәт бирә, бәхет китерә.

Аерым шигырьләрдә әлеге тип лирик герой табигать күренешләренең, пейзаж матурлыгын күреп соклана, шатлана, хозурлана («Ана догасы» (1909), «Җәйге таң хатирәсе» (1910) һ.б.). Мәсәлән, «Ана догасы» (1909) шигыренең беренче өлешендә табигатьнең матурлыгы, гармониясе, тынычлыгы сурәтләнә. Икенче өлештә табигать белән дога укучы ананың халәте ялгап куела: айның матурлыгы, илаһилыгы ана күңелендәге матурлыкка, изгелеккә, чисталыкка күчерелә, Аллага булган мәхәббәт дәрәҗәсен ачуга юнәлтелә, ягъни икенче өлештә ай символик образы ярдәмендә кеше күңелендәге илаһи матурлык турында сүз алып барыла. «Җәйге таң хатирәсе» (1910) шигырендә табигать гүзәллеге илһам чыганагы булып килә, җәйге табигатьнең, таң ату күренешенең гүзәллеге, табигый гармония Тукайның матурлык идеалы белән тәңгәлләшә.

Шагыйрь әсәрләрендә экзистенциаль мотивларның, сызлану фәлсәфәсенең көчәюе яңа тип лирик геройны алгы планга чыгара.

Мондый әсәрләрне сызланучы, философ лирик герой бер бәйләмгә туплый. Әлеге лирик герой чынбарлыкны экзистенциаль тоемлауның нигезе буларак төшенкелек, сызлану фәлсәфәсен укучыга җиткерә. Мондый шигырьләр күбрәк 1909–1912 еллар аралыгында языла. Мәсәлән, «Күңел» (1909) шигырендә лирик геройның, үз күңеленә мөрәҗәгать итеп, аны уйланырга, сызланырга чакыруы белән очрашабыз. Күңел газаплары, җан авыртуы шигырь структурасында лирик геройның горурлану белән үкенеч арасында тирбәлүенә китерә. Шуңа мөнәсәбәттә ул үз артыннан башкаларны ияртерлек әйдаман һәм язмыш кыерсытуларына, яшәеш кануннарының камил булмавына бәйле фәлсәфи уйланулар дулкынында тирбәлүче шәхес, философ булып күзаллана.

«Өмидсезлек» (1910) шигырендә исә дөньядан ваз кичкән лирик герой кеше гомере чикле һәм ул үлемгә таба бара кебек фикерне ассызыклый. «Өзелгән өмид» (1910) шигырендә яшәеш икегә: эссенция һәм экзистенция баскычына бүленеп, яшәү мәгънәсе эзләнә. Шуңа бәйле тормышта бәхетле була алмау хакыйкатенә төшенгән, экзистенция баскычындагы лирик герой алгы планга чыга. Бөтен гомерен халкына багышлаган шагыйрьнең яктылык, яхшылык турындагы идеаллары, өметләре тормышка ашмау лирик герой күңелендә сагыш хисен уята. Ул бертөрле мәхәббәтнең дә булмавын аңлаудан туган ачынуга ишарә ясый, гомернең үтүе, кешенең үлем алдында аның котылгысызлыгына төшенүе, яшәүнең мәгънәсезлеге, үз-үзеңнән канәгатьсезлек кебек төсмерләр аша сызлану фәлсәфәсен үткәрергә мөмкинлек бирә.

«Үкенеч» (1910) шигырендә дә җир йөзенең караңгылыгына, кешеләрнең әхлаксызлыгы, икейөзлелегенә әрнегән, ачынган лирик герой үзенең эчке халәте белән уртаклаша:

*Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз –*
*Ничек күктә яна бер данә йолдыз?*
*Шулай янсам, ни булды, төшми җиргә,*
*Якынлашмыйча һәр мәгърур сәфилгә!*
*Янып ялгыз шулай, күп еллар үткәч,*
*Сүнәр идем, Ходайдан вәгъдә җиткәч* [Тукай, 2006, б. 190].

Шигырь лирик геройның үз тормыш хәле, яшәеше белән бәйле хәсрәт хисенең үсә баруы рәвешендә язылган. Ул, экзистенциаль рухта, милләт өчен янып яшәп тә, кешеләр арасында, үлем каршында үзенең ялгызлыгы, көчсезлеге, чарасызлыгы өчен сызлана. Һәр якның нурсыз, караңгы булуы, кәгъбә-идеалның югалуы кебек әдәби детальләр сызлануны көчәйтү чарасына әйләнә. Алга таба шигырьдә шәхси күңел төшенкелеге, Яшәешнең мәгънәсен күрмәү мотивлары милләтнең киләчәгенә бәйле өмет белән сугарыла.

«Кыйтга» (1913) шигырендә дә үзенең яшәү мәгънәсе, яшәү миссиясе хакында уйланучы, сызланучы ялгызак лирик герой сурәтләнә, ул «кара көннәр»дән торган, дошманнары «эттән күбәйгән», пычрак дөньяда яшәве, әмма аны үзгәртә алмавы өчен сызлана. Шуңа

мөнәсәбәттә *«Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: / Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»* [Тукай, 2006, б. 244], дип белдерә.

Шул рәвешле, Г. Тукай иҗатында лирик герой әдәби барышта, иҗтимагый-фәлсәфи фикердә барган үзгәрешләр тәэсирендә үсеш-үзгәреш, трансформация кичерә. Бик күп яссылыкларда татар шигъриятенә яңарыш алып килгән, яңа үсеш сукмакларын салган шагыйрь лирик герой концепциясен дә яңа үзенчәлекләр, яңа хасиятләр белән баета.

**Әдәбият**

*Вәлиди Җ.* Мөгаллимә // Вакыт. 1915. 10 гыйнвар.

*Гобәйдуллин Г.* Милләтне ничек аңлыйсыз? // Аң. 1913. № 22. Б. 397–398.

*Гыйлаҗев Т. Ш.* XX йөз башы татар әдәбияты тарихын укыту мәсьәләләре. Методик кулланма. Казан: Печатный двор, 2002. 395 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Исхакый Г.* Тукай мәхәббәте // Мирас. 1992. № 4. Б. 83–85.

*Йосыпова Н.М.* Поэзия: XX йөз башы // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 206–226.

*Лотман Ю.М.* Литература в контексте русской литературы XVIII века // О русской литературе. СПб., 1997. С. 118–137.

Очерки истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 191 с.

Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 3 т.: XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 599 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 5 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 405 б.

*Тукай Г.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.

12. *Шәрәф Җ.* Ничек аңларга? // Аң. 1914. № 2. Б. 40–42.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге доценты*

УДК 821.512.145

***З.З. Рәмиев***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ ХАТЛАРЫ

Статья посвящена изучению взаимоотношений двух татарских поэтов – Габдуллы Тукая (1886 –1913) и Сагита Сунчелея (1889 –1937), прежде всего на основе восьми писем (1910 –1911 г.), адресованных Тукаем Сунчелею. Они были обнаружены в личном архиве Сунчелея и были опубликованы после его реабилитации Шарифом Сунчелеевым (братом поэта). Письма свидетельствуют об их весьма уважительном отношении к творчеству друг друга, о положительном влиянии поэтических устремлений Тукая на молодого поэта.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, С. Сунчелей, творчество, письма, литература.

The article is devoted to the study of the relationship between two Tatar poets – Gabdulla Tukai (1886 –1913) and Sagit Suncheley (1889 –1937), mainly based on eight letters (1910 –1911) addressed to Suncheley from Tukai. They were found in the personal archive of Sunchelei and were published after his rehabilitation by Sharif Suncheleev (the poet's brother). The letters reveal their very respectful attitude to each other's work, the positive influence of Tukay's poetic aspirations on the young poet.

**Keywords:** G. Tukai, S. Suncheley, creativity, letters, literature.

1958 елның 8 мартында СССР Югары суды Хәрби коллегиясе «өчлек» карарын юкка чыгаргач кына, 1937 елда Соловкида атып үтерелгән күренекле татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләйнең дә (1889 елда туган) тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнү, XX гасыр башы татар поэзиясендәге урынын ачыклау юнәлешендә беренче адымнар ясала. Мәсәлән, 1961 елда шагыйрьнең зур булмаган «Сайланма әсәрләре» басылып чыга. Шул ук вакытларда аның архивының мөһим өлеше бертуган агасы Шәрифҗан Сүнчәләй кулында сакланганлыгы мәгълүм булып, андагы материаллар белән танышу мөмкинлеге дә туа. Алар арасында кемдер тарафыннан күчерелгән Габдулла Тукай хатлары да табыла. Бераздан бу хатлар Ш. Сүнчәләйнең кереш сүзе белән, «Совет әдәбияты»ның 1960 елгы 4 нче санында нәшер ителәләр (барысы 12 булып, дүртесе югалган[1]). Сәйфи Кудашның Ш. Сүнчәләйгә язган бер хатында (5.10.1958) С. Сүнчәләйнең аларны Уфа шәһәрендә 1918 елның 2 апрелендә уздырылган Тукай кичәсендә (вафатына 5 ел тулу уңае белән) укуы әйтелә. Хатларның текстлары Тукайның биш томлы «Әсәрләр»ендә һәм алты томлы Академик басмасында искәрмәләр белән басылды. Бу урында исә аларның язылу тарихына караган мәгълүматны тулырак бирү максаты куелды.

[1] Р. Ишморат, Ш. Сүнчәләй сүзләренә таянып: *«Алар Сәгыйтьне төрмәгә алып киткәндә башка күп кенә кульъязмалары белән белән бергә юкка чыккан»,* – дип яза [Ишморат, 1989].

Тукайның беренче мәктүбеннән (ул 1910 елның 9 октябре белән даталанган) аңлашыла ки, ул шул елда гына да 30 лап шигыре белән үзен татар вакытлы матбугаты битләрендә («Идел», «Бәянелхак», «Йолдыз», «Казан мөхбире», «Вакыт» газеталарында, «Шура»да, «Ялт-йолт»та) танытып өлгергән яшь шагыйрь хатына[1] җавап рәвешендә язылган. Күренә ки, хат алышуны Сүнчәләй үзе башлап җибәргән. Ай ярым гына элек Камалетдин Хисаметдиновка юллаган «ачык хат»ында (открыткада): *«Һәр өч хатыңны алдым. Җавап язмаганым өчен гафу итәсез. Чөнки һичкемнең хатына да каршы җавап язмыйм. Әллә нигә ялкауландым. Хәзер бер җирдән дә хат килми. Барысы да минем җавап булмаганга тукталдылар»,* – дип акланган Тукай бу очракта «ялкаулыгын» җиңгән кебек – нәкъ менә Сүнчәләй хаты аны бу хәлдән чыгарга мәҗбүр иткән. Ни өчен соң Сүнчәләй хатын *«шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галәбәле рольне»* [Ибраһимов, 1910][2] уйнаучы «мөхтәрәм Тукаев»ка юнәлткән? Күрәсең, үз язганнары турында Тукай кебек шагыйрьнең сүз-фикерен ишетергә теләве аны шушы адымга этәргән. Бу фаразыбызның дөреслеккә якын торуын Тукай хатын укыганда күрми мөмкин түгел. Тукай Сүнчәләй шигырьләрен кулына төшкәндә укып баруын, аларда *«милләткә яки шәһәрткә бик кызу мәхәббәт бар»*лыгын таный, һәр язганының «нәфис һәм изящный» түгеллеген дә әйтә, шигырьнең, аз язылса да, *«матур вә хуш иттереп»* язылуын тели. Тукай Сүнчәләй әсәрләренең теленә дә игътибар итә, анда «провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр» таба, аларны катнаштырмаска[3] өнди. Чөнки Тукай күңеленә нык бер караш-фикер тирәнтен кереп урнашкан: *«Мин үзем – шовинистлык дәрәҗәсеннән узган бер милләтче. Мин Казанны тәхте пай һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятыбыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим».* Хатта Тукай Сүнчәләй алдында үзенең күңелен били башлаган авыр шәхси кичерешләрен дә (тормыштан, аның турында уйлаудан бизүен) яшерми, үзенең әле язып бетермәгән атаклы «Өзелгән өмид» шигыренең баш өлешен китерә һәм үзенең электә, *«жизнерадостный»* чагында, *«гомерен җылап үткәргән»* Надсон поэзиясен сөймәвен, хәзер инде фикере үзгәрүен, башкачарак булуын әйтә. Шунысы да ачык күренә: беренче хатында ук Тукай

[1] *«Кышка каршы... мин аңар «Мәхбүс»тән берничә сәтыр (юл) җибәргән идем. Вәзеннәрем зәгыйфьрәк иде. Шуңар Тукай үгет язды»,* – диелә С. Сүнчәләй истәлегендә.

[2] Автор, сүзен дәвам иттереп: *«Шул дәрәҗә ки, татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр»,* – дип тә язган.

[3] Бу фикеренә мисал булырлык сүзләр китерми. Сүнчәләй әсәрләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнгән Ф. Таһирова Сүнчәләй әсәрләрендә диалекталь сүзләрнең Тукай әйткәннән соң да чагылыш табуын язды *(«Основной характерной особенностью языка, по нашему мнению, следует считать яркую диалектную составляющую»)* [Тагирова, 2014, s. 1177–1180].

Сүнчәләйнең *«дустанә озаткан кулын ... мәгальмәмнүният[1] кысып»* кабул итә, аның белән киләчәктә дә «озын-озын мөзакәрәләр» булачагына өметләнә.

Тукайның хәерхаһлы, ихлас хаты Сүнчәләй күңелендә бу форматтагы әңгәмәне дәвам иттерү теләген көчәйткән шикелле. Бу аның «Шагыйрьгә мәктүб»[2] һәм «Хат кисәге (Г.Тукаевка багышлап язылган иде)»[3] исемле шигырьләрен укыганда да сизелә. Озакламый, шул ук ноябрьнең ахыргы көннәрендә ул Тукайга тагын хат белән мөрәҗәгать итә. Әйтергә кирәк, үз чиратында Тукай да кулына каләм ала, анысына да 4 декабрьдә үк хат белән җавап бирә. Бу юлы әңгәмә Тукайның үзенә дә якын темалар, мәсьәләләр тирәсендә бара. Күрәсең, Сүнчәләй хатында Тукайны да кызыксындырган бөек инглиз шагыйре Байрон [Мусабекова, 2016, б. 94–95; Юльметова, 1961; Нигматуллин, 1977, с. 42–44] иҗатына мөнәсәбәтле момент чагылган була. Тукайның җавапсыз калмавы шуның белән дә бәйле шикелле. 1907 елда, шигырьләренең икенче җыентыгында [Габдулла Тукаев шигырьләре, 1907] ук ул «Байроннан» исемле иҗади тәрҗемәсен (Лермонтов тәрҗемәсе аша) бастыра[4], «Мәхәббәт» шигырендә (1908) «әсәр тукымасына Европа һәм рус әдәбиятларының бөек шагыйрьләре исемнәрен китереп кертә» (алар арасында Байрон да бар). Сүнчәләй хатына игътибарлы булуны Тукайның шигъри тәрҗемә, элеккеге иҗатчылар әсәрләренә ияреп язу өлкәсендә үзенең дә шактый еш чыгыш ясавы белән бәйләп карарга тиешбездер. Дөрес, 1908 елда Касим Уралец исемле берәү хәтта Тукайны тәрҗемәче сыйфатында гына күрүен, оригиналь шигырьләрен бик аз итеп күрсәтеп язып чыккан иде. Әмма шул чор матбугатында аның бу фикере А. Пинкевич, Ф. Әмирханнар тарафыннан кире кагылды.

Тукай белән хат алышу башланганчы ук, Надсон, Плещеев, Тургенев, Крылов әсәрләренә ияреп язуда азмы-күпме тәҗрибә туплаган, үзе дә романтик табигатьле Сүнчәләй, мәшһүр инглиз романтик шагыйре Байронның «Шильон тоткыны» поэмасын да татарчалаштырырга алынып, Тукайны бу эшкә мөнәсәбәтен белү уена килә. Тукайның бу икенче хатында төп фикер әнә шуның тирәсендә әйләнә дә. Аныңча, Сүнчәләй бу эшкә иртәрәк, көченең *«микъдарын үлчәмичәрәк тотынганга охшый», башта кыскарак, «4–5 сәтырлык шигырьләрне асыл шагыйрендән калышмаслык дәрәҗәдә гүзәл вә нәфис чыгарырга тырышырга кирәк иде»*. Тукай үзенең дә, Сәгыйть Рәмиевнең дә олы поэмаларга тотынырга батырчылык итә алмавын таный. Әмма Сүнчәләй, бу сүзләргә карап, әлеге поэманы тәрҗемә итүдән

[1] *Мәгальмәмнүният* – шатлык белән.

[2] «Бәянелхак» газетасының 1910 елгы 9 ноябрь санында басылган. Анда: *«Мыскыл ителгән сынык җан һәр заман хыяллана, / Уйласа сезнең Казанны, дәртләнә, илһамлана»,*– дигән юллар бар.

[3] «С. Сүнчәләй шигырьләре»ндә (Казан, 1913) 1910 елгы әсәрләр рәтендә «25 октябрь» датасы белән китерелә.

[4] 1909 елгы икенче басмасы «Байроннан» шигыре белән ачыла!

баш тартмаган һәм бераздан әсәрнең тулы текстын Тукайга юллап, аның фикерен белергә омтылган. Тукай исә тәрҗемәне Сүнчәләйнең үтенүе буенча укып чыга [Мөкатдимә, б. 195–196]. Сүнчәләй истәлегендә (1923), «Мәхбүс»не язып бетергәч, текстны Тукайның яратуын, көтепханәдә бастыруны үз өстенә алуын, төзәткәләп күчереп чыгуын һәм «Мәгариф» нәшриятына басарга биргәнлеген яза. «Шильон мәхбүсе» исемле бу китапның кереш өлешендә[1] (1911 елның 23 апрель язылган) Тукай әсәрдәге мәгънәләрнең *«үз милләте вә үз мәмләкәте чигеннән үтеп, бөтен көррәи әрызның хәссас[2] вә көчле күңелләрен сил ташуы кебек»* басуын әйтә, хәтта Пушкин, Лермонтовларның да Байрон әсәрләре йогынтысын татып, «байронизм» мәзһәбендә иҗат итүләренә басым ясый. Байрон әсәрләренең татар теленә күчерелмәвен зур кимчелек итеп санаган Тукай, шулай итеп, Сүнчәләйнең бу иҗат җимеше китап рәвешендә дөньяга чыгуына[3] шатлыгын белдерә. Дөрес, «Бәгъзе килмешәкләрнең (Тукай дошманнарының) коткысы сәбәпле» ике шагыйрь арасында бераз гына кәеф китешү дә булып ала, әмма 1911 елның көзендә алар аңлашалар, үзара гафу итешеп онытышалар.

Хатларга кайчак шәхси тормыш-яшәешка кагылышлы мәсьәләләр дә килеп керә. Мәсәлән, Сүнчәләйне беренче хатыны Сәлимәнең баладан үлүе аркасында ялгызлыкка дучар булуы шактый борчыган булса кирәк, һәм ул Тукай алдында да гаилә кору мәсьәләсенә караган уй-фикерләрен ачып салган, киңәшләшкән шикелле. Җаектан кайтып Казанда яши башлагач та, Тукай күңелендә дә гыйшкый хисләр туу очраклары була (мәсәлән, Зәйтүнә Мәүлүдовага нисбәтле). Әмма инде бу хат язылган вакытка (1911 ел, 4 декабрь) ул реаль тормыштан чыгып, рациональ фикер йөртмәкче. Аныңча, *«рәфыйкаңның[4] хакын бөтенләй үк тәләф итмәгән[5] булсаң, син – аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә, шәрмәндәи гыял[6] булмасын өчен, иң азында җыл тәүлегеңә 5 йөз тәңкә килерең булса, һәркемгә өйләнү тиеш»*, әгәр инде *«“ике күңелдә чын мәгънәсе белән булган мәхәббәт уты янмаса, гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә мөрәҗәгать вә тәрилкә тотарга булса” өйләнмәскә кирәк, (“Алла сакласын!”)»*.

Тукай хатларында шагыйрьләрнең үз иҗади гамәл-омтылышлары, шулай ук татар вакытлы матбугатында, татар мәгарифендә, әдәби дөньясында бара торган хәлләр турында да фикерләр очрый. 22 гыйнвар 1911 ел даталы хаттан күренгәнчә, мәктәп китаплары төзү, бастырып чыгару белән шөгыльләнүен Сүнчәләйнең хупламавы («җәл»

[1] Китапның 1924 елгы басмасында бу кереш («Мөкатдимә») төшереп калдырылган.

[2] *Көррәи әрызның хәссас...* – Җир шарының сизгер...

[3] Китап Казанда «Мәгариф» нәшриятында басылган. 1924 елда поэма Байронның вафатына йөз ел тулу уңае белән икенче мәртәбә («аз гына төзәтмәләр белән») басыла (Уфа: «Октябрьский натиск», 30 б. ).

[4] *Рәфыйкаңның* – хатыныңның.

[5] *Тәләф итмәгән* – юкка чыгармаган.

[6] *Шәрмәндәи гыял* – гаиләне оятка калдыру.

дигән була) белән килешми: *«Мин мәктәпләремезнең хәл теле илә миндән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын белән карый алмадым. /.../ Мин үз шигырьләрем чүпләтеп башкалардан мәктәб китабы яздырганчы, әллә нинди шәкертләрне күрә торып баеткачы, бу эшкә үзем тотындым»*, ди (үзен «сөюдә дә милләтче» итеп күрә, «татар кызының телен, сөйләшү рәвешен» яратуын да яза)...

Ике шагыйрьнең күзгә-күз очрашуы 1911 елның августында булса да, хатлар язышу дәвам иткән. Әмма без икесе белән генә, алары да, әйткәнемчә, күчермәләр генә, таныша алабыз. Кунакханәдә номерлар җылытылмаганнан, 29 сентябрьдә үк зарлана, сәламәтлеге дә кабат тынычсызлый башлаган Тукай 1911 елның 20 октябрендә язган хатында: *«Авыруына кайгырмаганым шикелле, сәламәтләнүенә*[1] *дә куанмыйм. Барыбер»*, – дип яза. Анда ул Сүнчәләйгә үзенең бер борчуын да ача. Эш шунда: Тукай Парижда 1908 елда чыга башлаган «Мусульманин» журналында язышкан шагыйрь һәм журналист Мирсәяф Кырымбаев белән очрашкан, сөйләшкән була. Ул 1911 елда Петербургта чыга башлаган «В мире мусульманства» газетасын да укып барган, күңелендә анда язышырга да исәп тоткан икән. «1911 ел, 1 гыйнвар» тарихлы хатында Тукай: *«“Мусульманин”да, Ходай илһам бирсә, бик каты участвовать итмәкче булам»,* – ди. 22 гыйнвар тарихлы хатында: *«“Мөселманин”ның мөселманча чыгуы, әлбәттә, күңеллерәк булыр иде»,* – дип тә язган. Әмма әлеге басмаларның тоткан мәсләкләре турында төрле сүзләр ишетелү аны шикләндерә, җитмәсә, әле ул М. Кырымбаевның *«чукынмаганлыгына һәм дә татар булып калуына таянып»,* аның алдында үз рухын ачып салган була. Һәм бу басмалар тирәсендә эш йөртүчеләр хакында шөбһәләнеп, Сүнчәләйгә: *«Син аларны кемләр дип таныйсың? М*[2]*. ул кафказлыларга*[3] *алданып йөрми микән?»* – дигән сорау бирә. Сорауның нәкъ менә Сүнчәләйгә бирелүенә нигез дә бар. Күрәсең, алдагы хатларның берсендә Сүнчәләй «Мусульманин» журналы турында сүз алып барган. Бу аның «Мусульманин» журналы» исемле кыска гына мәкаләсеннән дә (Идел. 1911 ел. 19 октябрь) күренә. Автор журналның финанс ягыннан авыр хәлгә калганлыгын сөйләп, аны чыгаруга укучылардан акча сорый.

Тукайның кавказлылардан сагаюы исә бу вакытларда аның әсәрләре, басмалары белән цензура әһелләренең кызыксынуларына да бәйле булса кирәк...

Хәзерге вакытта Тукайның күп томлы басмаларында аның 35 хаты басылып чыкты. Әйтергә кирәк, аларның нәкъ менә Сүнчәләйгә адресланганнарында (8 хат) ике шагыйрь өчен дә мөһим мәсьәләләр тикшерелә, бер-берсенә ихтирамлы караш өстенлек итә.

---

[1] Хатның автографында «авыруыма», «сәламәтләнүемә» дип язылгандыр шикелле.

[2] М. – бу хәреф астындагы Мирсәяф сүзе сызылган.

[3] «Мусульманин» журналының нашире һәм редакторы (адыгей кешесе) М. Хаҗи Теләши һәм «В мире мусульманство» газетасы редакторы (осетин) А.Г. Датиев турында сүз бара. Бу басмаларның эшчәнлеге Россия мөселманнарына каршы юнәлтелгән була.

Соңгы хатында (1911 ел, 15 ноябрь) «*Сине мин һәр тугрыда сәдадил кеше таптым»,* дип язган Тукайның Сүнчәләй белән соңгы мәртәбә очрашканда (дөресрәге, саубуллашканда) аңа көмеш сәгатен бүләк итүен дә искә төшерсәк, ике шагыйрь арасындагы мөнәсәбәтләрнең чын мәгънәсендә дустанә булганлыгына инанырбыз.

**Әдәбият**

*Ишморат Р.* Язмышыма мең рәхмәтле! // Социалистик Татарстан. 1989. 13 август.

*Ибраһимов Г.* Татар матбугаты // Йолдыз. 1910. 12 январь.

*Тагирова Ф.И.* С. Сунчелей: особенности языка // Türk Dünyasında Sosyal ve Ekonomik İşbirliği. Kongre bildirileri. 2 Cild. İstanbul: Türk Dünyası Araştırmalar Vakfı: 2014. S. 1177–1180.

*Мусабекова Р.Р.* Байрон Джордж Гордон // Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016. Б. 94–95.

*Юльметова С.Ф.* Байрон рухы, Гейне ялкыны // Соц. Татарстан. 1961. 25 апрель.

*Нигматуллин Э.Г.* Раздвигая века и границы. Казань, 1977. С. 42–44.

Габдулла Тукаев шигырьләре. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр). Икенче кыйсем. 1907.

*Тукай Г.* Мөкатдимә // Габдулла Тукай. Әсәрләр: 6 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр. 2015. Б. 195–196.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 821.512.145

*Л.Ә. Медведева*

# Ә. УРМАНЧИЕВ һӘМ Г. ТУКАЙ

Статья посвящена творческой деятельности журналиста и редактора литературно-научного, общественно-политического сатирического журнала «Ялт-йолт» («Зарница») А. Урманчиеву (1880–1922) и идейного вдохновителя издания, поэта Г. Тукая (1886–1913). Автор обращается к малоизвестным фактам из жизни известных личностей, проводит обзор их совместной деятельности, определяет дальнейший потенциал исследования в данном направлении.

**Ключевые слова:** А. Урманчиев, журнал Ялт-йолт, Г. Тукай, татарская периодическая печать.

The article is devoted to the creative activity of the journalist and editor of the literary-scientific, socio-political satirical magazine “Yalt-yolt” (“Zarnitsa”) A. Urmanchiev (1880–1922) and the ideological inspirer of the publicationjournal, the poet G. Tukay (1886–1913). The author refers to little-known facts from life of these famous people, reviews their joint activities, determinesand determines the further research potential in this field.

**Keywords:** A. Urmanchiev, magazine Yalt-yolt, G. Tukay, Tatar periodical press.

Егерменче йөз башында татар вакытлы матбугаты зур күтәрелеш кичерә, Россиянең күп кенә шәһәрләрендә, шул исәптән Казанда да татар телендә газета-журналлар чыга башлый, китап басу эше алга китә. Казанда нәшер ителгән татар вакытлы матбугаты битләрендә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек күренекле иҗат әһелләре бәяләп бетергесез хезмәт куя. Кызганыч, алар арасында ни өчендер исеме бик сирәк телгә алына торган шәхесләр дә бар. Нашир һәм журналист, татар шагыйре Г. Тукайның замандашы, һәрвакыт аралашып, бергә хезмәттәшлек иткән якын дусларының берсе Әхмәт Урманчиев әнә шундыйлардан.

Урманчиев Әхмәт Шәрәфетдин улы 1880 елда туа [Габдулла Тукай. Энциклопедия, 2016, б. 671]. И.Г. Рәми һәм Р.Н. Даутов төзегән «Әдәби сүзлек»тә аның тумышы белән Касыйм төбәгеннән булуы күрсәтелә [Әдәби сүзлек, 2001], тәрҗемәи хәле турында башка мәгълүмат бирелми. «Татар энциклопедиясе»ндә (1999, 2002, 2014) бу шәхес турында бөтенләй искә алынмый.

Ә. Урманчиевның туган төбәген Җаек шәһәрендә гомер итүче Нәҗия Мәхмүт кызы Төхвәтуллина истәлекләре ярдәмендә ачыкларга мөмкин булды. Нәҗия ханымның әтисе – Әхмәт Урманчиевның бертуган энесе. Аларның чыгышлары белән Рязань губернасы Касыйм өязе Яубаш (хәзерге Рязань өлкәсе Касыйм районы) авылыннан булуы билгеле булды. Бу авыл Касыйм татарлары җирлегенең Ак аймак дигән төркеменә керә. Ак аймакка Касыйм ханлыгының аксөякләренә караган зур дүрт авыл кергән (дүрт сала дигән атамасы да бар): Шырын, Бием сала, Татарбай (Тарбаево), Яубаш (Болотце). Нәҗия ха-

нымның истәлекләренә караганда, Урманчиевлар үз утарларында хәлле генә тормыш алып барганнар. Бу гаиләнең нәсел дәвамчылары безнең көннәрдә утарны яңадан торгызганнар. Наҗия Төхвәтуллина үзе дә катлаулы тормыш юлы уза: яшьли ятим кала, балалар йортында тәрбияләнә, ачы сугыш елларын кичерә. Җаекта мәктәпне бетергәч, педучилищега укырга керә, соңрак пединститутны да тәмамлый, гомерен балалар укытуга багышлый. Язмышы катлаулы булуга карамастан, үзенең нәсел җепләрен югалтмый, татар халкының мәдәниятен һәм сәнгатен саклау өлкәсендә зур эш алып бара, татар иҗтимагый үзәге эшендә актив катнаша.

Ә. Урманчиевның Казандагы тормышы 1907 елда «Юл» китап нәшриятын оештырып җибәрүдән билгеле. Нәшрият китап бастыру һәм сату белән шөгыльләнә. 1910 елда ул Мәхмүдә исемле гаять укымышлы кызга өйләнә. Мәхмүдә 1893 елда Казанда мулла гаиләсендә туа. Әнисе шагыйрә һәм мөгаллимә М. Мозаффариядән башлангыч белем ала, аннары Х. Әхмәрова мәктәбендә укый. Соңрак үзе дә Ф. Аитованың кызлар мәктәбендә балалар укыта. Яшьтән үк Г. Тукай шигырьләрен укып, алар тәэсирендә үзе дә шигырьләр иҗат итә. Мәгърифәтле Мәхмүдә Ә. Урманчиевның китап кибетеннән төрле китаплар сатып ала торган була. Шулай танышып китәләр һәм гаилә коралар.

1910 елның 15 мартыннан Казанда Ә. Урманчиев наширлегендә һәм мөхәррирлегендә әдәби-фәнни, иҗтимагый-сәяси «Ялт-йолт» журналы чыга башлый. Айга ике тапкыр чыга торган журналның җаваплы секретаре итеп Г. Тукай билгеләнә. Менә шуңа күрә Г. Тукай Мозаффария-Урманчиевлар белән тыгыз мөнәсәбәттә була. Үлеменнән соң шагыйрьнең берничә шәхси ядкяре дә М. Мозаффария гаиләсендә саклана. Мәһруй ханым вафат булгач, аның улы – күренекле композитор Мансур Мозаффаров, әнисенең васыяте буенча, ул әйберләрне СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына тапшыра, аннан аларны музейга бирәләр. Бу ядкярләр турында Әхмәтнең улы Тимур болай дип искә ала: «Ул кәрзин еллар буе безнең өйнең чарлагында торды. Кечкенә чактан ук безне «Бу Габдулла Тукай кәрзине, аңа тияргә ярамый», дип өйрәттеләр. Ул кәрзиндә янына бик матурлап ау эте, аучы мылтыгы һәм аучы сумкасы ясалган кызыл бакырдан коелган кара савыты, аннан Пушкин, Лермонтов, Никитин, Майков, Некрасовның китаплары саклана иде» [Рәсүлева, 1985, б. 126]. Бүген исә бу гаиләдә сакланган кадерле ядкярләрне Г. Тукай әдәби музеенда күрергә мөмкин.

Милли музей фондында «Ялт-йолт» журналының 1910–1911, 1911–1912, 1912–1913 еллардагы тупланмалары да саклана. Аларны музейга 2010 елда Әхмәт Урманчиевның оныгы – улы Тимурның кызы Гүзәл Урманчиева тапшыра. Гүзәл Тимур кызы сүзләренә караганда, Ә. Урманчиев гаиләсе хәзерге Г. Тукай урамында, 138 йортта яши. Аларга еш кына Г. Тукай да килеп йөри. Ул хәтта шул йорттагы мич морҗасын да музейга бүләк итә.

1957 елда музей фондларына Ә. Урманчиевның фотосурәте дә тапшырыла. Аны «Аң» журналының җаваплы сәркәтибе Зәйнәп

Хәсәния бирә. Фотосурәтнең алгы ягында «Мөхтәрәм “Аң” мөхәррире вә нашире Әхмәтгәрәй Хәсәни җәнабләренә бүләгемдер. Әхмәт Урманчиев. 5/1. 1916» дигән автограф бар. Димәк, бу сурәт Зәйнәп ханымның тормыш иптәше, «Аң» журналының мөхәррире һәм нашире Әхмәтгәрәй Хәсәнигә бүләк ителгән.

Ә. Урманчиевның Г. Тукай белән танышлыгы 1907 елның көзендә, шагыйрь Казанга кайткач башлана. Ул Тукайның соңгы көннәренә кадәр аның якын дусты һәм фикердәше булып кала. 1910 елдан башлап алар «Ялт-йолт» юмор-сатира журналында хезмәттәшлек итәләр. Журнал, рәсемнәр белән бизәлеп, Харитонов матбагасында басыла. Барлыгы 123 саны дөнья күрә, 1918 елның июнендә ябыла. Журнал битләрендә төрле сатирик мәкаләләр, шигырьләр урын ала. Анда Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ф. Сәйфи-Казанлы, С. Сүнчәләй, М. Укмасый һәм башкаларның әсәрләре басыла. Бик күп язмалар яшерен имза белән чыга. Г. Тукай исә журналда «Гөмберт», «Шүрәле» кебек яшерен имзаларын куллана.

Ә. Урманчиев «Ялт-йолт» журналын чыгарырга уйлагач та, бу турыда Тукай белән уртаклаша. Ул истәлекләрендә: «Милләт өчен бер көлке журналы кирәклегенә ышанып җиткәч тә, бу турыда башлап киңәшләшкән кешеләремнең берсе Тукай иде. Ул бу эшкә бик әһәмият биреп, минем күңелне уйлаганнан артык күтәрде» [Урманчиев, 2015, б. 131], ди. «Ялт-йолт»ның беренче саны дөнья күргәч тә, тагын да рухланып, «бу журналга ахыргы минутларына кадәр хезмәт итәчәгенә вәгъдә бирә» [Урманчиев, 2015, б. 131].

Журналның мөхәррире һәм нашире дип Ә. Урманчиев саналса да, Г. Тукай басманы чыгаруда күп эшне үзе алып бара, аның чын-чынлап мөхәрриренә әйләнә. Шагыйрь «Ялт-йолт»ның сыйфатлы булып чыгуы өчен үзен җаваплы саный, һәр санның мәкаләләрен, рәсемнәрен үзе әзерли. Сатирик басманы чыгаруда Г. Тукайның соңгы көннәренә кадәр зур хезмәт куюын Г. Камал үз истәлекләрендә: «Яшен» туктагач, ул «Юл» көтепханәсе ияләреннән Әхмәт Урманчиев тарафыннан чыгарыла торган «Ялт-йолт» журналында берьялгызы эшли, мин тик ташка төшерү өчен карикатуралар гына эшләп бирәдер идем. Бу эш 1912 ел ахырына кадәр барды» [Камал, б. 300], дип билгеләп уза. Шул заман юмор-сатира журналлары арасында иң алдынгысы саналган «Ялт-йолт»ны «Яшен» журналының дәвамчысы дип атарга мөмкин. Г. Тукай бер мәкаләсендә бу турыда: «Сез бу “Ялт-йолт”ны кайдан ялтырый дип беләсез? Ул һаман да шул яңадан терелгән “Яшен” нурыннан ялтырый» [Тукай, 2015, б. 116], дип искәртә.

Г. Тукай Казаннан киткән чагында да Ә. Урманчиев белән даими хат алышып тора. Әстерхан, Уфа һәм Өчиледән язган хатларында журнал өчен борчылуы, аның һәр санын укып баруы күренә. 1911 елда шагыйрьнең Әстерханнан язган хатында: «Киләсе хатымда рәсемләр өчен темалар вә, булдырып булса, мәкалә вә шигырьләр дә җибәрсәм кирәк» [Тукай, 2016, б. 222], дип журналның киләсе санын кайгырта. Шул ук вакытта «бу мәкаләләрне дөрест басарга иҗтиһад

итеңез» [Тукай, 2016, б. 222], дип шелтәләп тә ала. 1912 елның башында Өчиледә абыйсы Кәшфелкәбирләрдә дәваланып ятканда язган хатында: «Әхмәт! Мин монда. Хәзергә кайтуымнан бик мәмнүнмен. “Ялт-йолт” чыккач, миңа җибәрерсез әле... Иншалла, рәсем мәүзугълары вә мәкаләләре җибәрсәм кирәк» [Тукай, 2016, б. 229] дип журнал турында кайгыртуын дәвам итә. Шул ук елның маенда Уфадан язган хатында: «38 нче “Ялт-йолт” гомумән яхшы чыккан. Мәскәү мулласының лексиясен әүвәлге биткә басарга кирәк иде. Бу номерда да әдәпсез сүзләр бар. Шундый сүзләргә юл киселсен иде» [Тукай, 2016, б. 231], дип киңәшләрен дә бирә.

Ә. Урманчиев, Г. Тукайның якын дусты буларак, аның шәхси үтенечләрен дә кире какмый. Өчиледән язган хатында: «Әхмәт! Син калушны кәрзинкәгә салган кебек идең. Ул ничектер монда килмәгән. “Шәрык”тә калмаганмы? Аннан соң минем паспорт “Шәрык”кә килергә тиеш. Килгән булса, зинһар, тизлек белән миңа җибәр» [Тукай, 2016, б. 229], дип үтенә.

Г. Тукай Урманчиевлар гаиләсендә дә еш була. Бу турыда Мәхмүдә Мозаффария: «...көлке “Ялт-йолт” журналының төп язучыларының берсе булганлыктан, Тукай безгә эш буенча килгәләп йөри һәм килеп керү белән безнең, ягъни хатын-кызлар бүлмәсе аркылы, Әхмәтнең эш бүлмәсенә тиз генә үтәргә ашыга иде...» [Мәхмүтова, 2012, б. 354], дип искә ала. Г. Тукай сәяхәтләре һәм Клячкин хастаханәсендә дәваланган вакытында үзенең кәрзинен һәм шәхси әйберләрен Урманчиев өендә калдыра торган була. 1912 елда Уфадан язган хатында шагыйрь: «керләрне җибәргәндә, почтада җугалмаслык итеп, эченә минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем “Җан азыклары” дигән пачти шул мәҗмугалык шигырьләрем бар» [Тукай, 2016, б. 232] дип, кәрзиндә онытылып калган дәфтәрне җибәрүен сорый. Күргәнебезчә, журналда бергә эшләү алар арасындагы дуслыкны тагын да ныгыта, моңа бу бу ике шәхеснең бер-берсенә язган хатлары дәлил булып тора.

Г. Тукай Клячкин хастаханәсендә дәваланганда Ә. Урманчиев аның янына бик еш килеп йөри. Шагыйрьнең соңгы төнендә дә аны Ә. Урманчиев белән Ш. Әхмәров саклап чыгалар. Иртән торгач, бергәләп сөйләшә-сөйләшә чәй эчәләр, шагыйрь аларны «кичкә тагын килсәгез, бик яхшы булыр иде» дип озатып кала. Бу дусларның соңгы саубуллашуы була. Ә. Урманчиев – Г. Тукайны соңгы юлга озатучы, җирләүне оештыручыларның берсе дә. Бу вакытта төшерелгән фотоларда Әхмәт Урманчиевның булуы әнә шул турыда сөйли.

Шагыйрь вафат булгач, «Ялт-йолт» журналы Г. Тукайның сатирик басмага нигез салучы булуын, «беренче нумирыннан башлап үзенең вафаты көненә кадәр журналда хезмәт итеп килүен» [Усал, б. 642] искәртә. «Габдулла Тукаевның вафаты “Ялт-йолт” идарәсе өчен гомергә онытылмаслык бер югалту вә гаять зур бер хәсрәт булды» [Усал, б. 642], дип белдерелә. Г. Тукайның үлеме мөнәсәбәте белән журнал редакциясенә Әстерханнан килгән тәгъзия телеграммасында:

«“Ялт-йолт” журналына үзенең шундый олуг мөхәррирен югалту кайгысына иштирак итәбез», – дип, шагыйрьнең басманың мөхәррире булуы билгеләп үтелә.

Г. Тукайның вафатыннан соң дуслары аның тәрҗемәи хәлен язу һәм аның турында хатирәләрне бастырып тарату хакында киңәшләшәләр. Мәгълүмат җыю өчен өч адрес тәкъдим ителә. Ул адресларның берсе итеп Ә. Урманчиев һәм аның «Юл» китап нәшрияты күрсәтелә. Бу турыда, мәсәлән, «Йолдыз» газетасының 1913 елның 18 апрель санында хәбәр ителә. Димәк, Тукай турында беренче мәгълүматларны һәм хатирәләрне туплауда Ә. Урманчиев башлап йөрүчеләрдән була. Г. Тукай турында истәлекләр җыйнау турында башка басмалар да язып чыга.

Г. Тукайның кайбер әсәрләренең кульязмалары Ә. Урманчиевның өендә сакланган булуы билгеле [Тукай, 2011, б. 350]. Бүген алар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Тукай фондында саклана. Ул кульязмалар арасында шагыйрьнең «Яшен яшьнәгәндә», «Кечкенә музыкант» кебек әсәрләре бар.

Ә. Урманчиев 1922 елда вафат була. Кызганыч, башка мәгълүмат юк.

Вакыт узган саен шагыйрь Г. Тукай даирәсендәге күренекле шәхесләр турында яңа мәгълүматлар табу кыенлаша бара. XX йөз башы татар матбугаты тарихында күренекле урын биләгән нашир һәм журналист Ә. Урманчиев эшчәнлеге бүгенге мәдәни тормышыбыз тарихында читтә калмасын иде.

**Әдәбият**

*Камал Г.* Габдулла Тукай турында истәлек // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 295–301.

*Мәхмүтова А.Х.* Вакыт инде: без дә торыйк... Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 366 б.

*Рәсүлева З.* Тукай эзләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 141 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. 2 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. 5 т. / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.

*Тукай Г.* «Яшен» мәрхүм // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 4 т.: проза, публицистика (1907–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. Казан, 2015. Б. 431.

*Урманчиев Ә.* «Ялт-йолт» һәм Тукай // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 131–132.

*Усал.* Габдулла Тукаев хатирәсе // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 642.

***Медведева Ләйсән Әхмәт кызы,***
*Г. Тукай әдәби музее өлкән фәнни хезмәткәре (Казан)*

УДК 821.512.145

# КӨЛКЕ ЖУРНАЛЫ («ЯШЕН»)

3 августа 1908 г. в Казани начинает издаваться иллюстрированный журнал юмора и сатиры «Яшен» («Молния»). Издателем и редактором журнала был Галиасгар Камал (1879–1933), секретарем – Габдулла Тукай (1886–1913). Вниманию читателей предоставляется статья-рецензия на первый номер журнала, вышедшая в номере газеты «Эльислах» от 14 августа 1908 г. за подписью неизвестного автора с псевдонимом «Саади». Автор статьи поясняет понятия «высмеивание», «посмешище», «сатира», «юмор», рассуждает о значимости юмора в межчеловеческих и общественных отношениях и отмечает его как самое действенное орудие в мире периодической печати. В статье приводится оценка и краткий обзор статей и карикатур, увидевших свет в первом выпуске журнала «Яшен».

**Ключевые слова:** татарская периодическая печать, журнал «Яшен», юмор и сатира, Г. Тукай, Г. Камал.

On August 3, 1908, the illustrated magazine of humor and satire “Yashen” (“Lightning”) was published in Kazan. The publisher and editor of the magazine was Galiasgar Kamal (1879–1933), Gabdulla Tukai (1886–1913) was the secretary . The readers are presented the article-review of the first issue of the magazine, published in the the newspaper “El-Islah” dated August 14, 1908, signed by an unknown author with the pseudonym “Saadi”. The author of the article explains the concepts of "ridicule”, “satire”, “humor”, discusses the importance of humor in interpersonal and social relations and notes it as the most effective tool in the world of periodicals. The article provides the assessment and brief overview of the articles and cartoons published in the first issue of the “Yashen” magazine.

**Keywords:** Tatar periodical press, Yashen magazine, humor and satire, G. Tukay, G. Kamal.

## Кереш сүз

1905–1907 елларда Россия дәүләтендә барган сәяси-иҗтимагый вакыйгалар, җәмгыятьтәге үзгәрешләр, хәрәкәт татар дөньясын да уята. Илдәге яңа вазгыять татар җәмәгатьчелегенә милли матбугат булдыру хакында хыялланырга мөмкинлек бирә. 1905 елның 19 сентябрендә Санкт-Петербургта Гатаулла Баязитов наширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Нур» газетасы чыга башлый. Бу елларда рус матбугатында сатирик басмаларның («Жупел», «Свобода», «Пчела», «Застенок», «Казанский раешник» һ.б.) саны артуы күзәтелсә, татар телендәге сатирик журналларның («Чикерткә», «Чүкеч», «Карчыга», «Уклар», «Туп») барлыкка килүе дә шушы чорга карый. Нәкъ шушы вакытларда татарның мәдәни үзәге булган Казанда да сатирик басма булдыру өлкәсендә җанлану күзәтелә. Бу эшкә иң беренчеләрдән булып, журналистика өлкәсендә инде тәҗрибә туплап өлгергән, «Казан мөхбире»ндә каләм уйнаткан, «Азат», «Азат халык» газеталарында

мөхәррирлек иткән, «Йолдыз» газетасы секретаре Г. Камал алына. «Йолдыз» газетасының 1906 елгы декабрь ае санында дөнья күргән һәм газета мөштәриләренә юлланган игъланда: «Хәзердән еллык акчасыны түләп язылган мөштәриләргә *(язылучыларга)* «Йолдыз» ның мөхәррире санисе *(икенче мөхәррире)* Галиәсгар Камал әфәнде идарәсендә айда бер микъдарында нәшер кылыначак «Яшен» исемендә көлке вә мотаябә *(күңел күтәрү)* журналы буш юлланачакдыр»[1] дип хәбәр ителә. Ләкин 1907 елга планлаштырылган бу эш ниндидер сәбәпләр аркасында тоткарлана. Көлке журналын бастыру нияте белән янып йөргән Камал нәкъ шушы вакытларда үзен «Яшенче» дип игълан итә, әдипнең 1907–1908 елларда иҗат ителгән шактый язмалары шушы имза белән дөнья күрә.

1907 елның көзендә Г. Тукай Казанга килә. Казаннан Уральскига, Габдулла Кариевка язган хатында үзенең мондагы тормышыннан бик канәгать булып, зыялылар белән аралашып фикер алышуы, үзе теләп «Әлислах» газетасына эшкә урнашуы турында яза[2]. Татар иҗтимагый-мәдәни тормышының эчендә кайнаган Г. Тукай, Ф. Әмирханнар да Казанда көлке журналы булдыру хыялы белән янып йөриләр. «Әлислах» газетасының 1908 елгы бер санында тиздән рәсемле сатира һәм юмор журналы чыгарылачагы турында хәбәр ителә: «Якын заманда «Әлислах» идарәсе һәфтәлек (*атналык*) көлке журналы нәшер итәргә рөхсәт алачактыр, һөҗүви журнал мәдрәсә мәгыйшәтенә *(тормышына)* генә хас булмыйча, татар мәгыйшәтенең һәр тарафыны тәнкыйть итәчәктер...»[3]. Әлеге көлке журналының проекты Ф. Әмирхан тарафыннан инде эшләнгән булса да, тормышка ашмый кала[4].

Г. Камал 1908 елның май башында Казан губернаторы канцеляриясенә үз мөхәррирлегендә, татар телендә, рәсемле «Яшен» журналы чыгарырга рөхсәт сорап гариза яза. 1908 елның 1 июлендә «Яшен» журналы нәшер итәргә рәсми рөхсәт бирелә[5] һәм шул ук елның 3 августында журналның беренче номеры дөнья күрә. Журнал редакциясе Г. Камалның Хәйбуллин йортындагы (Большая Мещанская урамы) фатирында урнаша. Басманың нашире, мөхәррире һәм рәссамы – Г. Камал, секретаре – Г. Тукай. Журналны оештыруда һәм чыгаруда Ф. Әмирхан да зур көч куя. «Яшен»нең беренче санында ук Тукайның шигырь һәм мәкаләләре күренә, шулар арасында – журнал чыга башлау уңае белән язылган «Август башы» мәкаләсе һәм «“Яшен” журналы хакында» исемле шигыре, «Сыбызгы», «Тотса

---

[1] [«Йолдыз» газетасына киләчәк 1907 нче сәнә өчен…] // Йолдыз. 1906. 3 декабрь.

[2] *Тукаев Г.* Габдулла Кариевка // *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т.: Мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 198.

[3] Казанда көлке журналы // Әлислах. 1908. 17 март.

[4] *Гимадиев У.И.* Г. Камал и «Яшен» / Галиасгар Камал (сборник статей, посвященный 100-летию со дня рождения писателя). Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. С. 70.

[5] Шунда ук.

Мәскәүләр якаң!», «Ысуле кадимче» һ.б. бар. Шагыйрьнең замандашы Г. Шәрәф әйткәнчә, журналның беренче номерында: *«...башыннан ахырына ахырына кадәр Тукайның каләме йөри»*[1].

Тукай «Яшен» журналында бик яратып эшли, журналның һәр номерын әзерләүгә зур көч куя, кызыклы материаллар табарга тырыша, Г. Камал белән берлектә рәсем асларына язмалар әзерли. Биредә шагыйрьнең сатирик таланты үсә. Тукай «Яшен» журналының төп авторларыннан берсе булганлыктан, үз язмаларын еш кына төрле псевдонимнар белән яки имзасыз бастыра. Журналда Тукайның алтмыштан артык язмасы урын алган, алар, нигездә, «Г. Тукаев», «Гөмберт», «Гөмберрт», «Гөмбербррт», «Шүрәле», «Кырмыска», «Сәгыйть», «“Хәятел хайван”нан күчерүче», «Милләтче», «Тәртә башы», «Мин язмадым», «Мөгаббир» имзалары белән бирелгән. Шагыйрьнең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы да «Яшен» журналы өчен языла башлый, әмма күләме зур булу сәбәпле, шагыйрь аны аерым китап итеп бастырырга карар бирә[2].

Журналның яртысын, төгәлрәк әйтсәк 1, 4–5, 8–9, 12–13 битләрен рәсемнәр һәм карикатуралар алып тора. Аларның барысы да диярлек Г. Камал кулы белән эшләнгән һәм татар җәмгыятенең актуаль сәяси, иҗтимагый һәм мәдәни темаларын сатирик планда сурәтли.

Журнал халык тарафыннан яратып кабул ителә һәм тиз арада популярлык казана. Ү. Гыймадиев китергән мәгълүматларга караганда, журналның тиражы шактый зур, 1400 дән алып 2000 экземплярга хәтле җиткән. «Яшен»не татар укучысы гына түгел, ә башкорт, үзбәк, казакъ, азәрбайҗаннар да яратып укыган. Журналны Кавказ, Төркестан, Якутия төбәкләреннән һәм Россиянең төрле өлкәләреннән яздырып алганнар[3].

Кызганычка каршы, «Яшен» журналының гомере озын булмый, бары тик 10 саны дөнья күрергә өлгерә. Матди кыенлыклар, цензура кысулары нәтиҗәсендә ул 1909 елның июнь аенда нәшер ителүдән туктый.

Укучылар игътибарына «Яшен» журналының беренче номеры чыгу уңае белән язылган мәкалә-рецензия тәкъдим ителә. Язма 1908 елның 14 августында «Әлислах» газетасының 41 нче санында «Сәгъди» имзасы белән басылган.

*Г. Ханнанова*

---

[1] *Шәрәф Г.* Тукай турында истә калганнар // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммлар. Казан: Җыен, 2015. Б. 271.

[2] *Гимадиев У.И.* Г. Камал и «Яшен» / Галиасгар Камал (сборник статей, посвященный 100-летию со дня рождения писателя). Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. С. 72.

[3] Шунда ук. Б. 71.

Казанда татарча беренче көлке журналы «Яшен» күп көтелгәннән соң, ахырысы, чыга башлады. Баш мөхәррире – чибәр әсәрләре илә яшь мөхәррирләремез арасында мөһим урын алган Галиәсгар әфәнде Камалдыр. Г. Камал әфәнде әсәрләрендә, хосусан «Беренче театр»да, үзенең оста көлүче икәнен күрсәткән һәм Казанда татарча гәзитә чыга башлаганнан бирле гәзитәчелек илә шөгыльләнгән, егерменче гасырның татарча яңа әдәбияты чыга башлау илә шуның хезмәтенә бирелгән кәнеж *(яшь)* мөхәррирдер.

Үзе мәдрәсә махсулы *(җимеше)* улып, иске тормышның инсанны кыса вә изә торган икәнен татып белгән вә шуны сизә башлаганнан бирле шуңа каршы җиһад *(көрәш)* илә мәшгуль булган заттыр. Ул үзен газаплаган иске тормыштан үч алырга, вә аның әшәкелеген башкаларга да ачык күрсәтеп аннан яшьләрне биздерергә керешкән. Вә моның эчендә иң якын юлны көлке журналы чыгаручылыкда күргәндер.

Беренче номерны күрү илә журнал тугрысындагы мөхакәмәнең *(хөкем йөртүнең)* һәммәсен язып бетерергә иртәрәк булыр. Беренче номерны күрүнең тәэсиратын язганчы, гомүмән, көлке тугрысында берәр сүз әйтеп китәсем килә. Мәсхәрә көлүе *(сатира)* бөтен көе аңлансын өчен, мин монда сөю көлүе *(юмор)* тугрысында берни дә әйтмим. Укучыларны мәсхәрә көлүенә алып кереп китәм. Көлү, мәсхәрә итү – зәгыйфь адәм балаларына бирелгән иң үткен коралларның берседер. Мескен адәм баласы бишектән кабергәчә мыскылны *(мәсхәрәне)* кешелеге дәрәҗәсендә сизә, аңлый. Аңа каршы үзенең калтырап торганын беләдер.


الاصلاح ٧ نومر ٤١

كولكى ژورنالى .

باش

«Әлислах» газетасы. 1908. № 41.
«Көлке журналы» мәкаләсенең башы

Хәтта гаҗәп, кешенең кай яктан булса да зураюы арткан үлчәвендә көлкедән, мәсхәрәдән куркуы да арта бара. Эшләнергә хәзерләнгән бик күп ямьсез эшләрнең бер «көләрләр» дигән сүз илә эшләнми калганы аз түгелдер.

Аһ, бу «көләрләр»... Бу бер авыз сүз байтак кешене үз хәленнән килмәслек эшләргә көчли, байтак кешенең йокысын калдыра, тынычлыгын качыра, котын очыра. Күп күзләрнең яшен түгә, күп симезләрнең маен эретә, канын сыздыра, күпме кешеләрне бу каһәр сүз малыннан аера, пакь теләрдән ялган сөйләтә, мәңгегә тугры буласы килгән кешеләрне якыннарына да хыянәт кылдыра... Холыкны ансерәтә *(боза)* торган авыруларның азымы «көләрләр» өрәгеннән куркып булган?

«Көләрләр» булмаса, җаен тапкан кешеләр дөньяда тагын рәхәтрәк тора булырлар иде. Ул булмаса, көчлеләрнең күбесе үз көчләренең чиген белмичә әллә ниләр кыланырлар иде. Дөньяда хәзергә күрә ун, бәлки йөз өлеше әшәкерәк мөгамәләдә булырлар иде.

«Кешедән яхшы түгел...», «артында көләрләр... битеңә әйтерләр...» , «көлкегә калырсың...», «атың-чабың чыгар...» дигән сүзләр күп кешеләрне теләгәннәреннән аерган, бик күп кешене үз муенына пычак салырга, газиз җаныннан аерылырга мәҗбүр иткән.

Сәясәт вә сугыш мәйданында, дөнья базарында үзен бик көчле күрүче Гуҗ[1] кебек кешеләр дә көлүдән курыкмыйлар түгел. Корал вә мал куәте илә көлкене дә каршы китерми торган мөстәбидләр *(тираннар)* һәм, инсафга *(гаделлеккә)* килгән заманнарында, тарихта яман исемнәре калудан куркып тыныч йокыларын җуйганнар.

Озын сүзгә ни хаҗәт? «Көләрләр»нең куәтен белер өчен һәркем үз хәятыннан берничә шундый вакыйганы искә төшерергә, яисә курыкмас җиһангирларның тарихларыннан берәр мөнасиб *(тиешле)* сәхифәне актарып карарга гына кирәк.

* * *

Матбугат галәмендә тәэсирен иҗра итә *(гамәлгә ашыра)* башлаган заманнан башлап бу көнгә һаман кулында мәсхәрә вә көлкене корал итеп тотмыштыр. Матбугат үз тарафдарларының дошманнарыны шуның илә чыбыркылый, вә шуның илә дә галәбәгә иҗтиһад итәдер *(җиңәргә тырыша).* Һәр дәүләтнең дошманны кыра торган (вә һәлак итә торган) кораллары булган кеби, дошманны олуг дәүләтләрнең йиденчесе[1] хисапланган матбугатның мәһлүк коралы да матбугат кулында, көлүнең куәте – мәсхәрә итү вә көлүдер. Тәзагыфы һәндәси *(геометрик прогрессия)* кагыйдәсенчә арта бара. Ягъни мәсәлән: бер кеше көлгәндә бер тамыр мигә тисә, йөз кеше көлгәндә өч йөз алтмыш тамыр мигә йитәдер.

Моны аңлар өчен татып карарга шаяд ихтыяҗ юктыр. Һәммә кораллар шикелле моны да истигъмаль итә белү *(куллана белү),* истифадә ичүн *(файдаланыр өчен)* беренче шарттыр.

Бинаән галәйһи *(шуңа күрә)* беренче номер «Яшен» дә бу көлүнең мөкәммәлияте *(тулылыгы)* вә кемгә каршы истигъмаль ителгәне тугрысында берәр сүз язып, мәкаләне тәмам итәргә ярыйдыр.

16 битлек беренче номерның 8 бите рәсемнәр илә вә калганы көлке мәкаләләр, шигырьләр, телеграмнар, хәбәрләр, кечкенә фельетон вә латыйфәләр илә тулыдыр.

Рәсемнәр дигәндә, гомумән татар арасында рәсем һөнәренең шагыйгъ булмаганын *(таралмаганын)* вә моның сәбәпле фән вә тәрбиянең тиз таралуына бик уңайсызлык булганын язарга теләнсә дә, мәкалә бик озын булудан куркып, шулай гына узып китәм.

Рәсемнәр, бик шәп оста эшләнгән булмасалар да, максудны *(ниятне)* аңлатырлык чыкканнар. Шәһәр Думасында татар гласныйларының руслар эшләгәндә йоклап утырулары, «Шәрык» клубының

бикләнеп торып тычканнар оясы гына булуы, татар хатыннарының беләзек кайгысы, ысулы кадимчеләрнең мөселманнарны кяфер ясарга тырышулары, мулланың мужик йилкәсендә утыруы, Казан сәүдәгәренең яшерен фатирдан тоткан хатынын куып йибәрүе, милләтчелек оясыннан чыгып капитал ауларга керешкән кош – һәммәсе кызык чыкканнар, шигырьләре һәркайсы көлке журналы өчен бик гүзәл «мөһим телеграмнар» дигәне йибәрүчеләрнең фикерен тәмам күрсәтәләр.

«Кечкенә фельетон» хәзерге татар тәрәккыйпәрвәрләренең *(алгарыш тарафдарларының)* төрле шивә *(диалект)* вә төрле фикердә улулары илә бәрабәр бер-берсен аңлашырга маташып мөзакәрә итешүләрен *(фикер алышуларын)* күрсәтәдер. Журналның беренче номерасына караганда, «Яшен»нең ташы һәм уты искелек тарафдарларына атылып, тәрәккыйпәрвәрләргә яктысы гына төшеп китәргә охшыйдыр.

Г. Камал әфәнде китапларында вә гәзитәләрдә уңлы-суңлы төрле шәйләр күрсәтдекеннән «Яшен»нең дә төрле якка сугылуын көтәргә мөмкиндер (тәссефемезгә каршы – *кызганычка каршы*). Казан матбугатының бер кимчелеге бетеп, көлке журналы һәм чыга башлавына куанып, Тукай әфәнденең «Яшәсен ул, яшәсен!» дия догасын тәкрар итәм *(кабатлыйм)*.

*Сәгъди*

«Әлислах», 1908, 14 август (№ 41)

**Искәрмәләр**

[1] Гуҗ [бине Гоньк] – мөселман риваятьләрендә: Ахырзаманда Җир өстенә чыгып барлык азыкны ашап, суларны эчеп бетерергә тиешле, кеше кыяфәтендәге зур җан иясе *(Г. Ханнанова искәрмәсе).*

[2] XX гасыр башында «бөек дәүләт»ләрдән алты дәүләт исәпләнгән: Бөекбритания, Франция, Россия, Алмания, Австро-Венгрия, Италия. Мәкалә авторы матбугатның әһәмиятен һәм көчен шул дәүләтләр дәрәҗәсенә күтәреп, аны олуг дәүләтләрнең җиденчесе дип атый *(Г. Ханнанова искәрмәсе).*

*Текстны басмага әзерләүче, кереш сүз һәм искәрмәләр авторы*
***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Т.Ш. Гыйлаҗев***

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РУХИ ҺӘМ МӘДӘНИ ЯҢАРЫШЫНДА Ф. ӘМИРХАН

В статье изучается многогранное творчество одного из основоположников новой татарской литературы Фатиха Амирхана. Ф. Амирхан сыграл большую роль в развитии национального словесного искусства. В работе определяется творческое кредо и особенности художественного мышления писателя. Рассматриваются его взгляды на преобразования в татарском обществе. Выявляются основные характеристики его литературной деятельности, публицистики и литературной критики.

**Ключевые слова**: новая литература, литературные взаимосвязи, литературные направления, модернизм, психологизм, литературная критика, публицистика.

The article examines the multifaceted creativity of the founder of the new Tatar literature Fatikh Amirkhan. F. Amirkhan played an important role in the development of national verbal art. The work defines the creative credo and features of the writer's artistic thinking. His views on transformations in the Tatar society are reviewed. The main characteristics of his literary activity, journalism and literary criticism are revealed.

**Keywords:** new literature, literary relationships, literary trends, modernism, psychologism, literary criticism, journalism.

Фатих Әмирхан XX гасырның беренче чирегендә татар халкының иҗтимагый-рухи яңарышында һәм мәдәни күтәрелешендә зур роль уйнаган көчле рухлы һәм милләтпәрвәр татар зыялылары буынының бер вәкиле булып тора. «Фатих Әмирхан – татар әдәбияты тарихында гына түгел, бөтен татар иҗтимагый тарихында иң күренекле бер урын тоткан, вакыты буенча кечкенә, ләкин әһәмияте буенча чиксез зур булган бер буынның үзәгендә торган кеше» [Вәлиди, 2008, б. 182], – дип яза Җ. Вәлиди. Нәсел-нәсәбе укымышлы руханилар булган ата-бабадан бирелгән сәләт, акыл һәм гыйлем культы хөкем сөргән гаилә, әдәби-мәдәни мохит йогынтысында ул үз чорының киңкырлы шәхесе булып формалаша: дөнья әдәбияты хәзинәсен бер-берсен кабатламаган күңел җимешләре белән баеткан татар әдәбиятының классик язучысы, теоретик әзерлекле тәнкыйтьче, татар иҗтимагый фикерен үстерүче ялкынлы публицист, журналист, әдәбият тарихына һәм аны укыту методикасына караган хезмәтләр авторы һәм җәмәгать эшлеклесе.

Төрек, гарәп, рус телләрен, Гареб һәм Шәрык философларының тәгълиматларын өйрәнгән киң карашлы, тирән белемле Ф. Әмирхан, төрле тармакларда эшләү мөмкинлегенә ия булса да, «бездә гомумгә хезмәт итү, гомумгә файда китерүдән ләззәтләнерлек кешеләр

аз табылуны» [Әмирхан, 3 т., 1989, б. 186] истә тотып, иң беренче нәүбәттә, аның сүз сәнгатен һәм публицистикасын үстерү аша үзен гомумхалыкка, милләткә хезмәт итүгә багышлый. Гомеренең соңгы көненә кадәр шушы кыйбладан тайпылмыйча, үз хезмәтеннән тәм табып, ләззәт алып яши.

Фатих Әмирхан идея эчтәлеге һәм сәнгати яктан Яңарыш (Ренессанс) кичергән татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә. Рухи мирасында милләт темасы кызыл җеп булып сузылган язучы әдәби эшчәнлеген татар тормышындагы искелекне, артталыкны, феодаль торгынлыкны тәнкыйтьләүдән башлый. Иҗатының башлангыч чорында ул бу мәсьәләләрне кече эпик жанрларда яктырта. Язучының XX гасыр башында иске татар тормышын асылыннын үзгәртеп кору проблемасына үзгә фикердә булуын һәм сүз сәнгатенә сәләтле каләм килүен хәбәр иткән «Гарәфә кич төшемдә» хыялый хикәясе 1907 елда иҗат ителә һәм анда язучы каләменең төп сыйфатлары күзәтелә. Әсәрдәге вакыйгалар хикәяләүче тарафыннан бәян ителә. Әдип традицион төш алымына мөрәҗәгать итеп, хыял ярдәмендә мәдәни, гыйльми, әдәби, фәнни-техник алгарышка ирешкән татар җәмгыятен сурәтли. Кичен татар музыкасы, лирик җырлары, милли телдә башкарылган арияләр, романслар белән әсәрләнеп, артистлар осталыгына сокланып уен тамаша кылган герой кинәт колак төбендә яңгыраган «Гает вакыты җитте, тор!» дигән тавышка уянып китә. Хикәянең бу өлешендә иске татар тормышын реаль детальләрдә, күренешләрдә тасвирлана. Ф. Әмирхан мәдәниләшкән, европалашкан татар җәмгыятенә ямьсез, шыксыз милли чынбарлыкны каршы куя. Сурәтләнгәннәргә үз мөнәсәбәтен һәм бәясен бирү максатыннан, караңгылык-яктылык, төш-өн, ямьсезлек-матурлык, реаль-идеаль, кайгы-шатлык, бәхет-бәхетсезлек катламнар каршылыгына мөрәҗәгать итә. Укымышлылык, фәнни алгарыш, рухи югарылык һәм европалашу татар тормышын асылыннан үзгәртеп коруның төп шартлары төсендә тәкъдим ителә.

Татар тормышындагы вакыйгаларны һәм күренешләрне иңләп алып, аларны тасвирлауда эпиклыкка ирешү өчен, Ф. Әмирхан күләмле жанрларга күчә. Язучы иҗатында гына түгел, ә татар әдәбиятында да иң көчле сатирик әсәрләрнең берсе булган «Фәтхулла хәзрәт» (1909–1910) повесте 1909 елда кисәкләп басыла башлый һәм аның соңгы дүртенче өлеше 1910 елда Казанда дөнья күрә. Анда милли чынбарлыктагы феодализм калдыклары, наданлык, артталык, татар җәмгыятенең рухи-мәдәни яңарышын тоткарлаучы көчләр фаш ителә. Иске карашлы, фанатик, кадим, бозык, әхлаксыз голяма катлавының бер вәкиле Фәтхулла хәзрәтнең сатирик һәм комик тибы тудырыла. Әсәр Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый-публицистик повесте тәэсирендә иҗат ителгән. Ф. Әмирхан да бу әсәрен, Г. Исхакый кебек шәхси мәнфәгатьләр өчен руханилар катлавына дошманлыганнан түгел, ә «хәзер тәрәккый өчен иң кирәкле эш – үземезне шул голяманың тәхте әсарәтеннән (тәхет коллыгыннан)

коткарып, һәр хәрәкәтемездә хөр булу» [Исхакый, 1998, 1 т., б. 155] максаты белән иҗат итә.

Повесть, бер яктан, замандашлары иҗаты белән бәйләнсә, икенчедән, бу әсәрдә язучының хәзрәт холкын, комедиячел халәтен тулыландыра торган башка әсәрләре белән аваздаш элементлар да бар. Мәсәлән, үзен юындырып, аңа киң итеп тегелгән тройка тәкъдим иткән егеткә, гает көнендә «чалма-чапан киеп, гатырша мае сөртергә тиеш икәнене сөйләве» әсәрне авторның «Гарәфә кич төшемдә» (1907), «Бәйрәмнәр» (1909) хикәяләре белән бәйли. Шул рәвешле әсәр ахырына иске карашлы, фанатик, татар тормышының яңарышын тоткарлаган дин әһеленең гомумиләштерелгән тибының тулы портреты формалаша.

«Фәтхулла хәзрәт» повестенда мәдәни һәм икътисади алгарышка ирешкән татар җәмгыятендә диннең урынын һәм иҗтимагый ролен күрсәтү уңаеннан, Ф. Әмирханның дини күзаллаулары, ислам диненә карашы да чагыла. Ул аны кешене рухи сафландыру, рухи камиллеккә ирештерүче көч төсендә карый һәм диннең матди әйбер түгел, ә җан белән бәйләнешле рухани күренеш булуын әйтә [Әмирхан, 1985, 2 т., б. 39].

Ф. Әмирханның «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912) хикәясендә иске карашлы, кадимче дин әһеленең психологик портреты тудырыла. «Сатира угы астында көлкегә калдырылып, гыйбрәт ителергә тиешле сыйфатлар, барыннан да элек, әдәпкә һәм әхлакка чакырырга яраткан хәзрәтләрнең үзләрендә тупланган булуын ачып бирә язучы» [Хәсәнов, 1984, б. 465]. Хикәя, әдипнең башка әсәрләреннән аермалы буларак, үткен диалогларның, градация һәм ирония алымнарының отышлы кулланылышы белән аерылып тора.

Ф. Әмирхан да замандашлары Г. Исхакый, С. Рәмиев, Г. Тукай, М. Гафури һәм башкалар кебек хатын-кыз темасына зур урын бирә. Феминистик мотивлар язучының әдәби һәм публицистик эшчәнлегендә яктыртыла. Язучының рухи мирасында күтәрелгән иҗтимагый-социаль, милли, фәлсәфи проблемалар хатын-кыз мәсьәләләре белән үрелеп тасвирланган «Яшьләр» (1909), «Тигезсезләр» (1914), «Урталыкта» (1912) романы һәм драмалары белән беррәттән, тулысынча бу теманы төрле сәнгати формаларда һәм алымнарда чагылдыруга багышланган «Татар кызы» (1909), «Хәят» (1911), «Кадерле минутлар» (1912) кебек берсеннән-берсе гүзәлрәк, нәфисрәк әсәрләр дә бар.

Ф. Әмирханның әдәби әсәрләрендәге хатын-кызның рухи һәм физик портретына туры килмәгән, эчке һәм тышкы гүзәллек гармониясенннән мәхрүм булып, автор идеалыннан ераклашкан татар хатын-кызлары тибы белән укучы «Рәхәт көн» (1910) хикәясендә таныша. Автор балигълык яшенә кереп бара торган Гайниҗамал һәм аның әбисе Мөхип карчыкны тасвирлый. Язучы, башка каләм ияләреннән аермалы буларак, хатын-кыз проблемасына үзгә позициядән якын килә: ул тышкы кыяфәтләренә битараф, мәдәниләшүгә омтылмаган, җәмәгать урыннарында үзеңне тоту, кеше белән аралашу кебек әхлак

кагыйдәләренә ия булмаган белемсез, тәрбиясез хатын-кызларны гаепли. Милли чынбарлыкта үзеңә лаеклы урын табуда, бәхеткә ирешүдә эчке һәм тышкы культурага ия булуның әһәмиятен ассызыклый. Әсәр идея эчтәлеге белән Г. Гобәйдуллинның «Яшьләр кичәсе» (1912), Г. Рәхимнең «Галия» (1914), Г. Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) хикәяләренә аваздаш булып, «Рәхәт көн» хикәясе аркылы мондый тип хатын-кызлар «милләт аналары» дигән зур җаваплы вазифаны башкара алмый, дигән фикер ныгытыла.

Ф. Әмирхан рухи мирасының таҗы булган «Хәят» повестеның беренче кисәге татар җәмәгатьчелеге тарафыннан «әдәбият мәйданына чыккан «яңа бер хәдисә (вакыйга)» (Г. Ибраһимов) буларак каршы алына. Аның икенче кисәгенең тиз арада язылып, матбугатта басылып чыгачагы турында хәбәр ителсә дә, ул чыкмыйча кала. Икенче кисәкнең язмышы мәсьәләсе Ф. Әмирхан тормышын һәм иҗат биографиясен өйрәнгән галимнәрдә зур кызыксыну уята. Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге галимнәре тарафыннан А. Шамов, И. Нуруллин, М. Мәһдиев тикшеренүләре дәвам иттерелеп, повестьның икенче өлешенә караган язмаларның Татарстан Республикасы Милли музее фонларында саклануы ачыклана. «Повестьның беренче өлеше, нәкъ акт кәгазендә искәртелгәнчә, ундүрт дәфтәрдән, 136 биттән гыйбарәт. Ә икенче өлеше исә, алты дәфтәргә теркәлгән, тәмамланмаган. Димәк, акт-чыганакта билгеләнгән ун дәфтәрдән алтысының язмышы ачыкланды дияргә мөмкин. Повестьның дәвамы язылган тагын дүрт дәфтәр дә киләчәктә табылмас дип әйтеп булмый» [Заһидуллина, Гомәров, 2016, б. 6], – дип язалар Д. Заһидуллина, И. Гомәров. «Хәят» әсәренең яңа басмасы, язучының үз кулы белән язылган егерме дәфтәрдәге оригинал текстлардан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп, татар классик язучысы Фатих Әмирханның тууына 130 тулу юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә нәшер ителде [Әмирхан, 2016].

Повестьның беренче кисәгендә Хәятның балигълык чорыннан алып кияүгә чыгу турында карарга килгәнчегә кадәрге ата-ана йортындагы идиллик тормышы күрсәтелә. Тышкы каршылык белән тыгыз бәйләнгән эчке акыл һәм хис каршылыгы әсәрнең үзәк конфликтын барлыкка китерә. Ул, үз нәүбәтендә, һәркайсы мөстәкыйльлеккә ия булып, әсәрнең төп идеясен ныгытуга хезмәт иткән рус егете Михаил, Мәскәү университеты студенты Гали Арсланов һәм аңа яучы җибәргән Салих Фатихов белән бәйле өч ярдәмче сюжет сызыкларына таркала. Төп сюжет сызыгында «хис һәм акыл үзгәреше бәхеткә, иреккә, үзең теләгәнчә яшәргә омтылышның – моның мөмкин түгеллеген аңлау, ризалашу, буйсыну белән алмашыну арасында тирбәлә» [Ибраһимов, 2018, б. 79]. Эчке халәт, эмоцияләр, билгесез сагышлар («эч пошу») аша гәүдәләнгән күңел кичерешләренең үстерелеше, героиня кулына Салих Фатиховның сурәте килеп кергәнгә кадәр дәвам итеп, үзенең кульминацион ноктасына җитә. Ата-ана теләгенә каршы

килмичә, «холкын, табигатен белмәгән, күрмәгән һәм танымаган, ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән» кешегә кияүгә чыгарга карар кылу белән эчке конфликт хәл ителә.

Тышкы каршылыклар татар тормышы, ул аралашкан даирә, тирәлек белән билгеләнә. Хәят тәрбияләнгән гаиләви тирәлек, башлангыч белем алу формалары XX гасыр башында башка татар кызлары кичергән шартлардан аерылмый, ул гомумиләштерелеп бирелә. Остазы тарафыннан Хәят күңеленә салынгын дини күзаллаулар, беркетелгән кагыйдәләр этисе Борһан абзый һәм энисе Газизә абыстайның яшәеше, гаиләдә хөкем иткән тәртипләр белән ныгытыла. Гаилә башлыгы күбрәк рус сәүдәгәрләре белән эш иткәнгә, аның йорты да рус урамында урнашу сәбәпле, Хәят бала вакытларыннан ук рус балалары һәм Лиза белән уйнап үсә һәм яшьтән бик яхшы итеп русча сөйләшергә өйрәнә. Моннан тыш Борһан абзый гаскәри Мясниковның аерым заказларын үтәгәнгә күрә, бу ике гаилә үзара аралашып яши, ә Хәят ике төрле тәрбия, мәдәният аерымлыгын күреп үсә. Билгеле ки, бу социаль һәм мәдәни шартлар эзсез узмый. Аннан соң Ф. Әмирхан XX гасыр башында формалашкан либераль буржуазия вәкиле Рәхимовлар гаиләсе тормышының Хәяткә тәэсирен күрсәтә.

«Хәят» повестенда эчке һәм тышкы каршылыкларны барлыкка китергән проблемалар, бер яктан, гомумкешелек характерында булсалар, икенче яктан, алар иҗтимагый-милли җирлекле. Бу аспект XX гасыр башында татар хатын-кызының иҗтимагый урынына барып тоташа. Ул төп герой Хәят, аның эти-энисе Борһан абзый һәм Газизә абыстай, Михаил, Гали Арсланов, Рәхимә Рәхимова һәм аның кызлары Рөкыя, Әминә, шулай ук икенче кисәктәге Гаделбану белән мөнәсәбәтләрдә ачыла. Европача яшәү үрнәгенә омтылган Ф. Әмирхан Хәят образы аша татар җәмгыятендә хатын-кыз хәлен типиклаштырып бирә һәм яратмыйча, ата-ана хакына үзең яратмаган егеткә кияүгә чыгуның күпчелек очракта хатын-кызны бәхетле итә алмавы хакында нәтиҗә ясый.

Повестьның табылган икенче өлешендә Хәятның туй көннәре, Идел буена сәяхәт һәм Салих Фатиховлар йортындагы тормышы сурәтләнә. Эзләнүләргә караганда, повестьның бу өлеше өстендә эш аның беренче кисәге басылып ятканда дәвам иткән. Ул романтик рухта калып, сәнгатьчә фикерләү тибы, идея-эстетик һәм тел-стиль үзенчәлекләре белән беренчесеннән аерылмый. Биредә дә акыл-хис каршылыгы, ягъни хыял белән чынбарлык бәрелеше вакыйгалар үстерелешен дәвам итә.

Тышкы каршылыкларны барлыкка китергән тормыш, тирәлек тә икенче кисәктә үзгә: атасыннан зур мирас белән калган Салих Фатихов йорты, ире, кайнана. Хәят үз хыялында «кәләпүшендән башка бөтен киеме иң соң мода белән Яуропача тегелгән» Салихны европалашкан, аның йортын «Рәхимовларныкына охшашлы йорт» итеп күзаллый. Ә чынбарлыкта исә, Хәят фикеренчә, Салих та «бигүк яуропалашкан кеше» булып чыкмый. Ул «тышкы тормышны яуропача

итәргә яратса да», Гаделбану абыстай «чын мөселманчылыгы» белән бу мәсьәләдә Салихка зур уңайсызлык тудыра, шуның аркасында ана белән угыл арасында каршылыклар да килеп чыга.

Ф. Әмирханның «Хәят» повесте фикри-мәгънәви эчтәлегенең тирәнлеге, гомумкешелек кыйммәтеннән тыш, аның сәнгатьчә эшләнеше бик югары, автор Хәятны гына түгел, һәр героен рухи һәм физик матурлык гармониясендә күрсәтүгә ирешкән. Әсәрнең сәнгати катламында шәркый традицияләргә нигезләнеп үсеп, XX гасыр башында күтәрелеш кичергән татар әдәбияты һәм гареб-рус сүз сәнгатьләре казанышлары очраша. Автор портрет остасы буларак танылып, бу деталь ярдәмендә геройларның характерын, психологик кичерешләрен һәм халәтен чагылдыра. Әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр сибелгән романтик буяулардан, детальләрдән, троплардан төп герой Хәятның илаһи портреты тудырыла, аеруча күзләр, алсу яңаклар, көлтә кебек чәчләр кебек детальләр уйнатыла. Кызның гүзәллеге *гөл, роза / былбыл, сандугач* парлы символлары һәм автор әсәрдә отышлы файдаланган *кояш, чәчәкләр, таң* табигать тасвирлары, пейзаж күренешләре ярдәмендә көчәйтелә. Шул ук вакытта алар герой, аның халәтенә бәя бирү функциясен дә үти. Хәят яшьлегенең иң матур вакыты табигатьнең иң гүзәл мизгеле яз фасылы, аның да май ае көннәренә янәшә куела. Резеда чәчәкләре, роза гөле матурлык символы булып килеп, кызның фәрештәви гүзәллегенә ишарә ясый. Ә инде җанына тынычлану, рәхәтлек, «бөтен җан, бөтен йөрәк белән сизелерлек алмашыну бирмәгән» ире Салих йортындагы тормышы кыш вакытына туры килә.

Ф. Әмирхан кешенең каршылыклы күңел дөньясын, кичерешләр тирбәнүен, нюансларын тасвирлауда оста психолог буларак танылa. Төп героиня Хәятның күңелендәге акыл һәм хис, чынбарлык белән хыял, яшь кызның шәхси азатлыкка, бәхеткә омтылышлары белән татар тормышы кануннары, күнегелгән тәртипләре бәрелешә. Автор Хәят тормышының иң киеренке, борчулы мизгелләренә нисбәтле психологизмның төрле алымнарын: психологик анализ, аң агышы, эчке монолог, читтән торып ясалган анализга мөрәҗәгать итә.

Зур талант белән язылган әдәби әсәрләрне бер юнәлеш, ысул кысаларында гына тикшерү мөмкин түгеллеге табигый хәл, чөнки болай якын килү аларның сәнгати матурлыгын, отышларын шәрехләү мөмкинлекләрен чикли. Бу ноктадан «Хәят» повесте иҗат ысулы мәсьәләсендәге карашларның төрлелеге белән аерылып тора. Г. Ибраһимов әсәрнең тулы канлы реалистик повесть булуына икеләнү белдереп, «Хәят тибының табигыйлеге хакында зур шөбһә бар» [Ибраһимов, 2018, б. 80], – дип яза. Совет чорында ул романтизм элементлары булган тәнкыйди реализм (И. Нуруллин, М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин), реализм һәм романтизм синтезы (Г. Халит) ысулы үрнәге буларак тикшерелә. Татар әдәбиятын тикшерү һәм бәяләүнең яңартылган методологиясе нигезендә ул «идеяләр романтизмы» (Й. Нигъмәтуллина), саф романтизм (Р. Ганиева, Д. Заһидуллина)

агымы поэтикасы кысаларында тикшерелә; әсәр стиленең модернистик агымнардан импрессионизм, экспрессионизм, экзистенциализм билгеләре белән дә баетылуы күрсәтелә.

Ф. Әмирханның Гареб һәм Шәрык традицияләренең синтезында иҗат ителгән «Кадерле минутлар» (1912) романтик хикәясе мәхәббәт темасының илаһи сурәтләнеше, гашыйклар хис-кичерешләре гәүдәләнешенең тирәнлеге һәм әдәби теленең гаҗәеп матурлыгы белән аерым урында тора. Әсәрдә саф, керсез һәм нурани мәхәббәт хисе акыл белән тереклек итүгә, тормышка каршы куела. Рәшадның кадерле минутлары гыйшык хисләре белән бәйле булып, ул өч мәхәббәт тарихын бәян итә. Һәр мәхәббәт героинясының портреты хосусый үзенчәлеккә ия булса да, фәрештәви гүзәллеккә ия кызларның матурлыгы, ялкынланып, очкынланып, нур эчендә йөзә торган күзләр, алсу яңаклар, бөдрәләнеп, тузгып торган көлтә кебек чәчләр кебек традицион образлар аша ассызыклана, ләкин алар хикәядә яңа мәгънәви төсмерләр белән баетылган. «Кадерле минутлар» хикәясенең идея эчтәлеге Г. Исхакыйның «Очрашу яки Гөлгыйзар», Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» әсәрләре, С. Рәмиев, Ш. Бабичларның күңел-интим лирика үрнәкләре белән аваздаш.

Яшьлек гомере Казан шәһәрендә үтү сәбәпле, Ф. Әмирхан татар шәкертләре, студентлары, гимназисткалары белән тыгыз аралаша, шуңа язган әсәрләрендә укучылар дөньясына күп урын бирелә. «Көнчыгышның мәдәни традицияләреннән читләшмичә, Европа-көнбатыш культурасына йөзне юнәлдергән прогрессив зыялының идеаль моделе» [Урманче, 2005, б. 52] буларак, Ф. Әмирхан милли чынбарлыкны асылыннан үзгәртеп коруда мәдәниләшкән һәм европалашкан укымышлы һәм югары әхлаклы зыялы татар яшьләренә зур өмет баглый. «Сез халык балалары, халык арасыннан чыккан яңа кешеләр, – дигән иде ул безгә дип яза А. Шамов. – Халыктан беркайчан да аерылмагыз, аңа хезмәт итегез. Аның туксан процентын тәшкил иткән хезмәт ияләренең мәдәни, икътисади һәм сәяси күтәрелеше – менә сезнең барыгыз өчен дә уртак кыйбла!» [Шамов, 2005, б. 153]. Шул сәбәпле зыялы татар яшьләре темасы Ф. Әмирхан әдәби эшчәнлеген үтәли чыккан темаларның берсе булып тора. Әлеге темага язучының «Яшьләр» (1909), «Урталыкта» (1912), «Тигезсезләр» (1914) «Танымаганлыктан таныштык» (1909) әсәрләре багышланган. Боларда укучылар кызыклы татар яшьләре образлар системасы белән таныша. Әдип югарыда искә алынган мәкаләсендә К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасына таянып, ул чорда зыялылар катламында яшәүнең рухи-әхлакый һәм фәлсәфи мәгънәсен төрлечә аңлаган типлар булуын искәртә.

1910 елларда әдәбият мәйданында тарихи темага язылган әдәби әсәрләр барлыкка килә. Бу теманың көчәюе, бердән, милли үзаң күтәрелеп, татар халкының шанлы һәм фаҗигале үткәне, милли дәүләтчелек тарихы белән кызыксыну белән бәйле булса, икенчедән, сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре тәмам формалашып

бетеп, модернистик агымнарның тасвирый алымнары һәм чаралары үзләштерелү процессына да барып тоташа. Ф. Әмирханның реаль һәм хыялый вакыйгалар иҗтимагый-милли мәсьәләләр белән үрелеп тасвирланган «Сөембикә», «Картада оттырылган Зөлхәбирә» исемле хикәяләре шушы тематикага карый.

«Ай өстендәге Зөһрә кыз» (1912) хикәясендә сюжетына XX гасыр башында шактый санда әсәрләр язылган Зөһрә кыз турындагы легенда файдаланыла. Ф. Әмирхан хикәясенең башлам һәм бетем өлеше үзенчәлекле. Шундый түгәрәк, шундый бөтен, шундый тулы һәм якты айда «әллә ниди бер моң, бер уйчанлык, бер кайгы барлыгы» әйтелә. Язучы ай моңының, кайгысының иҗтимагый-милли җирлекле сәбәбен билгеләгәннән соң, мифологик катламны – легенданы сөйләүгә күчә. Дини мифология белән үрелгән романтик рухлы «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәясендә автор милләт балаларын кешеләрне рәнҗетмәскә, ә игелекле, бер-береңә шәфкатьле булып яшәргә чакыра. Игелекле гамәлләрне кылган адәмнәргә Аллаһының рәхиме киң булуы турында фәлсәфи фикер үткәрелә.

1912 елда язучының морзалар тормышын фәлсәфи һәм эстетик яссылыкта тасвирлаган «Бер хәрабәдә» хикәясе дөнья күрә. «Милли сәнгатьтә өр-яңа яңгыраш алган» (Р. Ганиева) «Бер хәрабәдә» хикәясе реаль тормышның бер күренешен яисә кеше характерының бер сыйфатын тасвирламый, ә романтик һәм лирик геройның фәлсәфи яссылыктагы сызланулы кичерешен сурәтләү объекты итеп ала. Хикәяләүче герой еллар үткәч, Сөләйман морза утарына килә. Ала-кола тышлы, йөзне чыткан кебек караңгыланып торган, тәрәзә пыялалары кырылган, кәрнизләре, почмаклары ишелгән, җимерелеп беткән зур ике катлы таш пулатны күргәч, ул икеләнеп кала. Шушы күренештән соң ук Ф. Әмирхан капма-каршы кую композицион алымы ярдәмендә герой күңелендәге хисләр өермәсен сурәтли башлый. Әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр хәзерге һәм үткән (үткән һәм хәзерге) катламнар бәрелешендә Сөләйман морза йортындагы тормыш тергезелә.

Лирик чигенешләрдә, хатирәләрдә тергезелгән элекке бакча күренеше, шаулап-гөрләп торган тормыш, мәхәббәт мизгеле хикәяләүченең күңелен сызландыра. Ул бу коточыргыч бакчадан, коточкыч зәһәр сүзле карчыктан котылырга теләп, ишегалдыннан чыгып китә. Карчык йөткерена-йөткерена аның артыннан капканы бикләп кала. Капка хронотобы шулай ук билгеле бер вазифа башкара. Ул, әйтерсең, реаль тормышта түгел, ә ирреаль дөньяда гына була ала торган күренешләрне, халәтләрне укучы күзеннән яшерә, югалта. Морза утарының хәзерге хәле, бөтен бер гаиләнең аяныч язмышы, таш пулат эчендәге ямьсез күренешләр хикәя өстендәге сер томанын, билгесезлекне тагын да көчәйтеп киләләр. Әсәр артына әйләнеп карарга да курыккан хикәяләүченең кешегә киләчәккә өметләр уятып, бәхет вәгъдә итеп, әүвәл алдаган, ә аннан соң мыскыллаган тормышка ләгънәт укуы белән тәмамлана. Хикәянең фәлсәфи катламында Яшьлек, Матурлык,

Бәхет, Мәхәббәтнең вакытлы, кеше гомеренең чикләнгәнлеге хакында фикер үткәрелә. Һәр кешене гомеренең бер экзистенциаль чигендә авыру, хасталык, ялгызлык, өметсезлек, картлык, ямьсезлек сагалый, көтә дигән идея дә сәнгати чаралар ярдәмендә тудырылган тормыш моделендә ныгытыла.

«Бер хәрабәдә» хикәясенең поэтикасы бик бай. Ул әдип иҗатында төрле иҗат методларының, модернистик агымнарның үзара керешеп китүе белән билгеләнә: «Фатих Әмирхан – һәм реалист, һәм романтик язучы. Бер үк вакытта аның әсәрләрендә сәнгатьчә фикерләүнең бу ике төре төрледән-төрле модернистик алымнар белән дә мөнәсәбәткә керә» [Ганиева, 2016, б. 97–98], – дип яза Р. Ганиева. Мәсәлән, әсәрдә романтик хикәяләүченең «хәрабә» белән очрашудан соң туган авыр, сызланулы күңел кичерешләрен автор импрессионистларча моң һәм музыка катламы ярдәмендә бирә. Әсәрнең көчле позициягә ия булган исеме *хәрабә* символ-статусына күчеп, беренчедән, кеше гомеренең үлем экзистенциаль чигенә, икенчедән, тамырлары ерак гасырларга барып тоташып, татар халкының иҗтимагый һәм мәдәни тормышында эз калдырган морзалар социаль катлавының тарих арбасыннан төшеп калуына, өченчедән, мирза утарының җимерелеп юкка чыгуына ишарә ясый.

Ф. Әмирхан XX гасыр башында татар балалар журналистикасына һәм балалар әдәбиятына нигез сала. Бу вакытта Г. Тукай, Н. Думави, З. Ярмәки, Г. Рәхим, Ф. Агиев, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Әхмәдиев бу аудиториягә йөз тотып, язучыларның иң активларыннан саналалар. Алар арасында Ф. Әмирхан бала дөньясын нечкә тоемлап язуы һәм стиль үзенчәлекләре белән аерым урында тора, ул бу тармакта да оста психолог булып кала. Әдип бу жанр әсәрләрендә «милләтемезнең булачак әгъзалары – балаларны» милли рухта тәрбияләү, аларның эстетик зәвыгын үстерү, дөньяны таныту һәм белем, күнекмәләр формалаштыру максатын күздә тота.

Тематик яктан һәм сәнгати үзенчәлекләре белән-берсе белән тыгыз бәйләнгән «Ул үксез бала шул!» (1913), «Нәҗип» (1914), «Корбан» (1913). хикәяләрендә язучы балалар дөньясын, индивидуаль үзенчәлекләрен яхшы белгән оста психолог буларак чыгыш ясый. Беренче хикәядә Ф. Әмирхан көнчелек хисенең ямьсез нәтиҗәләргә китерүен күрсәтеп, балада кылган начар эш-гамәл өчен җаваплылык хисен тәрбияли. Икенчесендә, баланың үз гамәлләренә эчке кичерешләре, үзанализ алымы аша бирелгән бәя зурлар дөньясының карашлары, позициясе белән үрелеп, укучыда бер һөнәргә ия булу гына кешене файдалы, кирәкле, акыллы һәм батыр итә ала, дигән фикергә китерә. Ф. Әмирхан «Корбан» әсәрендә җанлы табигать белән кеше, аеруча бала арасындагы мөнәсәбәтне җылы, җанга үтеп керерлек итеп тасвирлый һәм шуның белән укучыда йорт хайваннарына сак караш, мәхәббәт тәрбияли. Бала күзаллавы аша корбан чалу йоласына, дин-шәригать кануннарына мөнәсәбәт белдерелә.

Ф. Әмирхан татар драматургиясен үстерүгә дә зур өлеш кертә. 1909 елда язылган «Яшьләр» драмасында татар тормышында башланган яңарыш хәрәкәте сурәтләнә. Ф. Әмирхан пьесаның төп темасына нисбәт итеп, аны әүвәл «Татар тормышының алмашыну көннәрендә» дип атаган. Әсәрдә милли яшәешне асылыннан үзгәртеп кору фикере «аталар» һәм «балалар» тартышы рәвешендә гәүдәләнә. Драманың үзәк конфликты әсәрнең беренче күренешләрендә үк бөреләнә башлый: гаиләдәге кычкырышларның, тавышларның балалар белән этиләр арасында түгел, ә «иске тормыш белән яңа тормыш арасында» булуы ассызыклана. Иске татар тормышына, күнегелгән тәртипләргә, татар зыялы яшьләренең эш-гамәлләренә мөнәсәбәттә ике төрле караш бәрелешә. Мәгърифәтчелек элементлары булган тәнкыйди реализм ысулы белән иҗат ителгән «Яшьләр» драмасы Ф. Әмирханның иҗтимагый, фәлсәфи һәм дөньяга карашларын, дини күзаллауларын туплаган әсәр буларак язучы мирасында аерым урында тора. Бу яктан татар тормышын асылыннан үзгәртеп кору юллары хакында бәхәс-фикерләрне туплаган икенче пәрдә аеруча кызыклы. Дөрес, андагы күренешләр пьесаның беренче һәм өченче пәрдәсендә барган вакыйгалар белән бәйләнмәгән, ул сюжет үстерелешен салмакландыра, әмма һәр әңгәмәнең үзәгендә йә Газиз, йә Йосыф булу, фикер алышуларның иске татар тормышын үзгәртү фикере белән төенләнеше икенче пәрдәнең дә драманың төп идеясе белән бәйләнешен ныгыта.

Социалист-революционерлар, социал-демократлар, мәгърифәтчелек, халыкчылык, социалистик идеаллар яклы татар зыялы яшьләре тарафыннан татар тормышын үзгәртүнең төрле юллары тәкъдим ителә: мәгърифәтче Гали хәзерге татар яшьләренең яңа татар тормышын төзергә һөнәри әзерлеге, акыл көче җитмәгәнлеген белдереп, «киләчәктә эшлисе кешеләр өчен почва (нигез) әзерләү» идеясен яклый. Әсәрдә автор тарафыннан якланган фикерләр чор иҗтимагый карашлары, әдәбиятта чагылган фикерләр белән аваздаш. Мәсәлән, Гали сүзләре күренекле прозаик һәм драматург Г. Исхакыйның «Тартышу» драмасындагы социалист Насыйр монологына аваздаш. Ул да татар тормышын яңарту өчен иске тормышның нигезен җимерү, ә аның өчен уку, гыйлем кирәклеге фикерен куәтли.

Фикер алышуларга Зәкәрия учитель кушылып китеп, халыкчылык хәрәкәтенә авыл халкының мөнәсәбәтен, милләт тормышын яңартуда бу юлның нәтиҗәсезлеген сөйли. Ф. Әмирхан татар милләтенең икътисади, иҗтимагый һәм мәдәни үсеше турында да уйлана. Социаль мәсьәләләр, иҗтимагый мөнәсәбәтләр хакында фикерләр, нигездә, Газиз авызыннан әйтелә. Язучы эре мануфактура, завод һәм фабрикаларның татар сәүдәгәрләре кулыннан мәдәниятле башка милләт вәкилләре кулына күчә баруына борчылу хисләрен белдерә. Кәләпүш сатып, читек-комган алыштырып кына хәзер зур икътисади үсешкә ирешү мөмкинлеген кире кага. Шәһәр кырыйларындагы татарлар тора торган урамнардагы эшсезлекне, җитештергән әйберләрнең бәһасезлеген шуның нәтиҗәсе итеп карый. Күренә ки, «Яшьләр»

драмасында милли чынбарлыкны яңарту кирәклеге идея, милли идеология рәвешендә яши.

Пьесада милли чынбарлыкны яңарту проблемасы хатын-кыз темасы белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Ул татар тормышының иске тәртипләре, гаиләдәге хокуксызлыгы, ирнең кешелексез мөнәсәбәте белән «җанлы курчак»ка әверелгән Фәхерниса язмышында һәм Зәйнәп белән бәйле күренешләрдә чагылыш таба. Өченче пәрдәдә милли чынбарлыкта татар хатын-кызларына караш, хатын-кыз азатлыгы, аның гаиләдәге хокукы, урыны, никах ирегe һ.б. мәсьәләләр калкуландырыла һәм ул «аталар» белән «балалар» каршылыгын тагын да көчәйтеп җибәрә. Ф. Әмирхан, татар тормышын асылыннан үзгәртми торып, хатын-кызларның «курчаклык» халәтенә, аларга «иске тормышның иң куәтле һөҗүмнәренә» чик куелу мөмкин түгеллеген раслый. «Яшьләр» әсәренең бу өлешендә Г. Исхакыйның ««Алдым-бирдем» драмасы белән фикри-мәгънәви бәйләнеш аеруча көчле.

Әдипнең татарларда туып килүче яңа социаль катлау – либераль буржуазия вәкилләре тормышын гәүдәләндергән реалистик эчтәлекле «Тигезсезләр» драмасы 1914 елда языла. Драматург әсәрдә татар милләтенең киләчәген, аның икътисади, иҗтимагый үсешен, мәдәни хәлен шушы катлау белән бәйләп карый. Сәүдә эшен яңача алып барган һәм аны Европа киңлегенә чыгарырга омтылган Гомәр белән татар сәүдә буржуазиясенең карт вәкиле Сафый Насыйбуллин арасында каршылык оеша, әмма бу психологик драмада «Яшьләр» драмасындагы «аталар» һәм «балалар» арасындагы тартыш салмакланган. Пьеса әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну белән кабул ителә. Вакытлы матбугат битләрендә Г. Кәрам, Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Искәндәров һ.б.лар тарафыннан әдәби бәхәс рухындагы тәнкыйть мәкаләләре языла. Әдәби бәхәс объекты булып милли чынбарлыкта җитешеп, драмада аерым бер җылылык, романтик купшылык белән сурәтләнгән матур, саф, керсез, зирәк, сәләтле, хәрәкәтчән Рөкыя образы тора. Әдәби әсәрнең образлар системасындагы геройга билгеле бер идея-эстетик вазифа йөкләнгән. Басынкы Сәлимә, язучы Сөләйман, Закир, Мәскәү университеты студенты Габдулла, Гөлчиһрә образлары пьесада авторның милли тарих, милли әдәбият, сәнгать, милли тел, мәдәният, дин турындагы уй-фикерләрен гәүдәләндерүгә хезмәт итәләр. Алар үз нәүбәтендә татар халкының киләчәк язмышы кебек мәсьәләгә килеп төенләнә. Бәхет, матурлык, яшьлек кебек мәңгелек мәсьәләләр исә аерым бер хисси-эмоциональ планда геройларның табигый хыяллары, теләкләре, омтылышлары яссылыгында тасвирлана. Тормыш, язмыш һәм мәхәббәттә тигезсезлек мәсьәләләрен автор илаһият биекләрендә хәл ителә торган кыйммәтләр буларак карый.

Ф. Әмирхан 1917 елгы Февраль һәм Октябрь инкыйлабларына зур өметләр баглый. Революция һәм гражданнар сугышы чоры әдәбиятында кешенең эчке кичерешләрен, күңел тирбәнешләрен тасвирлауга мөмкинлек биргән нәсер, шигъри проза жанры активлаша.

1910 елларда ук бу шәкелдә тәҗрибә туплаган Ф. Әмирханның 1920 елда «Чәчәкләр китерегез миңа» нәсере дөнья күрә. Вакытлы матбугат битләрендә әдипнең «кызыл гаскәргә бүләк итеп язылган һәм әсәрләре арасында иң матурларыннан» [Әмирхан, 1984, 1 т., б. 450] буларак бәяләнгән бу әсәренең жанры «шигырь-хикәя» дип тәкъдим ителә. Автор атама астына «Гражданнар сугышын галәбәле (җиңүле) тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайтып торган иптәшләргә багышлана» дип эпиграф куйса да, гади кешенең кичерешләрен, заман пафосына бирелмичә, традицион рухта тасвирлый. Нәсернең һәр абзацында кабатланып килгән чәчәкләр, күчерелмә мәгънә алып, символ-сурәт дәрәҗәсенә күчә. Шартлы-романтик сурәткә салынган мәгънә бер абзацтан икенче өлешкә күчә барып, матурлык, гүзәллек, яшьлек, беренче мәхәббәт-сөю, иҗат, бәхет мәгънәсен белдерәләр. Бу нәсер 1920 елларның беренче яртысы татар прозасында социаль, сыйнфый көрәш төп тема төсендә расланып, геройның эчке дөньясын чагылдыруга игътибар кимегәндә, татар әдәбияты үсешен схемалылыктан, берьяклылыктан саклап калуга үзеннән билгеле бер өлеш кертә.

Сизгер һәм талантлы язучы марксистик идеологиянең кешене кол хәленә төшерә торган табигатен тиз арада төшенә. Иҗтимагый-сәяси вазгыятькә, яңа социаль һәм мәдәни шартлар йогынтысында кеше аңында, психологиясендә һәм тормышында барлыкка килгән үзгәрешләргә, җәмгыятьтәге җитешсезлекләргә мөнәсәбәт белдерелгән «Март каһарманы» (1917), «Шәфигулла агай» (1924) кебек әсәрләре иҗат ителә. «Шәфигулла агай» тоташ сюжет сызыгына ия түгел, ә берсе артыннан берсе тезелеп килеп, гаилә башлыгының мәгънәсез эш-гамәлләрен сурәтләгән бүлекләрне Шәфигулла агайдан комик һәм сатирик көлү үзара бәйләп тора. Ф. Әмирхан яңа сәясәтнең, социалистик җәмгыятьнең һәм марксизм өйрәтүләренең һәм аларның кеше аңына көчләп кертелгән кануннарының асылын, дингә каршы башланган аяусыз көрәшне төшенеп эш итә. Моннан тыш элекке милли-рухи яшәешне хәзерге совет тормышына, ислам дине атрибутларын марксистик-ленинчыл идеология атрибутларына каршы куеп сурәтләү прнинцибы да повестьның композицион бөтенлеген ныгыта.

Мәсәлән, йокы алдыннан яки иртән Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп укыла торган дога урынына Шәфигулла агай иртәле-кичле балалары белән «Интернационал»ны җырлый һ.б. Моңа идеологик лексика, аллюзияләр, аятьләрдән, вәгазьләрдән алынган цитаталар, реминисценцияләр дә ишарә ясый. Ф. Әмирхан әсәрнең фикри тирәнлегенә ирешү, идея-проблематикасын үткенәйтү максатыннан телнең мөмкинлекләрен, сүзләрнең номинатив һәм күчерелмә мәгънәләрен, лексемалар сайланышын гаҗәеп дәрәҗәдә оста файдалана. Идеологик мәгънә салынган *дога – интернационал*, «*несознательный» – «сознательный»*, *Корбан гаете – 1 май бәйрәме*, *тәкбир – интернационал* һ.б.лар. «Шәфигулла агай»ның башыннан алып ахыры-

на кадәр төрле вакыйгаларда һәм күренешләрдә кабатланып килгән *кызыл* сүзе төрле функция башкара. Ф. Әмирхан әлеге чор иҗтимагый-сәяси вазгыятенең татар теленә тискәре йогынтысын, аның образлылыгын, аһәңлеген югалтуга китерүен күрсәтүгә ирешә алган. Шәфигулла агайның Мәскәүгә китүе уңаеннан газетада «Красный тел» дигән мәкалә урнаштырыла.

1920–1930 еллар татар әдәбиятында традицион архетиплар урынына сәяси юлбашчылар В.И. Ленин, М.И. Калинин, И.В. Сталин образлары барлыкка килә. Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай» әсәрендә В.И. Ленин исеме иҗтимагый гаделлек, бөеклек, эшче-крестьяннар атасы, бәхетле балачак, яңа тормыш өчен көрәшче мәгънәсендәге символ буларак кулланыла. Ф. Әмирхан бай сурәт-образлар, сәнгати алымнар ярдәмендә гасырлар буена тупланып киленгән милли традицияләрдән, яшәеш тәртипләреннән, дин-шәригать кануннарыннан, йолалардан баш тартып, социалистик идеологиягә табынуның ачы нәтиҗәсен тирәнрәк күрсәтүгә ирешә.

Әдәби җәмәгатьчелек арасында тирән белеме һәм фикер үткенлеге белән танылган абруйлы Ф. Әмирхан татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе булып тора. Ул киң карашлы, нечкә зәвыклы, эрудицияле тәнкыйтьчеләрдән санала. Аның бу төр эшчәнлегендә агымдагы тәнкыйди барышны бәяләү төп юнәлешне тәшкил итсә дә, тәнкыйтьнең предметы, жанрлар системасы, әсәрне бәяләү принциплары, алым-методлары, типлары һәм юнәлеш-агымнары кебек нәзари мәсьәләләр дә гыйльми күзаллана. Г. Сәгъди аның үткен каләмен, таләпчән, принципиаль тәнкыйтен күздә тотып, «карчыга күзле» беренче әдәби тәнкыйтьче» [Сәгъди, б. 15] дип атый.

Яңа татар әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләгән реалист Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, М. Гафури иҗатлары Ф. Әмирхан тәнкыйтенең бәяләү объекты булып тора. Аларның әдәби әсәрләре басылып чыгу уңаеннан дөнья күргән мәкаләләрендә, рецензияләрендә әдәбиятның иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте, сүз сәнгатенең милли характеры, реализм, халыкчанлык һәм әдәби осталык, театр тәнкыйте мәсьәләләре күтәрелә. Әдәбият һәм сәнгатьнең бурычын ул мәгърифәт тарату һәм әхлак төзәтү дип билгеләү белән бергә, иҗтимагый-милли мәсьәләләрне күтәрүдә, сәяси һәм икътисади стройның асылын сәнгатьчә ачып бирүдә билгели.

Әдәби тәнкыйтьнең юнәлешләрен һәм агымнарын аерып чыгарып, аларның үзенчәлекләрен билгеләү омтылышы 1920 еллар татар тәнкыйтендә үк башлана. Әдәби-тәнкыйди фикерне тарихи процесс буларак тикшерү юлында беренче сукмакны салган Г. Сәгъди, Ф. Әмирханның әдәби әсәрне бәяләү принципларына таянып, аны «реалист тәнкыйтьче» [Сәгъди, 1927, б. 16] дип атый. Ф. Әмирханның Г. Исхакый әсәрләренә язылган рецензияләрендә матур әдәбиятның реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру хасияте бары тик җанлы һәм тормышчан образлар, табигый типлар тудыру, детальләр дөреслеге ярдәмендә тормышка ашырыла, дигән фикер, кагыйдә

үзәккә куела. Мәсәлән, «Алдым-бирдем» рецензиясендә тәнкыйтьче пьесаның сюжеты нигезендә яткан төп каршылыкны – яңа тормыш белән иске тормыш арасындагы көрәшне билгели, милли чынбарлыктагы тартышны типлар аркылы анализлый. «Солдат» (1908), «Мөгаллим» (1914), «Зөләйха» (1917) рецензияләрендә дә Ф. Әмирхан реалистик тәнкыйть кануннары белән эш итә. «Гаяз» (1907) мәкаләсендә, иң беренче нәүбәттә, Г. Исхакый каләменең реалистик табигатен тотып ала [Әмирхан, 1989, б. 28]. Ул әдип әсәрләрендә гәүдәләнгән тормыш материалының иҗтимагый-социаль, милли азатлык мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнешенә һәрдаим үз игътибарын юнәлтеп бара. Ф. Әмирхан тәнкыйди язмасында фаҗига темасының иҗтимагый-милли әһәмиятенә басым ясый. Рецензия эчтәлеге, Ф. Әмирханның киң диапазонлы публицистикасы белән кушылып китеп, татар халкын милләт буларак саклап калуда ислам диненең ролен күрсәтә. Аерым фактлар, сыйфатлар белән конкретлаштырылмаса да, «Зөләйха» фаҗигасы сәнгатьчә эшләнеше, камиллеге ягыннан татар драма әсәрләреннән аерып куела.

Ф. Әмирханның әдәби тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Тукайның шигъри осталыгын, халыкчанлыгын һәм миллилеген, телүзенчәлекләрен ачып бирү, шәхесенең иҗтимагый кыйммәте кебек мәсьәләләр зур урын алып тора. Шагыйрь иҗатын чагыштырматарихи ысул белән әдәби-мәдәни багланышлар контекстында тикшерү юнәлешенең юл башында да Ф. Әмирхан тора. Тәнкыйтьче шагыйрьнең басылып чыккан һәрбер шигырь җыентыгына язылган бәяләмәләрендәге караш-хөкемнәре, аның шигъри дөньясын бәяләү принциплары һәм кагыйдәләре белән Тукайны өйрәнү фәненең (гыйльмиятенең) фәнни концепциясен эшләүгә зур өлеш кертә. Г. Тукай шигырьләренең телен этрафлы итеп анализлый, үзгәрешен күзәтә һәм шуның белән тел-өслүбне әсәр бәяләүнең мөһим үлчәменә әйләндерә. Ф. Әмирханның бу төр иҗатында Г. Тукай шигъриятен пропагандалау, рухи мирасын һәм шәхесен субъектив бәядән, нахак сүзләрдән саклау, әдәби абруй проблемасы кызыл җеп булып сузыла.

Ф. Әмирхан – үз чорының күренекле һәм үткен телле публицисты да. Ф. Әмирхан үз әдәби эшчәнлеген нәкъ шушы чорда мөстәкыйль үсеш сукмакларына чыккан публицистика һәм журналистика белән тыгыз үреп алып бара: «Безнең башка бик күп язучылар кебек Фатих та нәфис әдәбиятка гына бикләнеп калмады; ул моны гәзитчелек, җәмәгатьчелек белән бергә җыйды» [Вәлиди, 2008, б. 182]. Аның публицистик мирасы махсус тикшерү объекты булып тормаса да, язучының әдәби яисә тәнкыйди эшчәнлеген яктыртканда, публицистик язмаларына, алардагы тематика һәм проблематика, жанрлар системасы мәсьәләләренә М. Гайнуллин, Г. Халит, И. Нуруллин, Ф. Әгъзәмов, Р. Нуруллина, М. Борһанова, М. Мәһдиев, Ф. Мусиннарның тикшеренүләрендә игътибарга алына. Бу традиция Р. Ганиева, В. Гарифуллин, Д. Заһидуллина, Т. Гыйлаҗев һ.б.лар тарафыннан бүгенге көндә

дә дәвам ителә һәм соңгы елларда татар фәнендә күзәтелгән үзгәрешләр ноктасыннан якын килгәндә, бу төр иҗатында совет чорында хаксыз рәвештә күләгәдә кала килгән мөһим яклары ачыклана.

Ф. Әмирхан темасы гыйльми-фәнни эшчәнлегенең бер тармагын тәшкил иткән М. Мәһдиев публицистиканың язучы мирасында зур урын алып торуын, аның бу юнәлештә яратып эшләвен ассызыклый [Мәһдиев, 1987, 41]. Күренә ки, аның бу калыптагы язмаларында күренекле замандашлары Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, С. Рәмиев, Н. Гасрый һ.б.ларны борчыган актуаль проблемалар яктыртыла.

Мәгълүм булганча, Ф. Әмирхан татар халкын инкыйраздан саклап калу юлында, иң беренче нәүбәттә, кешенең аң-белеменә, рухи-әхлакый камиллегенә зур өметләр баглый һәм ул бу проблеманы иҗтимагый-милли һәм дини-фәлсәфи контекстта карый. Шуңа күрә башка публицистлар белән чагыштырганда, гыйлемлелек, әхлак һәм исламият, дин тарихы мәсьәләләре яктыртылган язмалар бер катламны тәшкил итә.

Ф. Әмирхан М. Бигиевнең «Кавагыйде фикъһия» («Ислам белеме кагыйдәләре») исемле зур күләмле хезмәтенә рецензия яза. Ул язучының җыентыкларына кермәгән. Язучы ислам белеменең тарихын күздән кичерә. Элекке гасырларда, дип яза ул, ислам илләрендә шәригатькә бина кылынган хокук Европада кулланылган хокукка караганда бик күпкә гадел, шәфкатьле булган, бик югары урын тоткан һәм белгечләр, галимнәр тарафыннан эшләнә килгән. Тора-бара ислам дөньясында бер торгынлык башлана. Вакытлар узу белән, фикъһенең заман рухына туры килмәгәнлеген төшенмәү мөмкин булмый. Менә шул уйлар татарлар арасыннан Габденнасыйр әл-Курсави, Шиһабетдин әл-Мәрҗани, Муса Бигиевләрне дөньяга чыгара. Ышану-инануны схоластикадан коткару исеме белән башланган бу дини хәрәкәт тиз бер заманда исламның тормыш белән еш очраша торган мәйданына – фикъһегә күчә. Мәкалә авторы Муса Бигиевнең бу юнәлештә җитди адым ясавын, мәдрәсәләрдә буталчыклык сурәтендә укытыла торган фикъһе кагыйдәләренең билгеле бер тәртипкә салынуын күрсәтә.

Ф. Әмирханның «Затымызга мөнасиб сыйфатларымыз» («Асылыбызга туры килә торган сыйфатлар») фельетоны «Идел»нең 1909 елгы 22 декабрь һәм 1910 елгы 12 гыйнвар саннарында басыла. Ул Муса Бигиевнең исламият проблемаларын яктырткан мәкаләләре һәм китаплары басылып чыгу уңаеннан «Шура» журналы битләрендә купкан бәхәс уңаеннан язылган.

М. Бигиев татар халкының дини һәм фәлсәфи фикер тарихында Г. Курсави, Г. Утыз Имәни, Ш. Мәрҗани кебек либераль карашлары белән танылa һәм дини реформатор буларак таныла. Әмма, хәнәфи мәзһәбенә өстенлек биргән беренче реформаторлардан аермалы буларак, исламның дүрт дини-хокукый мәктәбен дә таный. Коръән, хәдис белемнәрен хәзерге белемнәр, чынбарлык белән бергә кушарга

омтыла, мәдрәсәләрдә *кәләмне* укытуга каршы чыга, бай мөселман әдәбиятына, фәлсәфи һәм дини мираска мөрәҗәгать итәргә чакыра. Ул хатын-кыз хокукын, аның ир-атлар белән тигезлеген һәм мөселман дөньясында ролен югары күтәрү мәсьәләләрен үз эченә алган программа тәкъдим итә. Һәм бу карашларын «Коръән кәрим аять кәлимәләре» (1933) китабында бастыра. Бу китап мөселман галәмендә тулысы белән хатын-кыз проблемаларына багышланган беренче фәтва була.

Ф. Әмирхан мәктәп-мәдрәсәләр өчен нәшер ителгән уку әсбапларын, хрестоматияләрне һәм дин китапларын игътибарсыз калдырмый. Бу шәкелдәге язмалар «Әлислах» газетасының «Яңа китаплар» рубрикасын хасил итеп, шунда басылып киләләр. «Адабе тәгълим» (1908), «Яңа китаплар хакында мөхакәмә: «Сурәт каһвәханәсе», «Казан тарихы» (1908), «Әхлак дәресләре» (1908), «Яңа китаплар, «Тәхрирел-мәрьат» һәм «Әлмиратьел-җәдидә» (1909) тәрҗемәләре шундыйлардан. Ф. Әмирхан аларның күбесендә, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту, тәрбия методларының һәм принцип-алымнарының үзгәрергә, яңарырга тиешлеген күздә тотып, китапларның идея эчтәлегенә, төзүче-авторларның карашларына һәм тәрбия алымнарына тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Ф. Әмирхан проблеманы куеп кына калмый, ә аннан чыгу юлларын да тәкъдим итә. Бу очракта әхлакый мәсьәләләрне образ һәм тасвир аркылы гәүдәләндерүне, көнбатыш методикасындагы казанышларга таянып, мавыктыргыч һәм тискәре хисләр уята торган әсәрләр уку ярдәмендә яшь буында югары әхлак тәрбияләү юлын яклый.

Татар зыялылары дини оешмалардагы вакыйгаларга, чараларга һәм андагы үзгәрешләргә, мөфтилек мәсьәләләренә үз мөнәсәбәтләрен белдерүне кирәк дип табалар. Россия күләмендә мөфти сайлау компаниясе башлангач, аерым шәхесләр арасында гына түгел, дәүләт тә үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, билгеле бер дәгъвалар белдерә башлый. Бәхәстә Ф. Әмирхан да катнашып китеп, кандидатураларга, шушы уңайдан татар халкы менталитетына кагылышлы шактый кискен фикерләр әйтелгән өч мәкалә белән чыгыш ясый. Публицистның «Мәдәни ганганәсезлек хурлыгы» мәкаләсе «Кояш» газетасының 1915 елгы 30 июль санында басыла. Татар мәхәлләләрендә анархия, тәртипсезлек хөкем сөргән вакытта, эш башына «гыйлемле, гакыллы, гайрәтле эшсөяр» мөфтинең килүе көтелә. Шушы урынга никадәр шәхесләрнең «теш вә тырнаклары белән» азапланып менәргә тырышулары Ф. Әмирханны борчый. Автор мөфтилек вазифасының халык, милләт яшәеше алдында зур җаваплылыгын аңлап, үзләрен тәкъдим иткән кандидатураларның ни белем, ни тәҗрибә ягыннан лаек түгеллекләрен раслап чыга.

Ф. Әмирхан публицистикасында социаль контрастлар, иҗтимагый гаделсезлекләр, гадел, бәхетле җәмгыять төзү, милли бөтенлекне саклау мәсьәләләре «Авырулар галәмендә» (1908), «Богаулар өзелделәр» (1917) язмаларында күтәрелә. Җәмгыятьтә милли яшәештә

күзәтелгән тискәре күренешләргә мөнәсәбәт белдереп, аларны кире кагу рәвешендә язылган «Мөтәгассыйб Казан татарларына ачык хат» (1907), «Тел мәсьәләсенә бер караш» (1908), «Казан, 16 нчы февраль» (1908) мәкаләләре дә чорның иҗтимагый-милли проблемаларын кузгатуы ягыннан игътибарга лаек. Мәсәлән, ул беренчесендә тел бетүгә мондый карашын белдерә: «Бер милләтнең теленең җуелуы димәк улып, әдәбиятның җуелуы да, рухының бетүе дигән сүздер» [Әмирхан, 1989, 83].

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Киңкырлы талант иясе Ф. Әмирхан XIX гасырның икенче яртысында ук яңарыш юлына чыккан милли сүз сәнгатенең XX гасыр башындагы күтәрелешендә һәм үсешендә зур роль уйный. Элгәреге традицияләрне парлаклы җирлектә Гареб һәм Шәрык мәдәниятләренең казанышлары белән синтезлап, татар әдәбиятын дөнья аренасына чыгара. Тукайлар, Исхакыйлар чорында мөстәкыйль үсеш юлына чыккан әдәби тәнкыйть һәм публицистиканы формалаштыруга да зур көч сала. Ул рус әдәбият белемендә калыплашкан һәм XX гасыр башында милли әдәби-гыйльми фикер тарафыннан үзләштерелгән культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә, әдәби кануннарына таянып, татар реалистик тәнкыйтенә нигез салса, публицистикасында милли яшәешебезнең әһәмиятле мәсьәләләрен күтәрү белән бергә, татар әдәбиятының, милли мәгарифнең, милли тел, тарих, диннең мөһим проблемаларына да җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтә. Күренә ки, Ф. Әмирхан һәр тармакта новатор, киңкырлы, тирән белемле, иҗади шәхес, милләтпәрвәр, халык хезмәтчесе булып кала.

**Әдәбият**

*Әмирхан Р.* Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 1 т.: Хикәяләр (1907–1922). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 2 т.: Повестьлар роман һәм драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 488 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

*Әмирхан Ф.З.* Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 390 б.

*Әмирхан Ф.З.* Хәят. Казан: ТӘһСИ, 2016. 308 б.

*Вәлиди Җ.* Әдип Фатих Әмирхан // Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 182–186.

*Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

*Заһидуллина Д.* Кереш сүз // *Әмирхан Ф.* Әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр.. 2002. Б. 5–12.

*Заһидуллина Д., Гомәров И.* Кереш // *Әмирхан Ф.З.* Хәят. Казан: ТӘһСИ, 2016. Б. 3–14.

*Ибраһимов Г.* Хәят // *Ибраһимов Галимҗан.* Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914) / төз., текст.,

иск. һәм аңл. әзер. З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 79–81.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: унбиш томда. 1 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.

*Мәһдиев М.С.* Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 304 б.

*Сәгъди Г.* Бездә әдәби тәнкыйть (Үктәбернең унъеллыгына). Казан: «Безнең юл» редакциясе. 22 б.

*Урманче Б.* Фатих Әмирхан белән очрашуларым // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 50–54.

*Хәсәнов М.Х.* Фатих Әмирхан (1886–1926) // *Әмирхан Ф.* Сайланма әсәрләр: дүрт томда. 1 т.: Хикәяләр (1907–1922). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 458–474.

*Шамов А.* Бер кичәдә // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 137–155.

***Гыйлаҗев Таһир Шәмсегали улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең*
*татар әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

***Габделбари Баттал-Таймас***

# ПАРАЛИЧЛАНГАН ХӘЛДӘ 10 ЕЛ ИҖАТ ИТКӘН ӘДИП ФАТИХ ӘМИРХАН (1885–1926)

***80 еллык юбилее уңаеннан***

*Габделбари Баттал (Габделбари Габдулла улы Сәетбаттал – 1880–1969) – тарихчы, җәмәгать эшлеклесе. 1965 елда «Төрек культуры» журналының (Әнкара, Төркия) март санында аның Ф. Әмирхан турында истәлеге басыла. Биредә истәлек төрекчәдән татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә.*

Ун ел дәвамында параличланган хәлдә иҗат иткән атаклы татар әдибе һәм журналисты Фатих Әмирхан моннан 80 ел элек (1885 елда)[1] дөньяга килә. Ул – Казан шәһәренең, нигездә, мөселманнар яшәгән Яңа Бистә мәхәлләсе имамнарыннан Зариф Әмирхан әфәнденең олы улы. Урта белемне Казан шәһәрендәге җәдиди ысуллар нигезендә укытылган һәм алдынгы карашлы дин эшлеклесе Галимҗан Баруди җитәкләгән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ала. Гаиләнең фамилиясе Зариф имамның атасы, ягъни Фатих Әмирханның бабасы Хөсәеннең атасы Әмирхан исеменнән алынган. Казанның бер мәхәлләсендә имам вазифаларын башкарган Хөсәен Әмирхан дин гыйлеме өлкәсендә үз чорының алдынгы карашлы кешеләренең берсе саналган, шуның өстәвенә тарих өлкәсендә дә фәнни тикшеренүләр алып барган. 1883 елда Казанда аның «Тәварихе Болгария» исемле кечкенә генә бер хезмәте басылып чыккан.

Фатих Әмирхан 1905 елгы Беренче Рус революциясенә кадәр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган вакытта дин гыйлемен, гарәп әдәбиятын, берникадәр күләмдә дөньяви фәннәрне үзләштерә. Алга таба болар белән генә канәгатьләнмичә, рус теленнән дә шәхси дәресләр алып, аны җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнгәннән соң, рус матбугатын һәм әдәбиятын күзәтеп бара башлый. Бу тырышлыклары нәтиҗәсендә дөньядагы вакыйгалар, иҗтимагый тормыш һәм яңа фикер агымнары турында мәгълүмат туплаган акыллы егет, башка күп кенә яшьләр кебек, Россиядәге халыкларның тормышында яңа өмет чаткылары кабызган революцияне берникадәр дәрәҗәдә әзерлекле килеш каршылый. Шул сәбәпле, Фатих, кайбер иптәшләре белән бергә, мәдрәсә идарәсенә, дәрес программаларына яңа вазгыятькә җавап бирә алырлык үзгәрешләр кертүне таләп итеп чыгалар, теләкләре кабул ителмәгәч, демонстратив рәвештә мәдрәсәне ташлап чыгалар һәм «Ислах» җәмгыятен коралар.

---

[1] Дөресе: 1886 елның 1 гыйнвары.

1906 елның ахырында Кавказ халыкларының атаклы каһарманы Шәех Шамилнең оныгы Заһид Шамил (бәлки хатыны – Казаннан чыккан атаклы сәүдәгәрнең кызы – йогынтысы беләндер) «Тәрбияиәтфаль» исемле балалар журналы чыгару фикеренә килә һәм тәрҗемәче итеп Фатих Әмирханны чакыра. Журналның беренче номеры 1906 елның декабрь аенда чыга.

Фатих Әмирханның Мәскәүдә күпме торганын белмибез, әмма аякларына паралич нәтиҗәсендә ул әлеге шәһәрдә булган вакытта хәрәкәтсез калуы мәгълүм[1]. Шуннан соң яшь әдип Казанга кайта һәм, нәрсә генә эшләп караса да, аяклары төзәлми.

Бу казадан соң әдип аякларында туры басып тора алмый башласа да, ни гаҗәп, паралич сугу аның йөрәк һәм ми эшчәнлегенә зыян китерми. Ул коляскага кадакланган хәлдә дә аң эшчәнлегенә сәләтен, киләчәккә ышанычын һәм күңел көрлеген җуймый. Әдип якыннары хәтерендә шушы хәлендә дә тормышының соңгы мизгелләренә кадәр шатлык нуры чәчеп торган кеше буларак сакланып калган. Хәтерем ялгышмаса, мин аның белән 1912 елның җәендә Казанга сәфәр кылган вакытта шәһәрнең Суконная дип аталган бистәсендәге йортында күрештем. Бу безнең беренче күрешүебез иде. Шул вакытта мин хәрәкәтләнү мөмкинлеген югалткан бу кешедә ниндидер бер рух күтәренкелеге һәм шатлык хисләренең ташып торуына шаккаткан идем.

Фатих Әмирханның мөхәррирлек эшчәнлеге чын мәгънәсендә 1907 елда башлана. Мәскәүдән кайтып Казанда төпләнгәч, бераз соңлабрак, ягъни 1907 елның октябрендә үзенең кайбер фикердәшләре белән бергә «Әлислах» исемле атналык газета чыгара башлый. Бераз соңлабрак дидек, чөнки бу вакытка, 1907 елның 3 июнендә оештырылган хөкүмәт түнтәрелешеннән соң, дәүләт башында торган кешеләргә бик үк ошап бетмәгән Икенче чакырылыш Дәүләт Думасы куып таратыла һәм хөкүмәткә җайлы сайлау кануны кабул ителә. Хөкүмәт тарафыннан күрелгән көчле чаралар нәтиҗәсендә революцион хәрәкәт тә сүрелә, реакцион көчләр өстен чыга башлый.

Шул сәбәпле, радикал карашлы яшьләрнең матбугат органы саналган бу газета илдә алып барылган эчке сәясәтне теләгән кадәр каләм очына ала алмаса да, мөселманнарның иҗтимагый тормыштагы артталыгын, искелек һәм схоластика тарафдарларын, аларга терәк булган «могтәбәр» кешеләрне көчле тәнкыйть утына тота. Фатих Әмирхан – газетаның рухын һәм эчтәлеген билгеләүче дә, шул ук вакытта күпчелек мәкаләләрне язучы редактор да. Ул газета битләрендә әдәби һәм иҗтимагый тәнкыйтьче буларак та, сәяси эчтәлекле баш мәкаләләр редакторы һәм сатирик хикәяләр авторы буларак та чыгыш ясый (Моннан газетага мәкалә язган башка яшьләрнең ул кадәр белемле һәм талантлы кешеләр булмаганлыгы аңлашыла).

[1] Истәлектәге әлеге мәгълүмат язучы авыруы хакындагы фаразларның берсе буларак карала.

Фатих Әмирхан язган мәкаләләренең төренә карап, өч төрле псевдоним кулланган: 1) сәяси эчтәлекле мәкаләләрнең астына күп очракта үз исемен куйган (кайбер очракларда бу төр мәкаләләр имзасыз басылганнар); 2) җитди тәнкыйть мәкаләләрен «Дамелла» (Бохара шәкертләре телендә зур мулла) псевдонимы белән имзалаган; 3) сатирик эчтәлекле мәкаләләрендә «Ташмөхәммәд» псевдонимын кулланган.

Әдипнең беренче әсәре – «Гарәфә көн төшемдә» исемле фантастик хикәясе – әлеге псевдоним белән чыга. Язучы бу хикәясендә гарәфә көн күргән төшендәге вакыйгаларны, аерым алганда, милли бәйрәм дәрәҗәсенә күтәрелгән дини бәйрәм белән бәйле шатлыклы чараларны тасвирлый һәм, һичшиксез, ул әлеге уйдырма вакыйгаларның тормышта да чынга ашуын теләгән.

Фатих Әмирханның 1907 елда башланган җанлы әдәби эшчәнлеге 1917 елга кадәр, ягъни 10 ел дәвам итә. Язучы буларак кулыннан килгәннең барысын да ул нәкъ менә әлеге вакыт аралыгында башкара. Ун ел дәвам иткән «әдәби гомер». «Әлислах»ның тормышы ул кадәр озак булмый.

Газетасы ябылганнан соң Фатих Әмирхан биш ел журналистлык эше белән шөгыльләнми, бу вакыт аралыгында ул җитди һәм сатирик эчтәлекле хикәяләр, пьесалар язу белән мәшгуль була.

Әдипнең бу дәвердә «Хәят», «Кадерле минутлар», «Урталыкта», «Фәтхулла хәзрәт» исемле хикәяләре; «Яшьләр», «Тигезсезләр» һ.б. пьесалары басыла. Әлеге хикәя һәм пьесаларның төп геройлары – киемнәрендә, сүз һәм эшләрендә европалыларга охшарга тырышкан, кайберләре дәүләт мәктәпләрендә белем алган, күбесе исә әдипнең тар даирәсендәге яшь егетләр һәм кызлар. «Фәтхулла хәзрәт», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Салихҗан карый», «Сәмигулла абзый» исемле сатирик хикәяләрендә һәм фельетоннарында исә авторның көлү объекты – иске карашлы хаҗиләр, сәүдәгәрләр һәм кырык тартмачылар. Болар – язучының гаиләсе тирәсендәге танышлары һәм искелек тарафдарларының җыелу урыны булган Печән базары әһелләре. Димәк, Фатыйх Әмирханның әсәрләрендә ике төрле тип кешеләр тасвирлана: иске дәвер кешеләре һәм яңа чор яшьләре.

«Кояш» дәвере. Алдарак Фатих Әмирханның ун еллык әдәби эшчәнлегенең башында журналистлык һәм редакторлык эше белән шөгыльләнүе турында әйтеп киткән идек. Ул әлеге эш белән әдәби эшчәнлегенең соңгы биш елында да шөгыльләнә. 1912 елда Казанның атаклы сәүдәгәрләреннән Мөхәммәтҗан, Шәрифҗан һәм Хәсән Кәримовлар, нинди максатлардан икәнлеге билгесез, газета чыгарырга карар кылалар. Ул вакытларда Казанда татар телендә Һади Максуди нәшер иткән «Йолдыз» газетасыннан башка бернинди дә газета чыкмаган. Чөнки 1905 ел алып килгән яңалык җилләре тәэсире нәтиҗәсендә бер-бер арты чыга башлаган татар газеталары алга таба барысы да, кайсы сәяси, кайсы икътисади сәбәпләр аркасында ябылып бетәләр,

бары тик бер «Йолдыз» газетасы гына торып кала. Яңа газетаның җаваплы мөхәррире итеп Кәримовларның каенагасы Зәкәрия Садретдин, баш мөхәррире итеп Фатих Әмирхан чакырыла. Газетага, бәлки «Йолдыз»ны тулысынча каралту максатыннандыр, «Кояш» исеме бирелә.

Биредә шуны искәртеп үтәргә кирәк: «Әлислах»та эшләгән вакытта Фатих Әмирхан үзен каты тәнкыйтьче һәм аяусыз революционер итеп танытса, «Кояш» газетасы битләрендә ул җитди бер либерал-реформатор буларак чыгыш ясый. Газетага мәкалә язган вакытта ул, бер яктан, хөкүмәт вәкиле саналган Казан губернаторының нәрсә әйтәчәген уйлап эш итәргә, икенче яктан «Кояш» хуҗаларының Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының хуҗалары Рәмиевләр кебек алдынгы карашлы һәм билгеле бер сәяси юнәлеш тарафдарлары булмауларын да истә тотарга тиеш булгандыр. Шул сәбәпле Фатих Әмирхан сәяси мәкаләләрендә, «Әлислах»тагы кебек, каләменә тулы ирек бирмәгән булса, фельетоннарында да искелек тарафдарлары өстенә агулы укларын элеккеге кебек күп яудырмый. «Әлислах»ның Дамелласы белән Ташмөхәммәде «Кояш» редакциясенә бик еш кермәгәннәр. Кыскасы, сәяси мәкаләләрдә чиктән чыкса, газетаны губернатор яптырачак, ә милли мәсьәләләр күтәрелгән мәкаләләрдә сак булмаса, газета хуҗаларының хәтере калачак. Димәк, хәлләр югары төкерсәм, мыегыма, аска төкерсәм, сакалыма кебегрәк булган...

Минем фикеремчә, газетада Фатих Әмирханнан башка җүнлебашлы бер язучы да булмагандыр. Нәрсәдер өчен җаваплы язучының да каләмен үзе теләгәнчә тибрәтә алмавы шулай билгеле бер әйбер. Әлбәттә, «Кояш» битләрендә атаклы татар шагыйре Г. Тукайның да шигырьләре басылган, ләкин ул сирәк күренеш булган. Шул сәбәпле, яңа газета җәмәгатьчелектә зур уңыш казанган һәм «Йолдыз»ны күләгәдә калдыра алмаган. Мин 1913 елның җәендә, «Йолдыз» газетасында үз өстемә сәркәтиплек вазифасын алган вакытта, «Кояш» газетасы ике ел чыгып килә иде инде. Әлеге ике газета, бер-берсен батырмыйча, 1917 елгы Рус революциясенә кадәр яшәп килделәр. 1917 елның язында мин «Йолдыз»дан киттем һәм җәй айларында, мәрхүм Фуад Туктар белән бергә, «Корылтай» газетасын чыгара башладык. Әлеге газетаны без большевиклар хакимияте яптырганга кадәр чыгардык. «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталары исә большевиклар хакимияткә килү белән япканнарын көтмичә, үзләре чыгудан туктадылар. Шул рәвешле 1906 елда чыга башлаган «Йолдыз» газетасы унбер елдан соң, ә «Кояш» газетасы чыга башлавыннан соң биш ел үткәч, тарих мәйданыннан төшеп калдылар.

Фатих Әмирхан «Кояш» газетасында эшләгән вакытта да «Яшен» һәм «Ялт-йолт» исемле газеталарга кайбер сатирик мәкаләләр һәм фельетоннар, ә «Аң» журналына әдәби мәкаләләр язган.

Югарыда әйтеп үткәнчә, Фатих Әмирханның «әдәби гомере» 1917 елга кадәр ун ел дәвам иткән һәм ул бу вакыт аралыгы үтү белән тәмамланган. Большевиклар хакимияткә килгәннән соң, Фатих Әмир-

хан Казаннан башка бер җиргә дә китмәгән, качмаган, әмма ул һичбер вакыт советлар режимын кабул итмәгән.

Минем аңлавымча, ул 1922 елда Финляндиягә җибәргән хатында тасвирлап язган ачлык һәлакәте вакытында мохтаҗлар файдасына чыгарылган «Икенче Ярдәм Мәҗмуга»сында ачларга ярдәм максатыннан бастырган «Тәгъзия» исемле мәкаләсеннән тыш совет матбугаты битләрендә башка һичбер нәрсә бастырмаган. 20 ел параличланган хәлдә яшәгән атаклы әдип-журналист 1926 елда вафат була.

1922 елны Идел буенда куркыныч ачлык котырган вакытта Финляндиядә яшәгән туганнарыбыз тарафыннан, Америка ярдәм оешмасы (АРА) арадашчылыгы белән, Казанда яшәгән язучы һәм әдипләргә ашамлыклар тутырылган пакетлар җибәрелә. Алар арасында Фатих Әмирхан да була.

Пакетлар Финляндия имамы һәм мәхәллә җитәкчесе Хуҗа Вәли Әхмәт Хәким исеменнән җибәрелгәнлектән, аларны алган кайбер язучылар аңа рәхмәт хатлары җибәргәннәр. Бу хатларның иң әһәмиятлесе Фатих Әмирханныкы. Ул татар әдәби телендә язылган:

«Мөхтәрәм В.Ә. Хәким әфәнде, бүген 9 мартта сезнең АРА арадашчылыгы белән минем исемемә җибәрелгән бүләкне алдым. Мин шәхсән сезнең белән танышмы, түгелме, белмим. Чөнки АРАның биредәге бүлекчәсендә сезнең тулы исемегезне һәм вазифагызны әйтмичә, В.Ә. Хәким дип әйтү белән генә чикләнделәр. Һич көтелмәгән, уйланмаган җирдән һәм һич өметләнмәгән бер вакытта килеп ирешкән бу бүләк мине бик тә сөендерде һәм рухымны күтәрде. Мин яшәгән җирдән еракларда, чит-ят җирләрдә, сине хәтерләгән, синең турында уйлаган дусларыңның булуын белү чыннан да рухны күтәрә. Бу бүген без яшәгән шушы караңгы көннәрдә яктылык бөркүче бер нур кебек күзләрне камаштыра; киләчәккә өмет хисләрен уята; арган, таушалган нервыларга бераз ял итү мөмкинлеге бирә һәм кешенең йөрәген куәтләндерә. Сезнең бүләгегез менә шулай миңа үзе белән бергә әлеге әйберләрне дә алып килде. Туганым, боларның барысы өчен дә сезгә иң самими рәхмәтләремне җиткерәм.

Аеруча ачлык соң дәрәҗәгә җитеп котырган иң авыр айларда килеп җитешкән бу бүләкнең минем өчен зур матди ярдәм булганлыгын һәм күңел тынычлыгы алып килгәнлеген әйтмичә булдыра алмыйм. Мәсьәләнең (ягъни ачлык мәсьәләсенең) чишелеше Татарстанда хәзерге вакытта гаять өметсез бер дәрәҗәдә. Ачлыктан урам уртасында үлеп ятучылар, хәтта кеше суеп итен ашаучылар, кеше мәетен ашаучылар чын мәгънәсендә гадәти хәлләргә әверелделәр.

Шул рәвешле, туганым, мине исегездә тотуыгыз, минем турында уйлавыгыз һәм матди яктан ярдәм иткәнегез өчен тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәм.

Ихтирам һәм сәламнәр белән Фатих Әмирхан. 29/3/1922.

Искәрмә: Вакытыгыз мөмкинлек бирсә, миңа бер хат язып, үзегез белән таныштырсагыз, бик шат булыр идем. Ф.Ә.»

Россиядә ачлык бәласенә тарыган кардәшләремезгә «кырмыска кадәр генә» булса да ярдәм итү максаты белән Финляндиядә якташларыбыз тарафыннан 1921 елгы Корбан бәйрәме җыенында, мин Финляндиягә килер алдыннан, берникадәр иганә җыелган булса да, ул иганәнең ни рәвешле файдаланылачагы мин Финляндиягә килеп Хельсинкидә урнашкач кына хәл ителде. Аерым алганда, минем тәкъдимем һәм имам В. Әхмәт Хәким әфәнденең хуплавы белән җыелган акчаның бер өлешенә Казанда ачлык бәласеннән газап чиккән фикер һәм каләм ияләренә АРА – Америка ярдәм оешмасы аркылы ашамлык тутырылган пакетлар җибәрү турында карар кабул ителде. Ашамлык пакетлары җибәрелгәннәр арасында Фатих Әмирханнан башка Казан татарларының түбәндәге зыялылары да бар иде: мөхәррир һәм мөгаллим Җамалетдин Вәлиди, мөгаллим Мөхетдин Корбангали, голамәдән мөхәррир һәм фикер иясе Муса Ярулла Бигиев, тарихчы һәм ул дәвердә мөфти Ризаэтдин Фәхретдин, тарихчы Хәсән Гата Габәши, Ислам мәҗлесе әгъзаларыннан Кәшшаф Казый Тәрҗемани, тарихчы Һади Атласи, Әстерхан имамы һәм журналист Габдерахман Гомәр, шул ук шәһәрдән мөхәррир Нәҗип Гасрый, Оренбургтан мөхәррир һәм журналист Фатих Кәрими, Самара шәһәре имамы һәм журналист Фатих Мортаза, голәмадан мөдәррис Галимҗан Баруди, Диния мәҗлесе әгъзаларыннан Мөхлисә Буби (болардан Нәҗип Гасрый, Фатих Кәрими, имам Габдерахман Гомәрдән пакетларны алу турында озын яисә кыска җавап хатлары алынды). Бу мәгълүматны бер-ике ел элек Истанбулда басылган бер әсәремдә биргән булсам да, иҗтимагый эшчәнлек алып баручы һәм тарих белән кызыксынган кеше буларак, биредә дә яңадан әйтеп китүне кирәк дип таптым.

Бу мәкаләне язган вакытта Фатих Әмирханның югарыда телгә алган хатын тагын бер тапкыр күздән кичергәннән соң, хәзер искә алган тәкъдимемнең ни кадәр урынлы булганлыгын һәм шуның белән бик тә саваплы эш башкарганымны уйлап, күңелләрем ятырып китте.

*Истәлек ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Мирхәев тәрҗемәсендә бирелә*

УДК 94(47).07

*И.К. Заһидуллин*

# АЛЕКСАНДР I ҺӘМ КАЗАН ГУБЕРНАСЫ

В данной статье на основе анализа административного сопровождения становления университета и постройки памятника в память погибшим при взятии Казани в 1552 г., а также принятых оперативных постановлений по фактам правонарушений губернской администрации отслеживается социальное поведение императора Александра I и его личностный подход к решению проблем провинциального города. Выделяются такие черты характера российского монарха как последовательность в действиях и государственный подход в поступках.

**Ключевые слова:** Александр I, Казанский университет, строительство памятника «В память победы над татарами 1552 г.», сенаторские ревизии, Казанская губерния.

The article deals with the social behavior of emperor Alexander I and his personal approach to solving the problems of the provincial city. The paper analyses the administrative support of the formation of the university and the construction of a monument in memory of those who died during the capture of Kazan in 1552 year, as well as the adopted operational decisions on the facts of violations of the provincial administration. The author highlights such character traits of the Russian monarch as consistency and a state approach in actions.

**Keywords:** Alexander I, Kazan university, senatorial audits, construction of the monument “In memory of the victory over the tatars in 1552 year”, Kazan province.

Россия тәхетеварисларын дәүләт белән идарә итүгә әзерләгәндә, аларны төрле төбәкләр тормышы белән таныштырганнар. Мондый сәяхәтләр махсус яки яшьләрне император свитасы составына кертеп оештырылган.

Булачак император Александр I һәм энесе Константин өчен Урта Идел төбәгенә шундый сәяхәтне 1796 елның маенда әтиләре Павел I оештыра. Бу вакытта 21 яшьлек полковник Александр Павлович Санкт-Петербургның хәрби губернаторы, шәһәрдә урнашкан дивизия һәм азык-төлек белән тәэмин итү комиссиясе җитәкчесе буларак, мөһим дәүләт вазифаларын били.

Павел I Казанга, Оренбург хәрби экспедициясе гаскәрләренең хәрби әзерлеген тикшерү өчен, күпсанлы якыннары белән килә һәм биредә төгәл бер атна – майның 24 еннән 30 ына кадәр була. Патша галиҗәнаплары, Казан, Оренбург, Пермь губерналарыннан махсус тупланган гаскәрләр белән танышудан тыш, шәһәр халкы белән аралашырга да вакыт таба. Шәһәр имамнары да, ахун Ибраһим Хуҗаш җитәкчелегендә, башларына чалмаларын урап, хакимият вәкилләре, сәүдәгәрләр, христиан руханилары белән бергә олы кунакны каршы ала [Фәхреддин, б. 109].

Әйтик, Казанга килгән көнне Павел I кирмәндә урнашкан Благовещение соборында була, икенче көнне шәһәр халкының төрле социаль катламнары делегацияләрен кабул итә, ә кичен үзе хөрмәтенә Дворян собраниесе бинасында оештырылган балда катнаша. Дворян кызлары бу кичне бөек кенәзләр Александр һәм Константин Павловичларның кулларын тоту һәм алар белән бию бәхетенә ирешәләр.

27 майдан башлап, Павел I өч көнне гаскәрләр янында уздыра: шәһәр читендә, Арча кырында башта аларга инспекция ясый, аннары хәрби өйрәнүләрдә катнаша. Ә өйләдән соң яки кичке якта шәһәр халкы вәкилләре белән очраша. Әйтик, Казандагы өченче көнендә император Казан наместнигы генерал-майор Семен Батаев йортына балга бара. Бирегә Оренбург мөфтие Мөхәммәдҗан Хөсәенов, мөселман руханилары һәм татар сәүдәгәрләре, кайберләре гаиләләре, хатыннары һәм кызлары белән дә чакырулы булып, аларның һәрберсе патша галиҗәнапларына тәкъдим ителә.

Башка көннәрдә кичләрен патша яшәгән йорт янында (хәзерге М. Горький урамы) губерна түрәләре, шәһәр халкын оештырып, төрле уеннар һәм күңел ачу чаралары уздыра, ә Павел I үзе төрле катлам вәкилләренең депутацияләрен кабул итә, гозерләрен тыңлый [Загоскин, с. 235–242]. Р. Фәхретдин мәгълүматлары буенча, Павел I Иске татар бистәсендә мәчеттә ахун Ибраһим Хуҗаш җитәкчелегендә мөселманнарның җәмәгать намазы укуларын күзәткән, күрәсең, намаздан соң аның белән аралашкан. 1798 елда император Ибраһим Хуҗашка бүләккә 500 сумлык алтын сәгать җибәргән. Ахун хәзрәтләре, җавап итеп, Павел I гә рәхмәт хаты юллаган [Фәхреддин, б. 109].

30 май көнне, юлга кузгалыр алдыннан, император Богородицкий монастыре соборына нигез ташы салу тантанасында катнаша.

Күрәбез, патша галиҗәнапларының 25 меӊ чамасы кеше [Свердлова, с. 13] яшәгән губерна шәһәренә килүе халык өчен гаҗәеп олы вакыйга була, түрәләр император исеме белән уяна һәм йокларга ята, шәһәр халкы төрле уеннарда һәм күңел ачуларда катнашып, шул рәвешле хөрмәтен күрсәтә. Әлбәттә, бу чаралардан Павелның уллары Александр һәм Константин да читтә калмаган, аларның шәһәрнең истәлекле урыннарын карарга һәм төбәк тарихы белән дә кызыксынырга вакыты булган дип уйларга нигез бар.

### *«Александр I һәйкәле»*

Ханлык егылу вакыйгасына 260 ел туларга бер ел кала, Зилант монастыре архимандриты Амвросий патша Иван Васильевичның 1552 елда татарларны җиңүе истәлегенә һәйкәл-ташбилге төзү тәкъдиме белән чыга, аны Казанны алганда һәлак булган рус сугышчыларының туганнар каберлеге янына куярга тәкъдим итә.

Туганнар каберлеге урнашкан җирләр 1560 елда патша Иван IV тарафыннан Зилант монастырена бүләк ителгән була. Шуңа күрә монахлар каберлекне гасырлар дәвамында карап-күзәтеп тора. Ләкин

XVIII йөз ахырында генераль җир бүлү барышында, Казанның киңәю перспективасын күздә тотып, бу җирләр шәһәр карамагына бирелә. Шуңа күрә Эчке эшләр министрына Казан губернаторының архимандрит Амвросий тәкъдиме турындагы хаты һәйкәл урынына шәһәр думасыннан 1811 елны рөхсәт алынгач һәм казанлылардан 1,5 мең сум иганә акча җыелгач кына языла.

Александр I хат белән таныша, тәкъдимне хуплый, ләкин аңа таш багана формасында эшләнгән һәйкәл рәсеме ошамый. Күрәсең, 1798 елның маенда туганнар каберлеген зиярат иткәндә, Александр I аның хакимият һәм халык игътибарыннан читтә торганын искәргән булган. Россия өчен Казан ханлыгын буйсындыруның әһәмиятен истә тоткан хәлдә, император шушы тарихи вакыйгага лаек булырлык һәйкәл проекты эшләргә боера. Архитектор Н.Ф. Алефров (1789–1840) сызымы патша тарафыннан 1812 елның 12 февралендә раслана.

5 мең сумга төшәчәк дип уйланылган ташбилге-һәйкәл урынына мәһабәт корылма сурәтләнгән сызым белән танышкач, архимандрит Амвросий югалып кала. Аптырагач, үзенең шәһәр халкы матди ярдәме белән генә һәйкәл төзергә җыенуын, шуның өчен падишаһның фатихасын соравын әйтеп, Александр I гә хат юллый.

Патшаның җавап хаты архимандритны илкүләм җәмәгать эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрә. Аңа һәйкәлне төзү өчен империя күләмендә иганә кампаниясе игълан итеп, төзелешне җитәкләргә тәкъдим ителә, эшне башлар өчен, 5 мең сум акча да җибәрелә.

Амвросий, Казанны алганда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзергә матди ярдәм сорап, православие консисторияләренә хатлар яза, иганә җыю максатында Санкт-Петербургка һәм Мәскәүгә бара. Архимандрит Санкт-Петербургка килгәч, чиновникларга һәм халыкка үрнәк күрсәтеп, патша гаиләсе әгъзалары да иганәчелек кампаниясен җәелдерергә ярдәм итәләр. Павел I нең тол хатыны Мария Федоровна – 1 мең сум, Александр I нең хатыны Елизавета Алексеевна – 2 мең сум, энекәшләре, бөек кенәзләр, Константин һәм Николай Павловичлар – 350 шәр сум, бөек кенәгинә Екатерина Павловна 400 сум тапшыралар. Сәяхәт уңышлы тәмамлана – барлыгы 30 мең сум акча җыела.

Эшне башкарып чыгу өчен кимендә 80 мең сум кирәк дип фаразланса да, 1812–1816 еллар аралыгында 46341 сум туплангач, төзелеш барышында ярдәм көчәер дигән өмет белән, тантаналы рәвештә, зур чыгымнар тотып (975 сум!), булачак һәйкәлнең нигез ташы салына. Ләкин өметләр акланмый. 1817 елны, акча бетү сәбәпле, төзелеш эшләре туктап кала. Авыр хәлгә тарган Амвросий, ярдәм сорап, Александр Павловичка хат юллый, казнадан ел саен һәйкәлне төзергә 5 әр мең сум акча биреп баруны үтенә.

Синод, тикшерү үткәреп, архимандритның акчаны максатчан тотмавын ачыклый һәм Амвросийга ел саен 1 августка керем-чыгымнар һәм башкарылган эшләр бурында хисап бирергә боера. Казан рухани консисториясе, үз чиратында, төзелеш барышын контрольгә

ала. 1818 елны архимандрит соралган хисапны бирмәгәч, төзелеш эшләрен күзәтү губерна архитекторы М. Емельянов кулыннан алынып, архитектор А.К. Шмидтка тапшырыла. 1819 елга тотылган акча 74169 сум 50 тиенгә җитә. Калган эшләрне хисаплап, һәйкәлне тәмамлау өчен, тагын кимендә 26 мең сум акча кирәклеге ачыклана.

Александр I нең 1817 елгы хатындагы «һәйкәл төзүне тәмамларга кирәк» дигән сүзләренә таянып, Амвросий, ярдәм сорап, губернаторларга хатлар юллый. Шулай итеп, төбәк хакимияте дә иганәчелек эшенә тартыла, алар губерналарда иганә җыю чаралары оештыра. Кыска гына вакыт эчендә, 1819 елның июнь аена түбәндәге төбәкләрдән иганә акчалары килә: Киев губернасыннан – 139,6 сум, Тавриядән – 593,2 сум, Черниговтан – 164,93 сум, Херсоннан – 730,05 сум, Пермь губернасыннан – 78 сум, Полтавадан – 37,2 сум, Тамбовтан – 855 сум, Томск губернасыннан – 1295 сум, Екатеринославтан – 392,44 сум, Тверь губернасыннан – 85 сум, шулай ук Мәскәү хәрби губернаторыннан 145,45 сум күчерелә.

Архив чыганакларында 1820 елны архимандрит Амвросийның монастырьның ике вәкилен иганәчелек максатында Сембер, Саратов һәм Пенза шәһәрләренә җибәрүе әйтелә. Башка елларда да мондый гамәл кулланылган дип уйларга нигез бар.

Гомумән алганда, һәйкәлнең бәясе 100135 сумга төшә. Төзелешкә акчаның 25 мең сумын казна, 10 мең сумын император гаиләсе әгъзалары бирә, калганы казанлылардан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән җыела.

1823 елны төзелеш эшләре тәмамлангач, Александр I һәйкәлне тантаналы шартларда ачу көне итеп 30 августны – үзен саклаучы изге исеме көнен билгели (тезоименитство), шул рәвешле бу вакыйганың Россия дәүләте һәм шәхсән үзе өчен әһәмиятле булуын ассызыклый.

1823 елның 30 августы көнне Зилант монастыре чиркәвендә узган иртәнге литургиядән соң, руханилар, җыелган түрәләр һәм шәһәр халкы тәре йөреше белән һәйкәл янына килә. Биредә аларны парадка тезелгән гаскәрләр каршы ала. Һәйкәл ачылу хөрмәтенә тантаналы чаралар 101 тапкыр туплардан атып тәмамлана.

Юнан һәм мисыр стильләре катнашкан, өске өлеше кыелган пирамида итеп эшләнгән бу корылманың дүрт ягында икешәр колоннага утыртылган порталлар булып, эчендә чиркәү урнаштырыла. Һәйкәл порталлары фризларына дүрт яктан да «1552 елны татарларны җиңү истәлегенә» дип язылган була. Чиркәү стеналарына чапкан саен башлары үсеп чыга торган куркыныч еланнар сурәтләнгән ике калкан рәсеме ясала. Бу еланнар символик рәвештә татарларны гәүдәләндерә. Ә сметада каралган, һәйкәлнең фасадларына куелырга тиешле хәрби трофейлар һәм сыннар, акча җитмәү сәбәпле, эшләнмичә кала... [Загидуллин, с. 27–35].

Шулай итеп, император Александр I, Зилант монастыре архимандриты Амвросийның Казанны алганда һәлак булган рус

сугышчыларының туганнар каберлегенә ташбилге кую фикерен күтәреп алып, бу вакыйганың Россия тарихында тоткан урынына лаек булырлык мемориал проекты эшләтеп, империя күләмендә иганә кампаниесе игълан иттереп һәм беренче булып акча кертеп, аны олы патриотик чарага әверелдерергә омтыла. Акча бетү сәбәпле төзелеш эшләре тукталган һәм өзлеккән иң авыр вакытта, дәүләттән ел саен акчалата ярдәм оештыра. Патша игътибарын тойган җирле хакимият тә төзелешнең зур сәяси вакыйга икәнен аңлап эш итә. 1823 елны мемориалны ачуны үз исеме көненә – 30 августка билгеләтеп, император тагын бер кат игътибар күрсәтә.

Ә югарыда тасвирланган вакыйгаларның шаһитлары булган Казан төбәк тарихын өйрәнүчеләр, шул исәптән Н. Баженов та, бу һәйкәлне «Александр I һәйкәле» дип атап йөртә [Баженов, с. 109]. Казан түрәләре моның шулай икәнен яхшы аңлаган. XX гасыр башында мемориал эченә кергән кешене Россиянең ике патшасы – Явыз Иван һәм Александр Павлович портретлары каршы алган [Никанор, с. 48].

### *Александр I ревизияләре*

XIX гасыр башында губерналарда идарә системасын һәм хакимиятнең эшчәнлеген күзәтү, нигездә, төбәкләргә Сенат ревизиясе җибәрү юлы белән тормышка ашырыла. Ревизияләр төрлечә: «план» буенча яки шикаятьләр нигезендә оештырыла.

Шундый шикаятьләрнең берсе Казан каласын ил күләмендә җинаять кылуда гаепләнүчеләргә җәза куллану урыны итеп таныта. Үзен «мәгърифәтле монархия» төзүче дип дип игълан иткән Екатерина II, заманында яшерен Указ чыгарып, гаепләнүчеләргә карата җәза куллануны тыйган була, ә гади халыкка бу хакта хәбәр җиткерелми. Ул елларда еш кына шундый күренешне күзәтергә мөмкин була. Гаепләнүчене, психологик басым ясау максатында, җәза кораллары урнашкан бүлмәдәге станокка бәйләгәннәр, бик тырышып аның күз алдында җәзаларга әзерләү кыяфәте ясаганнар һәм сорау алганнар, ләкин җәзаламаганнар.

Казанда йортларга ут төртеп яндырулар еш кабатлану сәбәпле, хакимият шәһәрдә зур янгын чыгудан куркып яши. Ут төртүләргә каршы көрәшү, җинаятьчеләрне ачыклау максатында, шәһәрнең 3 нче полиция участогында шикләнеп кулга алынган кешеләргә карата җәза куллана башлыйлар. Бу чара уңай нәтиҗәләр бирә кебек: ут төртү очраклары бераз кими. Александр I тәхеткә утырган 1801 елны Казанда ут төртүдә шикләнгән Яковлев фамилияле мещанны, рәхимсез җәзалап, кулларын сындырып, гаебен таныталар. Судта мин гаепсез дип кабатласа да, мәхкәмә карары нигезендә камчы белән суктырганда, ул җан тәслим кыла. Сенат тикшерүе нәтиҗәсендә полиция өстеннән күзәтергә тиешле хәрби губернатор П.П. Пущин, шулай ук гражданлык губернаторы А.И. Муханов һәм тагын берничә түрә эшләреннән алына, җәзалауда катнашкан кешеләр Себергә хәрби хезмәткә озатыла [ПСЗ-1, № 20022]. «Казан инциденты» Россия империясендә га-

епләнүчеләргә карата җәза куллануны тыю турында императорның 1801 ел 27 сентябрь Указы чыгуга сәбәп була [Бикташева, с. 246–257; ПСЗ-1. Т. 26. № 20022].

Шул ук елны Казан тагын бер вакыйга белән шаулый. Үзәк хакимияткә, губерна һәм өяз администрациясен, алпавытларны һ.б. гаепләп, күпсанлы шикаятьләр ява башлый. Бераздан моның сәбәпләре дә ачыклана. Павел I, күрше Вятка губернасы чиновникларының канун бозулары турында 1799–1800 елларда уздырылган ревизия нәтиҗәләре белән танышкач, кызып китеп, губерна идарәсенең һәм губерна палаталарының (берсеннән кала) барлык түрәләрен эштән куа [ПСЗ-1, № 22076]. Эшсез калганнар Казанга күченеп, сораган кешеләрнең язу-сызу гозерләрен үтәп көн күрә башлый. Хакимият органнарында эш йөртү үзенчәлекләрен белгән кичәге чиновниклар шикаять язуны конвейерга сала. Даими табыш чыганагы булдыру өчен, алар бәлагә тарган яки гаделсезлеккә дучар булган кешеләрне шикаять бирергә котырталар. Акчаң гына җитсен! Үзләрен нахакка кыерсытылган, рәнҗетелгән дип санаучы кешеләр дә аз булмаган, күрәсең.

Нәтиҗәдә, Казанда акча эшләү максатында кешеләрне шикаять язуга этәрү белән шөгыльләнүче ике дистә кешегә бу эшчәнлекләрен туктатырга туры килә. Россиядә исә шикаять бирүне тәртипкә салу турында Александр I нең 1806 ел 30 март Указы игълан ителә [Бикташева, с. 246–259]. «Казан шикаятьләренең» сәбәпләре ачыкланганнан соң, мондый язулар фәкать герблы кәгазьдә, текстны төзүченең һәм күчереп язучының фамилияләре күрсәтелгән очракта гына кабул ителә башлый; күрсәтелгән фактлар расланмаса, мөрәҗәгать итүчеләрне мәхкәмә җаваплылыгына тарту тәртибе кертелә.

Гомумән алганда, шикаятьләр нигезендә оештырылган ревизия тикшерүләре нәтиҗәсендә Казан губернаторлары Н.И. Кацарев (1802–1804), Ф.П. Гурьев (1814–1815), И.А. Толстой (1815–1820) (күренекле рус язучысы Л.Н. Толстойның бабасы), П.А. Нилов (1820–1822) урыннарыннан алына. Шулай итеп, Александр I идарә иткән елларда вазифаларын башкарганда вафат булган А.А. Аплечеев (1801–1802) һәм Б.А. Мансуровтан (1805–1814) кала Казан губернаторларының барысы да, Сенат тарафыннан җинаять эшләүдә гаепләнеп, кәнәфиләрен бушатырга мәҗбүр була [Бикташева, с. 229–230, 239].

Шунысы да бар: биредә хикмәт аларның хакимияттәге тәртипсезлекләргә күз йомуында яки вазифаларын вәкаләтләрен арттырып үтәүдә яки ришвәт алуда гына булмый. Император билгеләгән һәр губернатор төбәк элиталары тарафыннан «варяг» дип кабул ителә. Алар, гадәттә, губерна дворян корпорациясе җитәкчесе белән, еш кына губерна прокуроры белән уртак тел табып, килешеп эшли алмыйлар. Өязләрдә хакимият дворяннар кулында була.

Бу каршылык И.А. Толстойдан соң губернатор итеп билгеләнгән П.А. Нилов вакытында иң югары ноктасына җитә. Губернада

«хакимият параличы» күзәтелә. Губернатор эшләренә губерна дворяннары җитәкчесе аяк чала – «ике хакимият» тамыр җәя. Ике як та, бер-берсен гаепләп, башкалага шикаятьләр юллый, яклау һәм ярдәм сорый. Бу хәлдән чыгу һәм тәртип урнаштыру өчен, Александр I Казанга (чыгарма рәвешендә) генерал-губернатор билгеләргә мәҗбүр була. Бу вазифаны 1822–1823 елларда сенатор В.Е. Самойлов башкара. 1823 елны мәхкәмә җаваплылыгына тартылган Нилов урынына вице-губернатор А.Я. Жмакин (1823–1826) билгеләнә [Бикташева, с. 338–374].

### *Император университеты*

1798 елны Казанда вакытта Павел I шәһәр гимназиясе карамагына Воскресенский урамында төзелә торган иркен һәм зур губернатор йортын биргән була. 1804 елда Александр I Казанда университет ачу турында Указга кул куйгач, яңа югары уку йорты нәкъ менә шушы бинага урнашкан гимназия белән янәшә формалаша башлый [Загоскин, с. 304–317].

Ул вакытта илдә өченче булып ачылган Казан университеты Россиянең Азия өлешендә беренче югары уку йорты санала. Бу чыннан да шулай. Чөнки XIX гасыр башында Европа белән Азия арасында географик чик Идел елгасы ярлары буенча үткән. Иделнең сул як, көнчыгыш ярында урнашкан Казан каласы илнең Азия өлеше дип саналган.

Галимнәр университет тарихын берничә этапка бүлеп өйрәнә. 1804–1814 еллар – уку йортының формалашу вакыты. Студентлар саны биш дистәдән артмый, укырга кергәннәрнең әзерлек дәрәҗәләре түбән, кабул итәргә студентлар табып булмый: чөнки дворяннар яңа ук йортына шикләнеп карый, мөмкинлеге булганнары улларын башкала яки чит ил университетларына җибәрә. Ата-аналарны укытуның бушка булуы кызыктыра, ләкин университетны тәмамлагач, 6 ел гимназиядә яки училищеда мәҗбүри эшләргә кирәклек шикләндерә.

1814 елның 5 июлендә университетның рәсми ачылышыннан соң гына биредә деканатлар оеша.

Казан университетында беренче тикшерүне 1808 елның сентябрендә сенатор М.И. Донауров, 1809 елның декабрендә сенатор П.А. Обрезков, 1811 елның августында сенатор П.Я. Аршевневский уздыра [Вишленкова, с. 96–97, 188].

1819 елгы тикшерү университеттагы уку-укыту һәм финанс-хуҗалык өлкәсендәге җитешсезлекләрнең сәбәпләрен һәм биредә Пруссиядәге студентлар чуалышлары йогынтысында туган иҗтимагый хәлне ачыклау өчен уздырыла. Тикшерүче М.Л. Магницкийга попечитель, ягъни теләсә кайсы документ белән танышу хокукы бирелә. Инспектор зур хезмәт куеп, тәфсилләп дүрт томлык (5 мең бит) яхшы хисап яза. Аның чыгышын Александр I дә тыңлый. Хисапта тискәре бәяләр өстенлек итсә дә, император үзе ачкан университетны саклау һәм ныгыту чарасына керешә. 1819 елның 8 июнендә

М.Л. Магницкий кабат Казан уку-укыту округы попечителе итеп, инспектор сыйфатында, ачыкланган кимчелекләрне төзәтергә җибәрелә.

М.Л. Магницкий үзе дәресләрен тыңлаган һәм йомшак хәзерлекле дип тапкан укытучыларны эштән азат итә, укытуга гыйлемле яшь белгечләрне тартырга тырыша, финанс һәм хуҗалык эшләрен тәртипкә сала, дин сабагын укытуга игътибарны арттыра. Ул барлык укытучылар һәм студентлар өстеннән контроль урнаштырырга омтыла, моның өчен ай саен университет ректорына бер инструкция әзерләп җибәрә. Үзе күбрәк Петербургта яши. Профессор Е.А. Вишленкова фикеренчә, М.Л. Магницкий Казанда укыту системасы православие дине әхлагына нигезләнгән, әмма бер үк вакытта фәнне һәм дини тәрбияне берләштерүче рус милли университеты моделе төзергә омтылган [Вишленкова, с. 98–121].

1825 елның беренче яртысында узган ревизия нәтиҗәсендә М.Л. Магницкий эштәге җитешсезлекләре өчен мәхкәмә җаваплылыгына тартыла һәм Ревельгә сөргенгә озатыла.

Шулай итеп, Александр I идарә иткән еллар университетның формалашу вакыты булып, тарихта үз урынын ала. Бу чор аның XIX гасырның икенче чирегендә башланган үсеш чорына нигез була.

Гомумән, һәр рус императорының Казан губернасы белән үз мөнәсәбәте барлыкка килә. Ул сәяхәтләр вакытында олы кунак буларак рәсми чараларда катнашу, саубуллашканда җирле проблемаларны хәл итүгә матди яки административ ярдәм күрсәтү, губернаторлар һәм башка җитәкчеләр билгеләп идарә органнарын формалаштыру, ревизияләр үткәреп, гаеплеләрне мәхкәмә җаваплылыгына тарту һ.б. бик күп күренешләрдә чагылыш таба. Алар арасында Александр I исеме исә Казанда университет ачылу һәм 1552 елда Казанга һөҗүм вакытында һәлак булган рус сугышчыларына һәйкәл куелу белән дә тарихка кереп кала.

**Әдәбият**

*Баженов Н.* Казанская история: в 3 ч. Ч. 2. Казань: Тип. ун-та, 1847. С. 1–150.

*Бикташева А.В.* Антропология власти: казанские губернаторы первой половины XIX века. М.: Новый хронограф, 2012. 480 с.

*Вишленкова Е.А.* Казанский университет Александровской эпохи: альбом из нескольких портретов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2003. 240 с.

*Загидуллин И.К.* Празднование в России покорения Казани во второй половине XVI – начале XX в. // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. Материалы научного семинара «Казанское ханство: актуальные проблемы исследования». Казань, 5 февраля 2002 г. / редколлегия: С.Х. Алишев (науч. редактор), И.К. Загидуллин (отв. ред.), Н.С. Хамитбаева. Казань: Фэн, 2002. С. 4–71.

*Загоскин Н.П.* Спутник по Казани. Иллюстрированный указатель достопримечательностей и справочная книжка города. Казань, 2005. С. 7–836.

*Никанор, архиепископ (Каменский).* Казанский сборник. Казань: Типолитогр. ун-та, 1909. 888 с.

Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т. 26. № 20022.

Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т. 26. № 22076.

*Свердлова Д.М.* «Жители казанские...» // История Казани в документах и материалах. XIX в. Кн. 2. Население, конфессии, благотворительность / авт.-сост.: И.К. Загидуллин, Н.С. Хамитбаева, Л.М. Свердлова, Л.Ф. Байбулатова, Х.З. Багаутдинова; науч. ред. И.К. Загидуллин; отв. ред. Н.С. Хамитбаева. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. С. 13–18.

*Фәхреддин Ризаэддин.* Асар. 1 том / төзүчеләр: Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин; русча текст: Сөләйман Рахимов; фәнни мөхәррир Миркасыйм Усманов. Казан: Рухият, 2006. 360 б.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы**,*
*тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының яңа чор тарихы бүлеге мөдире*

УДК 94(47)

***Л.И. Яруллина***

# КАЗАН СӘҮДӘГӘРЕ АПАНАЕВ ДИНАСТИЯСЕ (XVIII – XX гасыр башы)

В фонде музея А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина хранится множество фотографий, относящихся к XIX – началу XX веков. Среди них есть и изображения домов и мечети Апанаевых – известной династии в истории татарского народа. В статье дается общий обзор представителям разных поколений династии Апанаевых, связанных с фотоматериалами фонда музея. Также уделено внимание происхождению фамилии «Апанаевых», роду и виду деятельности его представителей.

**Ключевые слова:** Музей А.М. Горького и Ф.И. Шаляпина, дом Апанаевых, архитектура, купец, династия Апанаевых, интеллигенция, Старо-Татарская слобода, мечеть, родословная.

There are many photographs dating back to the 19th – early 20th centuries in the A.M. Gorky and F.I. Chaliapin museum. Among them there are images of houses and a mosque  owned or built by The Apanaevs – a famous dynasty in the history of the Tatar people. This article is devoted to a general overview of representatives of different generations of the Apanaev dynasty by photographic materials from the museum fund. The reader can find some information about the origin of the «Apanaev" surname, the family and the activities of its representatives.

**Keywords:** A.M. Gorky and F.I. Chaliapin museum, Apanaev house, architecture, merchant, Apanaev dynasty, intelligentsia, Staro-Tatarskaya sloboda, mosque, genealogy.

А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее фондында XIX–XX гасырлардагы Казан шәһәре, шул исәптән тарихта билгеле бер эз калдырган Апанаев династиясенә нисбәтле йорт һәм мәчет фотосурәтләре саклана. Шуларның берсе – Иске Татар бистәсендә Юнысов мәйданының көнчыгыш өлешендә урнашкан, XIX гасырның I яртысында сәүдәгәр М.И. Юнысов төзеткән классик стильдәге кирпеч бина. 1880 еллар ахырында әлеге йортны сәүдәгәр М.А. Апанаев сатып алган.

Казан татарлары тупланып яшәгән урыннарның берсе буларак, XIX гасырда тулысынча оешып җиткән Иске Татар бистәсе рухи, мәдәни һәм икътисади тормышның үзәгенә әверелгән. Биредә тормыш кайнаган, сәүдә эшләре һәм эшмәкәрлек киң җәелгән, төрле җәмәгать оешмалары: мәктәпләр, дәваханәләр, җирле үзидарә органнары ачылган. Сәүдә үсеше өчен уңай шартлар сәүдәгәрләр катлавы барлыкка килүгә булышлык иткән. Киң сәүдә-сәнәгать эшчәнлеге җәелдерү нәтиҗәсендә, алар зур байлык туплаган, шәһәрнең иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша башлаган.

Бу чорда Апанаевлар иң танылган сәүдәгәр гаиләләренең берсе булып исәпләнә. Алар Казан тарихына атаклы хәйрияче һәм

йорт хуҗалары буларак кереп кала. Бары тик Иске Татар бистәсендә генә дә Апанаевлар 14 бина салдырган. XIX гасырда Апанаевлар үз эшчәнлекләрен киң җәелдерә: сабын кайнату һәм күн заводлары, Гостиный дворда һәм Печән базарында сәүдә рәтләре, кунакханәләр һәм фатирлары арендага бирелә торган «табышлы йортлар» ача. Карл Фукс язганча, XIX гасырның беренче унъеллыгында Казанда беренче гильдиядә нибары биш, икенче гильдиядә өч татар сәүдәгәре гаиләсе генә булган. Апанаевлар ике дәрәҗәне дә йөрткән. Апанаевлар милли мәгариф һәм мәдәният үсеше белән дә гел кызыксынып торган. Фондларын татар гаиләләрендә сакланып калган борынгы китаплар, кулъязмалар, башка реликвияләр тәшкил итәчәк Милли музей төзү турындагы тәкъдим белән дә алар чыккан. Нәкъ алар киңәше һәм ярдәме белән беренче татар «Китапханәи исламия»се, шулай ук «Шәрык клубы» китапханәсе дә даими рәвештә яңа басмалар һәм рус классикларының әсәрләре белән тулыландырылган. Илдәге сәяси вакыйлар нәтиҗәсендә хаксызга гаепләнгән Апанаевлар гаиләсенең нәсел шәҗәрәсен барлау, милләтне үстерү өчен керткән өлешен ачыклау үзенең актуальлеген хәзер дә югалтмый. Безнең әлеге мәкаләбез дә шул максатка корыла.

Апанаевлар дин һәм дини тәрбиягә, гыйлем бирү мәсьәләсенә битараф булмаганнар. Хәзерге К.Насыйри урамында урнашкан мәчет XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башында Апанаевлар кайгыртуында булган. Гыйбадәтханәдә Салих бине Сәгыйть, Фәхретдин хәзрәт, Исхак бине Сәгыйть, Сәлахетдин бине Исхак, Таҗетдин бине Бәшир кебек дәрәҗәле дин белгечләре хезмәт иткән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Апанай мәчетенең имамы вазифасын аталы-уллы Габделгаллән белән Мөхәммәткасыйм Салиховлар башкарган.

Озынча дүртпочмаклы ике катлы мәчет бинасы урамга бераз кыеклап, михраб ягы белән көньякка (кыйблага) юнәлтеп салынган. Өч ярустан торган сигез кырлы манарасы бина түбәсенең уртасыннан күтәрелә. Башта мәчет бинасы әллә ни озын булмый, фасадлары бишәр генә тәрәзәдән, мәчет эче ике бүлмәдән тора. Фәнни тикшеренү эшләре алып баручы инглиз галиме Эдуард Турнереллиның «Татар бистәсендәге мәчет» исемле литографиясендә (1840) Апанай мәчетенең шул чагындагы күренеше тасвирланган.

Мәчет янында урнашкан Апанай мәдрәсәсе шул чордагы иң зур һәм популяр конфессиональ уку йортларының берсе саналган. Монда Россия империясенең төрле почмакларыннан килгән йөзләрчә шәкерт белем ала. Мәдрәсә мөгаллимнәре дә гаять әзерлекле, тирән белемле булулары белән аерылып торганнар. Шулар арасында Ш. Мәрҗани 1832–1875 елларда мөгаллимлек иткән Исхак һәм Сәлахетдин Сәгыйтовларны, Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимовларның исемнәрен атый. 1875 елда монда 300 артык шәкерт белем ала [Мәрҗани, б. 117].

Апанаев фамилиясенең кайдан килеп чыгуы, бу нәселнең кемгә барып тоташуы турында тикшеренүчеләр тарафыннан төрле фикерләр әйтелә. Шуларның берсе буенча, 1552 елда Казан басып

алынганнан соң, татарлар төрле җирләргә таралырга мәҗбүр ителгәннәр. Булачак Апанайлар нәселенең башына да төшкән бу бәхетсезлек. Күн эшләре белән шөгыльләнүче Амат исемле татарның ике улы һәм оныгы рус патшасына хезмәт итүне кулай күргәннәр. Бу тармакның эзе XVII гасыр уртасына, ягъни Романовлар патшалык итә башлаганчыга кадәрге чорга килеп җитә.

Аматның Ханбулат исемле улы һәм оныгы Айтулла, Мишә елгасы аръягына күчеп, Лаеш волостеның Ямбулат авылына килеп урнашалар. Айтулла малае Үтәк сәүдә эшләре җәелдереп җибәрә. Ә Үтәк малае Ярмәк Казанга килеп, Татар бистәсенә – хәзерге Сафьян һәм Күнче урамнары тирәсенә урнаша. Ярмәк тиздән өйләнә, улына Апанай исеме кушалар. Шуннан әлеге нәсел башланып китә [Гарипова, б. 8].

Л.М. Свердлова версиясе буенча, бу династиягә йомышлы татар Даут Апанаев нигез салган, аның кече улы Исмәгыйль XVIII гасыр ахырында сәүдәгәрләр катлавына кергән, ә аннан соң килгән буын нәселнең горурлыгы һәм даны булып җитешкән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 128].

Шәҗәрә материаллары һәм Ш. Мәрҗани мәгълүматлары бу гаиләнең тарихи тамырларын бераз башкача сурәтли. Шәҗәрәнең якынча схемасы мондый: Исмәгыйль бине Апанай хафиз бине Ярмәк бине Үтәк бине Айтуган бине Җанбулат бине Ямаш. Җанбулат Ямашев чынлап та йомышлы татарлардан чыккан һәм Лаеш өязе Ямбулат авылыннан булган.

Апанайның туган елы төгәл генә билгеле түгел. Борынгы елъязма 1815 елгы янгында юк ителгән. Бары шунысы гына мәгълүм: Апанай инде 15 яшендә мәдрәсәне тәмамлый һәм Казанның укымышлы катламы вәкиле булып санала [Зафир, б. 28].

1715 елда Апанайның Исмәгыйль исемле улы туа. Исмәгыйль бине Апанай (1715–1794) – Лаеш өязе Ямбулат авылыннан Айтуган бине Җанбулат бине Җамаш исемле кешенең оныкларыннан. Атасы Казан шәһәрендә яшәп, «Апанай Хафиз» исеме белән танылган [Гыйззәтуллин, б. 3]. Исмәгыйль бине Апанай – йортлар хуҗасы, тире эшкәртү белән дә шөгыльләнә [Татарская энциклопедия, т. 1, б. 164].

1763 елда Екатерина II тарафыннан татарларга башка төбәкләрдә сәүдә итәргә рөхсәт бирелгәч, Исмәгыйль беренчеләрдән булып Мәскәү, Әстерхан, Түбән Новгород, Самара һәм башка шәһәрләрдә икътисади бәйләнешләр булдыра. Күн, йон һәм башка кирәк-яраклар белән сәүдә итә. Эшләре яхшы бара, нәтиҗәдә, ул Казанда иң бай кешеләрнең берсенә әверелә, үз кибетләрен ача, Кытайдан һәм Мисырдан кайткан затлы тукымалар белән сәүдә итә башлый.

Исмәгыйль хатыны Тургайшә Аитова белән уллары Йосыф, Мусаны, кызлары Миһербану һәм Бәдигыльҗамалны тәрбияләп үстергән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 128]. Уллары Муса һәм Йосыф тугач, Захаровская [Зафир, б. 28] урамында (хәзерге Каюм Насыйри урамы) сүз башында сөйләнгән бинаны – Апанаевларның

беренче йортын салдыра. Исмәгыйль бай әлеге йортны олы улы Мусага мирас итеп калдыра [Зафир, б. 29].

Исмәгыйль бине Апанай 1782 елда Казан Татар Ратушасы оешкач, Казан татарларының шәһәр башлыгы итеп сайлана [Гарипова, б. 8].

Исмәгыйль Апанаев үлгәндә (1796 елда) олы улы Мусага – 30, Йосыфка – 26 һәм Исхакка 11 яшь була. Муса һәм Йосыф – Апанайлар нәселенең иң зур ике тармагын башлап китүчеләр. 1825 елда Исхак Апанаев мещан дәрәҗәсендә була, ә аның улы Шаһиәхмәт Казан сәүдәгәрләре арасында саналмый [Свердлова, 1994, б. 53].

Муса Исмәгыйль улы Апанаев (1766–1826) – тире иләү мануфактурасында җитештерелгән күнне Кяхтада саткан беренче гильдия сәүдәгәре, почётлы гражданин. Казанда Гостиный дворда аның кибете һәм башка күчемсез милке булган. Казан мөселманнары арасында беренчеләрдән булып ул шәһәр идарә органнарына сайлана башлаган. 1788 елда судта судья, ә 1809 елда җинаятьләр палатасы утырышчысы булган. 1808 елда үзенең үлгән кызы Зөбәйдә истәлегенә Яңа Татар бистәсендә кирпечтән мәчет төзеткән [Золотые страницы купечества…, т. 1, б. 128].

Муса Апанаевның күн җитештерү «заводы» 1818 елда 5000 сумга бәяләнә. Аның мәйданы 3076 кв. сажин булып, мануфактура дүрт таш һәм агач корпустан, таштан салынган киптерү урыныннан, амбарлардан һ.б. биналардан тора.

Моннан тыш, Мусаның Иске Татар бистәсендә бер катлы агач йорты (Кабан күле буенда, Комсомольская урамы) һәм Екатерининская урамында ике катлы таш йорты була [Свердлова, 1994, б. 53].

К. Насыйри урамындагы Икенче мәхәллә мәчете Муса Апанай хисабына тотылган [Гарипова, б. 8].

Аның уллары да коммерция дөньясы үрләрен яулаган һәм беренче гильдия сәүдәгәр булган. Алар арасында:

1) Мортаза Муса улы Апанаев. Ул Екатерининская урамында антресольләре, флигеле булган бер катлы агач йортта яши. Аның үзенең күн эшкәртү мануфактурасы була. Спасс өязендәге Епанчино авылы янындагы җирләр Мортаза Муса улы биләмәләренә карый. Аның кул астында 1961 дисәтинәдән артык җир була (2148 га). Милке 16808 көмеш сумга бәяләнә. Биләмәсе елына 1142 көмеш сум табыш китерә. Монда шунысын да ассызыклау мөһим: ул чорда татар сәүдәгәрләре арасында җирбиләүчеләр сирәк була.

Матди авырлыклар аркасында, Мортаза Апанаев җирен сата, 1843 елда Мортаза үзе дә, улы Мөхәммәтшакир да мещаннар сословиесенә язылалар. 1846 елда Мөхәммәтшакир Екатерининский урамында ике катлы таш йорт сатып ала. 1857 елда Лаеш шәһәренең беренче гильдия сәүдәгәренә әйләнә [Свердлова, 1994, б. 53].

2) Хәсән Муса улы Апанаев (1801–18.07.1863) җиде ел буе (1833–1840) Казан шәһәре Ратушасы башлыгы – бөтен Казан мөселманнарының рәсми лидеры булган. Х.М. Апанаевның беренче хатыны –

морза Алкиннар нәселеннән чыккан Сахибҗәмал Габдерәшитова, ул үлгәннән соң, икенче хатыны – Бибишәгъван Мөэмин кызы Хуҗасәитова-Усманова. Сәүдәгәр гаиләсе һәм уллары Мөхәммәтҗан (1827–?), Мөхәммәтша (?–1878), Әхмәтша (5.07.1848–?) белән үзенең Захарьев урамындагы (хәзерге К. Насыйри урамы, 38 нче йорт) [Свердлова, 1994, б. 53] йортында яшәгән.

Хәсән Муса улы хәйрия эшләре өчен ике алтын медаль белән бүләкләнгән. 1830 елда Казанда ваба белән авыручылар өчен хастаханә төзелешенә шактый зур сумма акча биргән. Вабадан үлгәннәрнең гаиләләренә ярдәм иткән [Татар энциклопедиясе, 1 т., б. 164].

Аның нәсел дәвамчылары күп еллар үткәч тә шәһәрнең сәүдә элитасында исәпләнгән һәм җәмгыятьтә югары урыннар биләгән. Мәсәлән, Х.М. Апанаевның оныклары Исмәгыйль, Закир, Исхак Мөхәммәтша уллары 1905 елның 7 ноябрендә күптөрле товарлар җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче, ышанычка нигезләнгән «Апанаевлар һәм Казаковлар сәүдә-сәнәгать ширкәте»н оештырганнар. 1908 елның 1 мартында Исмәгыйль Мөхәммәтша улы үзенең абзасы Ибраһим Исхак улы белән «Ибраһим һәм Исмәгыйль Апанаевлар һәм К» Сәүдә Йортын оештырганнар һәм Пләтәндә арендага алынган сабын «заводы»нда сабын кайнату белән шөгыльләнгәннәр. Ширкәтнең устав капиталы 10000 сум тәшкил иткән.

И.М. Апанаев XX гасыр башында күп тапкырлар «Мәрҗани» мәчете попечителе итеп сайланган. Үзе шул мәхәлләдәге ике катлы кирпеч йортта (хәзерге Мәрҗани урамы, 20 нче йорт) яшәгән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 129].

3) Мөхәммәт Муса улы Апанаев (1804–1877) – икенче гильдия сәүдәгәр. Чимал һәм күн әйберләр белән сәүдә иткән. Захарьев урамындагы (хәзерге К. Насыйри урамы, 37 нче йорт) әтисеннән калган аерым йортта яшәгән. Бердәнбер улы Мөхәммәтйосыф (1833–27.12.1903) – беренче гильдия сәүдәгәр. Казанның татарлар яши торган өлешендәге иң зур кунакханә – «Апанаев мосафирханәсе» аныкы булган. Сәүдәгәр берничә тапкыр шәһәр Думасына, Апанаев мәчетенең попечителе итеп сайланган. Хатыны Бибиәсма Исхакова (1837–1908) белән уллары Габдулланы, Исхакны, Исмәгыйльне, кызлары Бибихәдичәне (1861–?) һәм Бибизөһрәне (1868–?) тәрбияләп үстергән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 129]. Алга таба Исхакка – сабын «заводы», Габдуллага – ат «заводы», өч йорт һәм 300 дисәтинә җир, ә Исмәгыйльгә печән җирләре калган [Свердлова, 1994, б. 54].

Беренче гильдия сәүдәгәр Габдулла Мөхәммәтйосыф улы Апанаев (1873–8.09.1937) 1905 елда ышанычка нигезләнгән «Апанаевлар һәм Казаковлар сәүдә-сәнәгать ширкәте»н төзүчеләрнең берсе булган (3000 сум акча керткән). Сәүдә эшенә һәвәс эшкуар иҗтимагый активлык та күрсәткән: бер үк вакытта шәһәр Думасында да, шәһәр Управасының дүрт комиссиясендә дә эшләргә өлгергән, балалар йортларының Губерна попечительлеге әгъзасы да булган.

1913 елда Г.М. Апанаев бик кызыклы инициатива белән чыккан. Фондларын татар гаиләләрендә сакланып калган борынгы китаплар, кульязмалар, башка реликвияләр тәшкил итәчәк Милли музей төзү турында тәкъдим керткән. Ул милли мәгариф һәм мәдәният үсеше белән дә һәрвакыт кызыксынып торган. Нәкъ аның киңәше һәм ярдәме белән беренче татар «Китапханәи исламия»се, шулай ук «Шәрык клубы» китапханәсе дә даими рәвештә яңа басмалар һәм рус классикларының әсәрләре белән тулыландырылган. Хәйрия эшләре белән дә шөгыльләнгән: 1916 елда сәүдәгәр Спас өязе Зүзәй авылы янындагы 40 дисәтинә җирен Казанның икенче җәмигъ мәчете файдасына тапшырган.

Габдулла Апанаев сәүдәгәр Мөхәммәтшакир Казаков кызы Зөләйхага өйләнгән. Аларның кызы Гайшә югары медицина белеме алган, мөселман Казанының иң чибәр кызы саналган. Нәкъ менә аның хөрмәтенә булачак ире, танылган әдәбиятчы Гали Рәхим (шулай ук «бай сәүдәгәр» гаиләсеннән) «Кәккүк» дигән бик матур шигырь язган. Композитор С. Габәши көйгә салган бу татар романсы безнең көннәрдә дә бик популяр. Моңлы, матур тавышлы Гайшә Апанаева алдынгы татар яшьләре үткәргән әдәби-музыкаль кичәләрнең берсендә аны тәүге мәртәбә башкарган.

Революциядән соң Габдулла Апанаевның үзенең һәм балаларының язмышы фаҗигале булган. Улы Якуб Төркиягә күчеп киткән. Кызы Гайшә, ире Гали Рәхим кулга алынганнан соң, Бакуга киткән һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим Нәҗип Хәлфингә кияүгә чыккан. Ләкин соңрак икенче ире дә «халык дошманы» дип гаепләнеп репрессияләнгән. Габдулла Апанаев СССРны ташлап китәргә җыенганда уңышсызлыкка очраган һәм 1931 елда лагерьга җибәрелгән. 1937 елда ирекә чыгу белән, яңадан хөкемгә тартылган, шул ук елның 28 сентябрендә атып үтерелгән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 130].

4) Габделкәрим Муса улы Апанаев (1813–1873/74) – беренче гильдия Казан сәүдәгәре. Ул Урта Азиядә һәм Россия ярминкәләрендә чимал һәм азык-төлек белән сату иткән. Бик юмарт хәер-сәдака өләшүче дә булган, 1863 елда Курса авылында таш мәчет салдырган.

Ул беренче гильдия Казан сәүдәгәре Гобәйдулла Мөхәммәтрәхим улы Юнысовның кызы Бәдигыльҗамалга (1813–?) өйләнгән. Гаиләсе белән Өченче Аркылы урамда (хәзерге Сафьян урамы, 5 нче йорт) яшәгән. Уллары Мөхәммәтвәли (1825–30.10.1885), Мөхәммәтзакир (17.08.1846–1912), Габдрахман (1852–1910) һәм кызы Бибизөһрә (1871–1911) булган. Бу Апанаевлар да коммерциядәге уңышлары, эчкерсез хәйрия эшләре белән танылу алган. Олы улы Мөхәммәтвәли үзенең банктагы акчасыннан (4000 сум) килгән табышны Апанай мәчете, мәдрәсәсе, имамнары файдасына васыять итеп калдырган.

Мөхәммәтзакир һәм Габдрахман сәүдә эшләрен бергә алып барганнар, 1900 елдан соң инде сәүдәгәрлек катлавына кермәгәннәр.

Мөхәммәтзакир Апанаев һәм хатыны Бибимаһруй Мостафина (1852–?) белән ике малай һәм ике кыз үстергәннәр. Аларның олысы Мөхәммәтшакир (9.06.1873–1950) уңышлы эшкуарлык эшчәнлеге белән генә түгел, җәмгыятькә файдалы эшләрдә актив катнашуы белән дә шөһрәт казанган, шәһәр Думасына сайланган, Шәһәр управасы әгъзасы булган. Энесе Мөхәммәтвәли (30.08.1889–1922) – музыкант (скрипач), драматург һәм әдәби тәрҗемәче [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 130].

Мөхәммәтвәли Мөхәммәтзакир улы Апанаев (1889–1922) Казанда туа. «Апанай» мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлый. Вәлинең балачагы гаиләдә кадерләп сакланган борынгы китаплар һәм кулъязмалар арасында үтә. Вәлинең әтисе Мөхәммәтзакир алдынгы карашлы эшмәкәр була, Европа мәдәнияте белән кызыксына, Россия матбугатын яздырып ала, мөселманнар арасында дөньяви белемнәр таралуга уңай карый. Улы Мөхәммәтвәлинең дә дөньяви белемнәргә омтылышын хуплый. Бистәдә беренчеләрдән булып, улын Р. Гуммертның шәхси музыка мәктәбенә укырга бирә. Монда ул тәҗрибәле педагог И. Русс җитәкчелегендә скрипкада уйнарга өйрәнә.

Казан университеты студенты яшьтәшләре арасында үзенең эрудициясе, рус телен яхшы белүе, искиткеч тәрбияле булуы белән танылып өлгерә. Европа модасы буенча киенгән зыялы бу егет җидти интеллектуаль бәхәсләрдә дә, әңгәмәләрдә дә актив катнаша.

Тормышта Мөхәммәтвәли Апанаев һәрчак абыйсы – уңышлы коммерсант, актив җәмәгать эшлеклесе, Шәһәр управасы әгъзасы Мөхәммәтшакирның ярдәмен тоеп яши [Салихов, б. 21].

Р. Гуммертның Казандагы шәхси музыка мәктәбен тәмамлагач, XX гасыр башында татар мәдәниятенең күренекле вәкиленә әйләнгән. Дуслары һәм [6, б. 130] фикердәшләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Рахманколов белән «Шәрык клубы» эшендә актив катнашкан. Аның оркестры белән җитәкчелек иткән, халык музыкасы турында лекцияләр укыган. Апасы Бибигайшә (1886–?) беренче татар профессиональ театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Рәхмәтуллинга (Г. Кәрам) кияүгә чыккан [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 131].

«Шәрык клубы»ның өч катлы яңа бинасы Вәлинең якын туганы Мәрьямбану Апанаева җирендә төзелә (хәзерге Татарстан урамы, 8 нче йорт) [Салихов, б. 21].

«Шәрык клубы»нда үзешчән спектакльләр куела, әдәбимузыкаль кичәләр үткәрелә, лекцияләр укыла. Алдынгы карашлы татар зыялыларын профессиональ татар әдәбияты, театры, музыкасы, сынлы сәнгате, фән проблемалары кызыксындырган. Шул ук вакытта алар халык авыз иҗатына, аеруча халык җырларына зур игътибар биргәннәр.

М.-В. Апанаев, И. Галиәкбәров һәм Г. Зәйпин белән берлектә, музыкаль коллектив оештыра. Аларның репертуарын татар халык җырларының классик үрнәкләре тәшкил итә («Ашказар», «Әллүки», «Тәфтиләү», «Җизнәкәй», «Зиләйлүк», «Салкын чишмә» һ.б.).

М.-В. Апанаевның берничә музыкаль пьеса иҗат итүе дә мәгълүм. Шулар арасында «Сөембикә» инструменталь пьесасы аеруча популяр була. М.-В. Апанаев татар музыка җыр сәнгатен үстерүгә үзеннән билгеле бер өлеш кертә. Аның татар музыка сәнгате турындагы лекцияләрен халык яратып тыңлый. Матбагалар, еш кына, М.-В. Апанаевтан рус һәм Европа классикларының әсәрләрен сыйфатлы итеп татар теленә тәрҗемә итүен сорыйлар.

Кызганычка каршы, М.-В. Апанаевның бу бәхетле чоры озак дәвам итми. Илдә зур сәяси үзгәрешләр башлангач, 1907 елда, хөкүмәткә каршы чыгышлары өчен, ул университеттан куыла. Бу авыр чорда Мөхәммәтвәлигә абыйсы Мөхәммәтшакир ярдәмгә килә. Мөхәммәтшакир аны коммерция эшенә тарта.

1914 елда Мөхәммәтвәли Сембер сәүдәгәре Шәйхетдин Бәхтиев кызына өйләнә. Коммерсант үзенең скрипкасын бервакытта да ташламый. Аларның өйләрендә скрипка моңнары яңгырый, татар мәдәнияте язмышы хакында бәхәсләр, әңгәмәләр булып тора.

М.-В. Апанаев үз гаиләсен эзәрлекләүләрне, 1921 елгы ачлыкны бик авыр кичерә, 34 яшендә авырып китә һәм вафат була [Салихов, б. 21].

Габделкәрим Муса улы Апанаевның хатыны Бәдигыльҗамал Гобәйдулла кызы, Юнысовлар токымыннан булып, иреннән аерым сәүдә эшләре алып барган. Бу – шул чор татар гаиләсе өчен уникаль күренеш була. Сәүдә эшендә аңа башта ир туганнары, соңрак, үсеп җиткәч, уллары ярдәм итә. Бәдигыльҗамалга әтисеннән мираска йорт та кала. Ул үзенең сайлау тавышын (икенче разряд буенча) башта иренә, аннан олы улы Мөхәммәтвәлигә бирә.

Бибизөһрә кияүгә чыкмый. Әтисенең үлеменнән соң, Зур Сембер урамындагы йорт мирас булып, аның исеменә күчә. Әлеге йорттан тыш, әтиләре үлгәннән соң, Мөхәммәтзакир белән икесенә елына 1000 сум табыш китерүче имение дә кала. Бибизөһрәнең вафатыннан соң, Мөхәммәтзакир имениене туганы Габдрахман белән бүлешә [Свердлова, 1994, б. 54].

Габдрахман Габделкәрим улы Апанаевның уллары Габдерәшид (22.02.1877–?) һәм Һарун Әл-Рәшид (24.03.1886–14.11.1937) революциядән соң нигезсез эзәрлекләүләргә дучар ителгәннәр, соңгысы атып үтерелгән [Камалова, б. 89].

5) Гобәйдулла Муса улы Апанаев (?–1870), икенче гильдия сәүдәгәр. Туганнары белән бергә күн эшкәртү «заводы»ның хуҗасы була. Казан өязе Курса авылы мәчетен төзүгә акча бирә. Балалары Габдессәләм белән Габдулла, әтиләре үлгәч, 1870 елда Зур Сембер урамындагы йортка хуҗа булалар [Свердлова, 1994, б. 54].

Апанаевлар нәселенең икенче канаты – II гильдияле сәүдәгәр, заманына күрә олы сабын кайнату «заводы» арендаторы, хәйрияче Йосыф Исмәгыйль улы Апанаев (1770–1825 елдан соң). Карл Фукс аның Корбан гаете уңаеннан күпсанлы сарыклар, берничә сыер һәм бер дөя чалып, итен ярлыларга һәм гарипләр-

гә таратуын язып калдырган [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 131].

Йосыф Исмәгыйль улы – Казанның иң зур сәнәгатьчеләренең берсе. Аның сабын кайнату заводында, мисал өчен, 1818 елда 3 мең пот сабын җитештерелә. Моннан тыш, өч күн җитештерү заводы да аныкы була. 1806–1809 елларда типография тота [Татарская энциклопедия, т. 1, с. 195]. Типографиядә татар телендә дини эчтәлекле китаплар һәм уку әсбаплары басыла [Даминова, б.79]. Мисал өчен, 1806 елны типографиядә 19000 данә татар әлифбасы, 3000 данә Коръәннең җидедән бер өлеше, 15000 данә аның тулы тексты, һәм 3400 данә башка әдәбият нәшер ителә [Свердлова, 1994, б. 54]. Йосыф Апанаев 1794–1800 елларда Казан шәһәр Думасы гласные, гражданлык һәм җинаять судлары утырышчысы да [Татарская энциклопедия, т. 1, с. 195].

Ул Хөсниҗамал Йосыповага өйләнгән һәм 8 бала – Сөләйман, Хөсәен, Салих, Исхак, Сахибҗәмал, Фатыйма, Зәбирә, Шәрифҗәмал – атасы булган. Улларының барысы да диярлек бик булдыклы эшкуарлар булып җитешкән, зур мал-мөлкәтләргә хуҗа булган, ләкин татар халкы тарихында аеруча якты эзне Салих (1806–1887) һәм Исхак (1815–1908) калдырган.

1) Хөсәен Йосыф улы. К. Фукс аның байлыгын ярты миллион сумга бәяли [Свердлова, 1994, б. 55]. Байның мәгърифәтчелек эшчәнлеге турында Ш. Мәрҗани язып калдырган [Даминова, б. 79].

2) Салих Йосыф улы Апанаев (1806–1887) эшчәнлеге Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» дигән атаклы китабында аерым очеркта яктыртыла. Салих хаҗиның математика, география, тарих буенча биниһая белемнәрен билгеләп, Ш. Мәрҗани болай дип яза: «Завод мәхәлләсендә Таш мәчетне төзегәндә, кыйбланы билгеләгәндә мөселманнар, барыннан да элек, бу кеше киңәшләренә һәм исәпләүләренә таяналар. Ул Ай һәм Кояш әйләнешен бик яхшы белә, бер сәгатькә кадәр төгәллек белән теге яки бу айны, көнне ачыклый...» [ Мөхәммәтшин, б. 107].

Салих Йосыф улы вафат булганнан соң, сәүдәгәр дәрәҗәсендә аның кече улы Мөхәммәтгосман гына кала, өлкән улы Мөхәммәтшакир уллары Исмәгыйль һәм Мөхәммәтфатыйх белән мещан сословиесенә күчә [Свердлова, 1994, б. 55]. Мөхәммәтшакирның оныгы Якуп Исмәгыйль улын гражданнар сугышы вакытында Колчак армиясенә алалар. Соңрак ул кызыллар ягына күчә. 1938 елда атып үтерелә. Ә 1953 елда исеме аклана [Свердлова, 1994, б. 55].

3) Исхак Йосыф улы Апанаев (1815–1908) эшен 3 нче гильдия сәүдәгәр буларак башлап җибәрә. Аннары 2 нче, 1 нче гильдиягә күчә. Аңа этисеннән Зур Мещан (Нариманов урамы) урамында, бертуган Крестовниковлар заводыннан ерак түгел урнашкан сабын кайнату заводы кала [Свердлова, 1994, б. 55]. Беренче хатыны Нәгыймә Мусинадан аның улы Габделкәрим (5.04.1840–1893) һәм кызы Бибифәхрибану туган [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 131].

Габделкәрим икенче гильдия сәүдәгәр, йон, тиреләр, сабын һәм кәгазь мануфактура белән сәүдә иткән. Шәһәрнең Болак артындагы өлешендә аның берничә табышлы йорты булган. Аның балалары:

Мөхәммәтбәдретдин Габделкәрим улы Апанаев (3.10.1867–1930/1937 елдан соң) – беренче гильдия сәүдәгәр, почетлы гражданин.

Сабын заводы, Казандагы беренче разрядлы кибет хуҗасы. Чимал, кыйммәтле тиреләр, терлек мае, йон сатып, XX гасыр башына М.Г. Апанаев искиткеч зур байлык туплаган. Сәүдәгәр И.М. Борнаев белән бергә тоткан зур сабын «заводы»нда берничә төрле сорт сабын чыгарылган.

Ул Казанның иң бай мөселманы дигән данын Юныс мәйданындагы атаклы Юныс йортын (хәзерге Тукай урамы, 67/14) бик кыйммәт бәягә сатып алуы һәм үзгәртеп коруы белән раслаган [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 131].

Бәдретдин Габделкәрим улы сабын заводын заманча үзгәртеп корырга тырышкан. Бу заводта төрле сортлардагы сабыннар эшләп чыгарылган, аларны сату өчен Зур Проломная (Бауман) урамында сәүдәгәр махсус сабын кибете тоткан.

Тихвинская урамында (Г. Тукай урамының бер өлеше) үзенең йортында, сәүдәгәр беренче разрядлы кибет тоткан. Ул биредә 1906 елда мех, йон һ.б. белән сәүдә итә. Моннан тыш, Бәдретдин Габделкәрим улының Мәскәүдә комиссион конторасы булган [Свердлова, 1994, б. 55].

Бәдретдин байлыгы белән генә түгел, ә иҗтимагый эшчәнлеге белән дә танылган. Ул Александр һөнәр училищесы һәм Казан коммерция училищесы Попечительләр советы әгъзасы, ярлы Мөселманнарга ярдәм итү җәмгыятенең Идарә рәисе булган. Шәһәр Думасында финанс, училищелар һәм мәктәпләр төзү комиссияләрендә эшләгән. Ул мәдрәсәләрдә яңача укыту яклы булган һәм Юныс мәйданындагы йортында күп тапкыр руханилар, сәүдәгәрләр, демократик интеллигенция вәкилләрен җыеп, милли белем бирүнең әһәмиятле проблемаларын тикшергән. Бу эшчәнлеге һәм җәдитчә уку йортларын, мөселман съездларын финанслаганы өчен полиция күзәтүенә эләккән. 1905 елгы октябрь вакыйгалары вакытында студентлар һәм шәкертләр хәрәкәтен җитәкләп, городовойлар һәм атлы полиция сакчыларын коралсызландырган, аннан соң баш күтәрүчеләр тарафыннан Казанның 5 нче өлешенә (Яңа һәм Иске Татар бистәләре) милиция приставы итеп билгеләнгән [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 132].

Революция җиңелгәннән соң, берничә ай сак астында утырса да, милли хәрәкәттән читләшмәгән, элеккечә аның абруйлы җитәкчеләренең берсе булып калган, шуның өчен 1917 елның октябренә кадәр күп тапкырлар суд эзәрлекләүләренә дучар ителгән. 1923 елда Төркиягә күчеп киткән, 1930 елларда шунда вафат булган [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 132].

Аның улы Әхмәтнең (1892–1942) эшләре 1917 елга кадәр яхшы бара. Әхмәт сәүдә эшенең нигезләрен атасы фирмасында өйрәнеп,

Европа илләре белән бәйләнештә торган «Братья Гольдерберг и Ко» сәүдә йортында кассир-приемщик буларак стажировка үтә. Ләкин совет дәүләтенә аның белемнәре кирәк булмый. Һәм ул, зур гаиләсен туйдыру өчен, Татпищеторг лавкасында ипи сатучы булып эшләргә мәҗбүр була. 1930 еллар ахырында Әхмәт Апанаевны кулга алалар һәм 10 елга төрмәгә утырталар. Ул 1942 елда дөнья куя. Соңрак исеме аклана [Свердлова, 1994, б. 55].

Мөхәммәтбәдретдиннең кызы Разия да, ике яшь баласын ятим калдырып, 10 елга җәзага тартыла. Истанбул портына аның балаларын каршы алырга килгән җирендә Мөхәммәтбәдретдин йөрәге ярылып үлгән [Биктимирова, б. 57].

Габдулла Габделкәрим улы Апанаев (1861–1919) – Мөхәммәтбәдретдиннең абыйсы, Печән базары мәчете имамы, танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог-җәдитче, журналист, «Азат» газетасын чыгаручы – кызыл террорның беренче корбаны [Золотые страницы купечества..., т. 1, б. 132].

Габделхәмит Исхак улы Апанаев (1885–1937) 1885 елның 15 августында Казанда туган. 1913 елда Санкт-Петербург университетының көнчыгыш телләр факультетын беренче дәрәҗәдәге диплом белән, 1916 елда Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган, Ерак Көнчыгышта «Орел» хәрби крейсерында гардемарин булып хезмәт иткән, 1920 елның августыннан Владивосток һәм Чита таможняларында эшләгән, 1923 елның сентябрендә хатыны Софья Апанаева (Радецкая) һәм улы Надир белән Казанга кайткан. Озак вакыт эш эзләгәннән соң, педагогия институтына доцент булып урнашкан, ләкин озакламый социаль яктан бозык элемент буларак эштән чыгарылган. Берничә тапкыр апелляциягә бирүе дә нәтиҗә бирмәгән. Ахыр килеп, югары юридик белемле, алты чит телдә иркен сөйләшүче кеше базарда сәүдәгәрләргә чек биреп торырга мәҗбүр булган. 1932 елда нахакка гаепләнеп, кулга алынган, өч елга лагерьга, Беломорканалга сөрелгән. Милли мәдәният музеенда аңа 1935 елның 24 июлендә бирелгән Ударник кенәгәсе саклана. Азат ителгәннән соң, контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп, кабат кулга алына. Г.И. Апанаев 1937 елның 15 сентябрендә Казанда атып үтерелә [Золотые страницы купечества…, т. 1, б. 132–133].

Апанаевлар нәселеннән булган дистәгә якын кеше Сталин терроры вакытында төрмәләргә ябылган һәм аннан чыга алмаган. Рәшәткә артына эләккән туганнарының хәлләре белән кызыксынучы һәм аларга ярдәм итәргә теләүче Апанаевларны да шундый ук язмыш көткән. Шуңа күрә алар, эзәрлекләүләргә түзә алмыйча, фамилияләрен үзгәртергә, чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр булганнар. Дистәдән артык татар бае, мәсәлән, Маньчжуриягә барып төпләнгән. Алар озак еллар Харбин шәһәрендә яшиләр. Ләкин, Кытайда Советлар Союзындагы кебек тәртипләр кертелә башлагач, Кореяга, ә аннан Япониягә күченеп китәләр [Могыйнов, б. 115].

Качак тормышының бөтен газапларын күп еллар бергә кичергән татарлар бу илләрдә дә мәхәллә булып укмашып, аралашып яшиләр. Үзләренең тырыш, булдыклы булулары аркасында тиз арада Япония эшмәкәрләре арасында танылып өлгерәләр. Бер-берсенә ярдәм күрсәтеп яшәүләре татарларның күбесенә үз йортларын төзергә, үз эшләрен ачып җибәрергә мөмкинлек бирә [Могыйнов, б. 116].

Әмма, тормышлары җайланып китсә дә, Казан татарлары туган якларын бик сагыналар. Кайберләре, сагынуга түзә алмыйча, кире кайтып та китә. Ләкин монда алар жан тынычлыгы, бәхет тапмыйлар. Чит илдә булып кайткан һәр кешедә шпион, «халык дошманы» гына күргән Сталин кешеләре аларны чәнечкеле тимерчыбык артына ябалар яисә бөтенләй юк итәләр. Исән калганнары да эшкә урнаша алмыйча, качып, яшеренеп йөрергә мәжбүр булалар һәм, михнәт чигүләргә түзә алмыйча, акрынлап үлеп бетәләр. Ә чит җирләрдә яшәп калучыларга туган нигезләренә кайту мөмкинлеге җитмеш елдан соң гына туа.

Сәяси вакыйгалар нисбәтле нахакка гаепләнеп, гомерләрен чит илләрдә үткәрергә туры килгән, ләкин татар милләте өчен заманасында күп файдалы эшләр башкарган Апанаевлар – сәүдәгәрләр, фабрикантлар, завод хуҗалары, иганәчеләр, атаклы җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре, зыялы, укымышлы шәхесләр династиясе онытылырга тиеш түгел. Бу нәселдән булган Габделхәмит Исхак улы Апанаев, Габдулла Кәрим улы Апанаев, Ибраһим Исхак улы Апанаев һ.б.ларның исемнәре, үз халкына китергән яхшылыклары киң җәмәгатьчелеккә бүген билгеле һәм татар халкы моның өчен аларга рәхмәтле.

**Әдәбият**

*Биктимирова Т.А.* Затлы Апанайлар нәселеннән: [репрессия корбаны Габдулла Апанаев тур.] // Мәгариф = Просвещение. 2012. № 10. Б. 57–58.

*Гарипова З.Г.* Апанайларның затлы нәселе: [Габдулла Апанаевның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция тур.] // Шәһри Казан. 2012. 5 июнь (№ 64). Б. 8–9.

*Гыйззәтуллин Р.* Буыннар истәлеге: «Буыннар истәлеге» дигән шәҗәрәләр күргәзмәсендә Апанаевлар нәселе турында мәгълүматлар бар // Татарстан хәбәрләре. 1994. 22 окт. Б. 3.

*Даминова Ф.К.* Ученики и потомки Шигабутдина Марджани // Шигабутдин Марджани: Наследие и современность. Сборник статей = Шиһабетдин Мәрҗани: Мирасы һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Алма-Лит, 2008. С. 76–82.

*Зафир З.* Тарихта калган диварлар, яки Апанаевлар йортына сәяхәт [Апанаевлар йорты тур. Казан] // Идел. 2011. № 10. Б. 28–30.

Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. В 2 т. Т. 1. Казань: 2001. 288 с.

*Камалова Н.* Дом Гаруна аль Рашида: [воспоминания внучки Г. Апанаева об истории дома Апанаевых (ул.Сафьян 5)] // Казань. 2013. № 5–6. С. 85–90.

*Мәрҗани Шиһабетдин.* Китабе мөстәфадел-әхбар фи әхвал Казан вә Болгар. 2 кит. 1 басма. Казан: (Типо-литогр. Императ. ун-та), 1900. 367 б.

*Могыйнов Р.Ә.* Тимер ташкынга каршы: очерклар, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 206 б.

*Салихов Р.Р.* Судьба музыканта: [О жизни и творч. татар. музыканта, лит. переводчика, писателя Вали Апанаева (Мухаметвали Мухаметзакирович Апанаев /1889–1922] // Время и деньги. 2004. 29 янв. С. 21.

*Свердлова Л.М.* Казанские купцы и чайный рынок России (конец XVIII–XIX в.): [О казанских купцах-чаеторговцах А.Я. Сайдашева, Н.А. Иванова, М. Апанаева и др.] // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2008. № 1. С. 218–223.

*Свердлова Л.М.* Апанаевы: Среди татарских купцов Казани размахом предпринимательской деятельности выделялись промышленники, торговцы и землевладельцы Апанаевы, представленные семью... // Идель. 1994. № 3–4. С. 52–55.

Татар зыялылары: тарихи портретлар: Укытучылар һәм югары сыйныф укучылары өчен мәкаләләр җыентыгы / төз. Р.М. Мөхәммәтшин; русчадан Ә.М. Камалов тәрҗ. Казан: Мәгариф, 2003. 208 с.

Татарская энциклопедия: В 6 т. Т. 1. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2002. 672 с.

***Яруллина Ләйсән Илсур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы милли музее*
*А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музейларының*
*музей предметларын саклаучысы*

УДК 398

*И.К. Фазлетдинов*

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ: ТАРИХЫ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ
## («Башкортстан татарлары фольклоры» сериясе китапларын[1] төзү тәҗрибәсеннән)

Статья посвящена выходу в свет трех книг в новой серии «Фольклор татар Башкортостана». В ней проанализирована история собирания, издания и научного изучения устного народного творчества татар данного региона; раскрыты методологические принципы создания книг, отбора фактического материала. Отмечены некоторые локальные особенности фольклора татар Башкортостана. Автор делает вывод о том, что произведения устного народного творчества татар Башкортостана, веками проживающих на данной территории, являются неотъемлемой частью общетатарского фольклора.

**Ключевые слова:** фольклор, серия, татары Башкортостана, народное творчество, история, предание, легенда, мифология, традиция.

The article is devoted to the publication of three books in the new series “Folklore of the Tatars of Bashkortostan”. It analyzes the history of collecting, publishing and scientific study of the oral folk art of the Tatars of this region; it reveals the methodological principles of creating books, selecting factual material. Some local features of the folklore of the Tatars of Bashkortostan are noted. The author concludes that the works of oral folk art of the Tatars of Bashkortostan, who have lived in this territory for centuries, are an integral part of the general Tatar folklore.

**Keywords:** folklore, series, Tatars of Bashkortostan, folk art, history, tradition, legend, mythology, tradition.

Бүген Башкортстан Республикасына караган җирләрдә яшәгән татарларның фольклор мирасы 1768 елда Россия Фәннәр академиясенең карары буенча рус тикшеренүчеләре П.С. Паллас һәм И.И. Лепехин тарафыннан оештырылган экспедицияләр вакытында теркәлә башлый. XIX йөздә С.Г Рыбаков тарафыннан тупланган йөздән артык татар һәм башкорт җыры ноталары белән бергә Петербургта басылып чыга. XIX гасыр азагында хәзерге Башкортстанның төньяк-көнбатышын үз эченә алган Уфа губернасында яшәүче татарларның телен, этнографиясен, фольклорын өйрәнү максатында Н.Ф. Катанов Уфа губернасының Бәләбәй өязенә килә һәм, Казанга кайткач, шул хакта өч фәнни хезмәт бастыра. 1914–1915 елларда М.А. Васильев

[1] Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Идел-Урал төбәге буенча сәяхәт итеп, биредә яшәүче татарлар арасында таралган алтмыштан артык әкият, легендаларны җыеп, рус теленә тәрҗемә итеп, 1924 елда аерым китап итеп бастырып чыгара. Биредә Стәрлетамак өязе, Миркәтле волосте, Толбазы авылында язып алынган «Шүрәлене ничек алдарга» дигән мифологик хикәят һәм Бәләбәй өязендә теркәлгән «Сак-сок» легендасы да урнаштырыла.

XX гасыр башыннан татар галимнәре һәм язучы-шагыйрьләре дә әлеге эшкә керешә. Биредә тарихчы һәм тел белгече Г.Н. Әхмәров хезмәтләренең, мәгърифәтче Риза Фәхретдинов җитәкчелегендәге «Шура» журналы эшчәнлегенең әһәмиятен аерым билгеләргә кирәк. Мәшһүр әдибебез Габдулла Тукай 1910 елның 15 апрелендә Казанның «Шәрык клубы»нда укылган «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә татарлар һәм башкортлар арасында таралган «Тәфтиләү», «Сак-сок», «Җизнәкәй» кебек халык җырларын анализлый, шунда ук аларның барлыкка килүе турындагы риваятьләрне дә китерә.

Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылында туып үскән бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимов 1926 елда «Безнең юл» журналында басылып чыккан «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы. Татар халык әдәбияты турында» исемле мәкаләсендә Башкортстанда яшәүче татарларның фольклорын өйрәнү эше канәгатьләнерлек дәрәҗәдә алып барылмавын күрсәтә һәм бу өлкәдә башкарыласы эшләрне санап чыга.

Югарыда атап үтелгән тикшеренүчеләр һәм бүгенге Башкортстанга караган җирләрдә туып үскән күренекле татар фольклорчылары Нигъмәт Хәким *(Кыйгы районының Еланлы авылы)* белән Нәкый Исәнбәт *(Салават районының Нәсибаш авылы)* биредә яшәүче милләттәшләренең авыз-тел иҗаты үрнәкләрен җыюга сизелерлек өлеш кертсә дә, 1960 еллар уртасына кадәр бу эш системалы рәвештә алып барылмый, фрагментар характерда гына була.

Башкортстандагы татар фольклор мирасының системалы рәвештә җыела һәм өйрәнелә башлавы 1960 еллар уртасында фәнгә килгән Риф Мөхәммәтҗанов исеме белән бәйле. Соңгы елларда күпсанлы хезмәтләр аның тормышын һәм фәнни-педагогик эшчәнлеген шәрехләүгә багышланды [Хәмид, 2014, б. 22–27; Фазлетдинов, 2009, б. 30–31; Фазлетдинов, 2019, б. 94–99].

Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы доценты Риф Мөхәммәтҗанов 1967 елдан алып 1990 еллар башына кадәр республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләрчә авылны урап чыга. Әлеге экспедицияләрдә җыелган материалларны саклау һәм өйрәнү өчен, аның тарафыннан үзе эшләгән кафедра каршында фольклор фонды оештырыла.

Биредә тупланган язмалар тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Мәсәлән, 1976–1988, 1993 елларда Казанда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» академик басмасының һәр китабында да Р.М. Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге экспедицияләр барышында Башкорт-

станда яшәүче татарлардан язып алынган халык авыз иҗаты үрнәкләре урын ала.

1973 елда Риф Мөхәммәтҗанов тарафыннан Башкортстандагы татар фольклорының төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган беренче кандидатлык диссертациясе яклана [Мухаметзянов, 1973]. «Башкортстан Ык буе татарларының йола поэзиясе» дип аталган фәнни эш күренекле башкорт фольклорчысы, филология фәннәре докторы, профессор Ә.Н. Кирәев (әдәби тәхәллүсе – Кирәй Мәргән) җитәкчелегендә башкарыла. Әлеге диссертация Башкортстан татарларының милли фольклорын биредә яшәүче башка халыкларның авызтел иҗаты белән чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә анализлаган беренче фәнни тикшеренү булып тора.

1977 елда галимнең – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе» [Мөхәммәтҗанов, 1977], 1982 елда – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия» [Мөхәммәтҗанов, 1982], 1984 елда рус телендә «Специфика татарских фольклорных жанров» [Мухаметзянов, 1989] дип аталган хезмәтләре үзе эшләгән Башкорт дәүләт университеты нәшриятында дөнья күрә. Алар бүген дә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганак булып кала. Шуны истә тотып, быел әлеге хезмәтләр һәм галимнең «Казан утлары» журналында басылып чыккан фәнни-популяр мәкаләләре Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Башкорт дәүләт университеты галимнәре тарафыннан бергә тупланып, «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты» [Мөхәммәтҗанов, 2021] дигән исем астында аерым китап итеп бастырып чыгарылды.

Галим Р.М. Мөхәммәтҗановның 1996 елдагы вакытсыз вафатыннан соң, ул башлаган эш укучысы И.К. Фазлетдинов тарафыннан дәвам иттерелә. 2005 елда ул филология фәннәре докторы, профессор Ә.М. Сөләйманов җитәкчелегендә «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идеяэстетик функцияләре [Фазлутдинов, 2005]» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларын тикшерүгә багышланган берничә күләмле фәнни хезмәт бастырып чыгара [Фазлетдинов, 2003; 2007; Башкортстан…, 2018].

Шуларның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» дип аталганы аерым әһәмияткә ия. Биредә татарлар күпчелекне тәшкил иткән, яисә укмашып яшәгән районнардан җыеп алынган 702 фольклор әсәре – 630 риваять, 23 легенда, 33 мифологик хикәят, 16 сөйләк тексты урнаштырыла. Шуларның 600дән артыгы фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә. Автор-төзүче укыткан Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы каршындагы фольклор фондында 1996–2017 еллар аралыгында тупланган материаллар томның нигезен тәшкил итә.

Соңгы елларда Башкортстан татарлары фольклорын җыю һәм фәнни өйрәнү өлкәсендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренең эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. 2017 елда алар тарафыннан Башкортстанның Стәрлебаш районына комплекслы экспедиция оештырыла. Институт директоры, филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миңнуллин билгеләвенчә, «экспедиция составында фольклорчылар, телче-диалектологлар, археография, сәнгать һәм музыка белгечләре барлыгы 15 татар авылында (Айдарәле, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Карагыш, Куганакбаш, Стәрлебаш, Турмай, Тәтер-Арслан, Өч-Әсән, Хәлекәй, Яңгырчы, Яшерган) булдылар. Экспедиция җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, фольклорчы И. Ямалтдинов һәм фәнни хезмәткәр Г. Яхшисарова тарафыннан 700 берәмлеккә якын халык авыз иҗаты үрнәкләре язып алынды» [Милли-мәдәни…, 1 нче кисәк, 2021, б. 22].

Әлеге экспедиция барышында тупланган фольклор материаллары И.И. Ямалтдинов тарафыннан системалаштырылып һәм фәнни анализ ясалып, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә ике кисәктән торган «Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабының беренче кисәгендә дөнья күрә [Ямалтдинов, 2021, б. 168–405]. Шунда ук И.К. Фазлетдиновның «Стәрлебаш районы татарлары риваятьләренең тарихи һәм мифологик нигезләре» дип аталган фәнни мәкаләсе урнаштырылып, аның кушымтасында Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары тарафыннан биредә тупланган 27 риваять һәм легенда тексты китерелә [Милли-мәдәни…, 1 нче кисәк, 2021, б. 406–435].

«Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш» китабының икенче кисәгендә «Ерак юллар кайтавазы» исеме астында Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлеге студентларының 1971 елның 1–15 июлендә Стәрлебаш районына доцент Ф.М. Хатипов җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе вакытында тупланган материаллар урын ала. Фольклор материаллары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты И.И. Ямалтдинов тарафыннан сайлап алына, системалаштырыла, аларга жанрлар буенча фәнни классификация ясала, кереш языла [Ямалтдинов, 2021, б. 252–439].

Күзәтүдән күренгәнчә, Башкортстан татарларының фольклор мирасын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү юнәлешендә соңгы 50 елда шактый зур эшләр башкарылды. Күпсанлы фәнни экспедицияләр оештырылды, йола иҗатына, әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларына махсус монографик тикшеренүләр багышланды, риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр тупланмасы аерым китап булып дөнья күрде. Башкортстан Республикасы территориясендә яшәүче татарларның халык авыз иҗаты әсәр-

ләрен җыеп бастыру, өйрәнү бүген дә көн кадагындагы мәсьәлә булып саналырга хаклы.

Аерым алганда, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның эпик, лирик һәм лиро-эпик фольклор төрләренә караган жанрларның күпчелеге (мәсәлән, әкиятләр, мәзәкләр, афористик иҗат жанрлары, бәетләр, мөнәҗәтләр, халык җырлары, балалар иҗаты) аларның төбәк үзенчәлекләре, үзәк мотивлары, персонажлары, бер үк географик һәм рухи мохиттә яшәүче төрле халыкларның эпик традицияләренең бер-берсенә йогынтысы әлегә кадәр тикшерелмәгән өлкәләр булып кала. Быел Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителә башлаган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә караган өч китап шушы мәсьәләләрне тикшерү өчен кыйммәтле фәнни чыганак булып хезмәт итәр дип уйлыйбыз [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк…, 2021].

* * *

Татар фольклорын бербөтен система буларак күзаллап, «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларны басмага әзерләгәндә, беренче чиратта, тикшеренүчеләр өчен милли фольклорыбызның локаль үзенчәлекләрен чагыштырма планда анализлау мөмкинлеген тудыру максатын куйдык. Шул ук вакытта хезмәт бүгенге катлаулы иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә татар халкының бөтенлеген саклау, аны төрле тарафларга тарткалау-бүлгәләүгә юл куймау өчен дә хезмәт итәчәк.

Китапларны төзегәндә, Башкортстан татарлары арасында таралган барлык фольклор төрләрен һәм жанрларын да колачлау максаты куелды. Чыганакларның күбесе Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондыннан алынды. Биредә әлеге уку йортының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары тарафыннан 1962 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр үткәрелгән фольклор экспедицияләре вакытында тупланган материаллар саклана. Серия китапларына кергән төньяк һәм төньяк-көнчыгыш, үзәк һәм төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнарның һәммәсенә дә шундый фәнни экспедицияләр оештырылган, аларда җыелган үрнәкләр системалаштырылган. Китапларны төзегәндә, «Татар халык иҗаты» академик басмасында, тел белгечләренең хезмәтләрендә, вакытлы матбугатта дөнья күргән фольклор үрнәкләре дә файдаланылды.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларның төзелеш структурасы уртак. Һәр китап биредәге татар авылларының тарихларын тасвирлаган риваятьләр белән ачыла. Бу – бик үзенчәлекле төркем. Чөнки алар «гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утырган кешеләр, аерым

нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә, авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Гыйләҗетдинов, 1987, б. 13]. Безнең карашка, авыл тарихларының шушы үзенчәлеге – бер үк вакытта топонимик та, тарихи да характерга ия булуы – аларны риваятьләр составындагы аерым төркем итеп карарга мөмкинлек бирә. Шуңа да алар һәр китапта башка төр риваятьләрдән аерым, районнар буенча урнаштырылып, тикшерелгән географик ареалда яшәүче татарларның тарихы, тормыш үзенчәлекләре белән укучыны алдан ук таныштыра.

Һәр китапта шуннан соң риваять, легенда, мифологик хикәят, сөйләк, әкият кебек эпик фольклор жанрлары урын ала. Алардан соң лиро-эпик фольклор үрнәкләре – бәетләр һәм мөнәҗәтләр урнаштырыла. Соңыннан бер-бер артлы халык җырлары, афористик жанрлар – мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар, ышанулар, юраулар тезелеп китә. Аннан инде тикшерелгән районнардагы йола иҗатының төрле жанрлары бирелә. Һәр җыентык балалар фольклорына караган әсәрләр белән тәмамлана. Бу Башкортстанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәгән татарларның рухи мирасын тулы һәм системалы итеп күзалларга мөмкинлек бирә.

Хезмәтнең күләме чикләнгәнлектән, бүгенге көндә инде югалган яисә югалып баручы фольклор төрләренә һәм жанрларына – теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның йола иҗатына, риваятьләргә, легендаларга, мифологик хикәятләргә, әкиятләргә, им-томнарга, ышануларга, халык җырларының аерым жанр төрләренә, мәсәлән, шәкерт, рекрут һәм солдат җырларына төзүче аеруча зур игътибар бирде. Аларның барлык текстларын да (вариантлары белән бергә) китапларга урнаштырырга тырыштык. Мәсәлән, борынгы йола фольклоры әсәрләре тулысы белән сакланмаган очракларда аларның аерым элементларын булса да бастырып чыгаруны максатка ярашлы дип таптык.

Шул ук вакытта бүген дә күпләп иҗат ителгән һәм таралган бәет, мөнәҗәт, мәзәк, сөйләк, лирик җыр, мәкаль, әйтем, табышмак кебек фольклор жанрларының кулыбызда булган барлык үрнәкләре дә хезмәткә кертелмәде. Биредә без җирле халыкның тормыш тәҗрибәсен, тарихи асылын ачкан иң характерлы берничә әсәрне бирү белән генә чикләндек.

Һәр китапта теге яки бу жанр үрнәкләре күп урнаштырылган очракта, аларга эчке тематик классификация ясалды; фольклор үрнәкләре аз булса, мондый бүленеш-классификация эшләү кирәк дип табылмады. Жанрлар эчендә классификация үткәргәндә, төзүче күренекле татар фольклорчылары Ф.И. Урманче һәм М.Х. Бакиров хезмәтләрендә китерелеп, бүгенге фольклористиканың үзәгендә торган фәнни принципларга һәм терминологиягә таянып эш итте.

Шунысын да искәртү мөһим: фольклор үрнәкләре халыкның җирле тел үзенчәлекләрен саклап тәкъдим ителде. Сериянең аерым

китапларын төзегәндә, географик принцип нигез итеп алынды. Мондый бүленеш шактый дәрәҗәдә шартлы булса да, гамәли күзлектән караганда һәм татарлар компактлы яши торган аерым бер территориядә таралган фольклор үрнәкләренә игътибарны юнәлтү җәһәтеннән, иң уңышлысы дип табылды.

Шуны да әйтик, Уфа өязендә 1718–1727, 1761–1764, 1743–1747, 1781–1782 елларда узган I–IV халык исәбен алу – ревизия материалларында ук биредә татарларның күпләп яшәве күрсәтелә [Татары..., 2020]. Әлеге документларда татар авылларының тулы исемлеге дә, аларда яшәүче милләттәшләребезнең төгәл саны да китерелә. Кулыбыздагы фольклор материалларын аерым китапларга бүлгәндә, без әлеге тарихи-статистик материалларны да истә тотарга тырыштык.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясендә әлегә өч китап дөнья күрде.

**Беренче китапка** Башкортстанның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләре кертелде [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, 2021]. Аның нигезен Аскын, Караидел, Кыйгы, Краснокама, Мәчетле, Тәтешле, Яңавыл, өлешчә Нуриман, Учалы районнарында җыелган фольклор материаллары тәшкил итте. Биредә шуны истә тотарга кирәк: Аскын, Караидел, Кыйгы, Нуриман, Мәчетле, Учалы яклары – этник яктан катнаш төбәкләр. Шуның өчен дә, «биредә төрле этник традицияләрнең тарихи закончалыкка нигезләнеп, берегеп килүе һәм бер-берсенә йогынты ясавы» [Ахметшин, 2001, с. 5] ачык сизелә. Нигезен татарлар тәшкил иткән, татарлар аеруча күпләп яшәгән авыллардан җыелган фольклор әсәрләре генә китапка кертелде.

**Икенче китапка** Башкортстанның үзәк һәм төньяк-көнбатышына караган районнарда яшәүче татарларның фольклор әсәрләре тупланды [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк…, 2021]. Болар исәбенә Бакалы, Балтач, Борай, Дүртөйле, Илеш, Чакмагыш төбәкләре карый. Бу районнар, тел ягыннан, нигездә, моноэтник – татар халкы күпчелекне тәшкил иткән районнар. Гади генә итеп әйтсәк, бу – татарның нигезе. Аларның этник бөтенлеген саклау, халык иҗаты әсәрләрен саклау һәм пропагандалау аша тарихка игътибарны көчәйтү безнең төп бурычыбыз булып тора.

**Өченче китапта** Башкортстанның көнбатышында һәм көньяк-көнбатышындагы Авыргазы, Әлшәй, Бишбүләк, Миякә, Бүздәк, Туймазы, Шаран, Ярмәкәй районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләре урын алды [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, 2021]. Бу районнар һәммәсе дә борынгы Казан ханлыгы җирләрендә урнашкан [История…, 2016, с. 225–250]. Тел җәһәтеннән караганда да, бу як татарларының сөйләше татар әдәби теле нормаларыннан бөтенләй аерылмый, диярлек [Рамазанова, 1993, б. 66]. Гомерен Башкортстан татарларының тарихын һәм тел үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлаган галим Р.Г. Сибәгатов фикеренчә, гомумән,

«Төньяк-Көнбатыш Башкортстан сөйләшләре йөз ел элек тә, ике йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә татарча яңгырашлы булган» [Сибәгатов, 2020, б. 62].

Эш барышында барлыкка килгән кайбер күзәтүләребезне дә бәян итик. Беренчедән, Идел буе татарларындагы кебек үк, Башкортстанда яшәүче татарлар репертуарында соңгы елларда язып алынган архаик дастаннар очрамый диярлек. Моны, беренчедән, ислам диненең халкыбызга иртә үтеп кереп, тәңречелеккә нигезләнгән мифологик традицияләрне кысрыклап чыгаруы белән аңлатырга мөмкин. Ә алар архаик дастаннарның нигезен тәшкил итә. Икенчедән, бу татар халкында борын-борыннан китап культурасының, язма әдәбиятның киң үсеш алуы белән дә бәйле. Нәтиҗәдә, фольклор халыкның эстетик, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган бердәнбер чыганак булудан туктый, күләмле әсәрләр язма рәвештә, әдәби кануннар буенча иҗат ителә, төрле вариантларда язып тарала башлый. Архаик дастаннардан аермалы буларак, стадиаль яктан соңгырак чор эпосы булып санала торган мәхәббәт дастаннары, аларның билгеле сюжетка корылган вариантлары, эпик җыр үрнәкләре һ.б. исә Башкортстан татарлары авызыннан шактый күп язып алынган. «Йосыф һәм Зөләйха», «Таһир һәм Зөһрә», «Ләйлә һәм Мәҗнүн» кебек фольклор һәм язма әдәбият арасында торучы китаби дастаннарның вариантлары тикшерелгән ареалда күпләп очраса да, алар, күләмнәре зур булу аркасында, әлегә китапларга кертелмәде. Киләчәктә мондый төр дастаннарга аерым җыентык багышлау күздә тотыла.

Шул ук вакытта Башкортстан татарлары репертуарында борынгы мифологик фикерләү рәвешен чагылдырган, шул чорларда бабаларыбыз аңындагы дөнья моделен ачып салган сюжет-мотивлар шактый. Мәсәлән, Аскын, Караидел, Нуриман, Илеш якларында алыплар – гадәти кешеләрдән алда яшәгән зур гәүдәле адәми затлар турындагы риваятьләр гаять күп таралган.

Башкортстанда яшәүче милләттәшләребез репертуарында, Казан татарлары фольклорыннан аермалы буларак, күршеләренең малын, җирен тартып алу өчен күчмә кабиләләр арасында барган феодаль сугышлар – карымта-барымта яулары турындагы риваятьләр дә зур урын тота. Моңа кадәр әлеге төр әсәрләр мөстәкыйль тематик төркем буларак бары тик башкорт риваятьләре составында гына аерымлана иде. Соңгы еллардагы тикшеренүләребез карымта-барымта яулары белән бәйле мотивларның башкорт фольклорында гына түгел, Башкортстан татарларының риваятьләрендә дә мөһим урын тотуын ачыклады һәм аларны мөстәкыйль тематик цикл итеп карарга мөмкинлек бирде [Фазлетдинов, 2007, б. 8–15; Фазлутдинов, 2005, с. 20]. Безнең фикеребезчә, биредә «татар халкының бер өлешенең хәзерге Башкортстан җирләрендә борын-борыннан яшәп, бу сугышларда турыдан-туры катнашкан булуы турында фикер йөртергә дә урын бар» [Башкортстан…, 2018, б. 31]. Архаик мотивларның күп очравы үзе үк татарларның бу җирләрдә гасырлар дәвамында яшәвен исбатлый.

Янә шуңа да игътибар итү кирәк: китапларга кергән материалларның зур өлеше 1962–1991 елларда, ягъни совет идеологиясе хакимлек иткән чорда язып алынган. Шуңа күрә аерым үрнәкләрдә коммунистик идеология, сыйнфый караш шаукымы, дингә һәм муллаларга карата ифрат тискәре караш та сизелеп кала. Моны аңлап кабул итү сорала. Чөнки фольклор әсәре үзен тудырган, үзе яшәгән чор чынбарлыгын чагылдырмыйча яши алмый. Шуңа күрә дә Совет чорында язып алынган әсәрләрдә мондый, бүген инде бик иске булып тоелган карашларның саклануы – табигый күренеш.

Хәзерге Башкортстан территорияләрендә борын-борыннан, әле Алтын Урда чорыннан ук һәм аннан да иртәрәк, яшәп көн күрүче татарлардан язып алынган авыз иҗаты әсәрләре татар милләтенең уртак тарихын һәм яшәү рәвешен, тел һәм этнографик үзенчәлекләрен чагылдыра. Татар халкының милли асылын саклаучы иң мөһим рухи энҗе-мәрҗәннәр алар.

**Әдәбият**

*Ахметшин Б.Г.* Горнозаводской фольклор Башкортостана и Южного Урала / Б.Г. Ахметшин; науч. ред. Р.Г. Кузеев. Уфа: Китап, 2001. 288 с.

Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М.Сөләйманов Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

*Гыйләҗетдинов С.М.* Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 5–18.

История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства: коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. 464 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүчесе Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррире И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. 440 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 2 нче кисәк / төзүчесе Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррире И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘҺСИ, 2021. 448 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төзүчеләр: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘҺСИ, 2021. 228 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Туй поэзиясе: «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. Уфа, 1977. 70 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Календарь поэзия: «Татар халык иҗаты» курсы буенча уку әсбабы. Уфа, 1982. 72 б.

*Мухаметзянов Р.М.* Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 1973. 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164

*Мухаметзянов Р.М.* Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие по спецкурсу. Уфа, 1989. 84 с.

*Рамазанова Д.Б.* Ык ага чик сызыгы булып... // Идел. 1993. № 9. Б. 58–71.

*Сибгатов Р.Г.* Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 190 б.

Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. 192 с.

*Фазлетдинов И.К.* Риваятьтә халык тарихы. Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышы: уку кулланмасы / фәнни редактор Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2003. 201 б.

*Фазлетдинов И.К.* Тарих кайтавазы – риваять. XVI–XIX гасырлардагы зур тарихи вакыйгаларның Башкортстан татарлары риваятьләрендә чагылышы: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2007. 111 б.

*Фазлетдинов И.К.* Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2019. Б. 94–99.

*Фазлетдинов И.* Юксыну // Тулпар. 2009. № 4. Б. 30–31.

*Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2005. 26 с.

*Хәмид Р.* Яшьти абый // Тулпар. 2014. № 3. Б. 22–27.

*Ямалтдинов И.И.* Башкортстанның Стәрлебаш районы татарлары заман фольклоры. Халык иҗаты үрнәкләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүчесе Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррире И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән). Б. 168–405.

*Ямалтдинов И.И.* Ерак еллар кайтавазы. Башкорт дәүләт университеты студентлары тарафыннан җыелган халык иҗаты үрнәкләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 2 нче кисәк / төзүчесе Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррире И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘҺСИ, 2021. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән). Б. 252–439.

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәре (Казан)*

УДК 398.5+82-131

***Г.Р. Хөсәенова***

# ТАТАР РОМАНИК ДАСТАННАРЫНДА КОРЪӘННӘН КИЛӘ ТОРГАН СЮЖЕТЛАР ҺӘМ ДИНИ МОТИВЛАР

В статье автор подчеркивает тесную взаимосвязь татарского эпического наследия с вековыми идеологическими взглядами народа. Выдвигая мысль о том, что татарские дастаны, а именно их романическая разновидность, глубоко пронизаны религиозными мотивами, автор стремится выявить влияние национального историко-культурного процесса в жанровые особенности эпического творчества народа; дает определение и обобщенную характеристику татарским романическим дастанам; выявляет религиозные мотивы и образы в конкретных дастанных сюжетах. Статья раскрывает содержание понятия суфизма и его роль в формировании поэтики татарского эпоса.

**Ключевые слова**: народное творчество, дастан, религия, Коран, Джабраил, хузур, суфизм, вариант.

In the article, the author emphasizes the close relationship of the Tatar epic heritage with the age-old ideological views of the people. Putting forward the idea that the Tatar dastans, particularly their romance variety, are deeply imbued with religious motives, the author seeks to reveal the influence of the national historical and cultural process on the genre features of the epic creativity of the people; gives a definition and generalized description of Tatar romanic dastans; reveals religious motives and images in specific dastan subjects. The article reveals the content of the concept of Sufism and its role in the formation of the poetics of the Tatar epic.

**Keywords:** folk art, dastan, religion, Koran, Jabrayil, khuzur, sufism, variant.

922 елда Идел Болгарында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәннән соң, татар халкының дөньяны танып белүе, әйләнә-тирә дөньяга карашы тамырдан үзгәрә. Ул чорда дөнья әдәбиятында шактый киң танылу алган Шәрык шагыйрьләренең әсәрләре татар әдәбиятының барлыкка килүе һәм үсешенә әйтеп-бетергесез зур йогынты ясый. Урта гасырларда әдәбият белән халык иҗаты тыгыз бәйләнештә була. Барлык әсәрләрдә дә диярлек дини мотивлар, Коръәннән алынган сюжетлар, образлар урын ала. Татар халкы ислам дине аша гомумкешелек рухи кыйммәтләренә төшенә.

Фольклор әсәрләрендә дини темалар урын алган әсәрләр артуның бер сәбәбе – әдәби әсәрләрнең даими рәвештә фольклорлашуында. Урта гасыр шагыйрьләренең Аллаһы Тәгаләгә генә буйсыну, гыйбадәт кылу темасына язылган шигырьләре, дини мотивлар зур урын тоткан әсәрләре, шул исәптән, дастаннар да халык арасында киң таралган була. Телдән телгә күчеп, сөйләнелеп йөри торгач, алар фольклорлаша. Халык тарафыннан актив укылган һәм төрле варианттагы кульязмалар рәвешендә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән романик дастаннар да әнә шундыйлардан.





Татар романик дастаннары кульязмалары һәм басма китапларыннан кайберләре. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Колл. 39, сакл. бер. 4896, 1861, 2811, 2016, 34 97; колл. 7, сакл. бер. 3.

Романик дастаннар – билгеле бер сюжетка нигезләнгән һәм шул ук вакытта берничә варианты булган, мәхәббәт маҗарасына корылган әсәрләр алар. «Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Шаһсанәм һәм Гариб», «Бүз егет» кебек дастанарыбыз шушы категориядәге әсәрләрдән санала.

Еш кына бу төр дастаннарның нәкъ менә «романик» дип аталуы укучыда сорау тудыра. Чынлыкта, алар галимнәр тарафыннан романик дастаннар дип тә, романтик дастаннар дип тә йөртелә. Шулай да Е.М. Мелетинский [Мелетинский, с. 141, 143, 145, 167 и др.], П.А. Гринцер [Гринцер, с. 3–44], В.М. Жирмунский [Жирмунский, с. 19, 643 и др.], С.Ю. Неклюдов [Неклюдов, с. 251–267] кебек галимнәр бу ике терминның «романик» дигәненә зуррак әһәмият бирәләр. Фольклор галиме Л.Х. Мөхәммәтҗанова да үзенең фәнни хезмәтләрендә әлеге терминны куллана [Мөхәммәтҗанова, 2014, б. 261–318 һ.б.].

Романик дастаннар көнчыгыш шагыйрьләре Кол Гали, Җами, Физули, Низами Ганҗәви, Ә. Нәваи, Мәҗлиси кебекләрнең мәшһүр поэмалары белән тыгыз бәйләнгән. Әлеге поэмаларның сюжетлары төрле милли версияләрдә киң таралыш алган. Мондый «күчмә» эчтәлекле әсәрләр Идел буе татарларына да килеп ирешкән. Биредә алар татар халкына хас булган милли үзенчәлекләрне сеңдергәннәр, әдәби-мәдәни процесска халык иҗаты стилендә кушылып киткәннәр [Мөхәммәтҗанова, Хөсәенова, б. 80].

Романик дастаннарда төп игътибар мәхәббәтне олылау һәм аның иң көчле хис булуын күрсәтүгә юнәлдерелсә дә, каһарманнарның эчке дөньясын, Аллаһы Тәгаләгә булган ышанычын һәм сөйләүче яки авторның дингә уңай мөнәсәбәттә булуын да инкяр итеп булмый. Әсәрләрдә дини терминнар һәм образларның еш кулланылуы да дастаннарның ислам дине белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә.

Әмма татар романик дастаннары бары ислам рухы белән генә сугарылган дип әйтү дөрес булмас иде. Чөнки аларда мифологик геройлар, мотивлар, ышанулар да еш очрый. Романик дастаннарның сюжетында экияти һәм дини алымнар бергә үрелеп бара. Бары тик «Йосыф

китабы» гына тулысынча дини сюжетка нигезләнүе белән аерылып тора (хәтта бу дастанда да мифологик мотивлар кулланылган урыннар бар). Әлеге сюжетка корылган Урта гасырлар төрки әдәбиятларында уннарча нәзыйрә-дастаннар, ягъни ияру яисә җавап рәвешендәге әсәрләр иҗат ителгән. Шушы барышка бәрәкәтле этәргечне XII йөз башы Идел буе Болгары шагыйре Кол Гали ясаган [Хисамов, б. 4].

Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителгәннән соң, XI гасыр урталарында әлеге җирлеккә суфичылык идеяләре үтеп керә башлый. Бу юнәлеш беренче урынга күңел (калеб) мәсәләсен чыгаруы һәм кешенең рухи сафлыгын, җан ирегән фәлсәфи нигездә аңлатуы белән үзенчәлекле. Мөселман кешесе өчен аның күңел пакьлеге асыл сыйфат буларак күрсәтелә. Болгарлар арасында суфичыл карашларны таратучылар булып Яссәви тәрикате әгъзалары торган. Әлеге тәрикатькә нигез салучы булып танылган Әбү Йосыф Хамаданиның укучысы булган Хуҗа Әхмәт Ясәви саналган.

Суфичылыкның татар поэзиясе формалашуда да роле зур була [Яхин, б. 269]. Шигърият фәлсәфи һәм суфичыл карашларны пропагандалау мәйданына әйләнә. Әлеге идеяләр мәхәббәт сюжетлы дастаннарга да йогынты ясамый калмый. Мисал өчен көнчыгыш әдәбияты аша дөньяга танылган «Ләйлә һәм Мәҗнүн» поэмасын гына алыйк.

Поэмада беренче булып Ләйлә Мәҗнүнгә гашыйк була. Аны үзенә җәлеп итү өчен ул тышкы кыяфәтен дә үзгәртә. Мәҗнүн Ләйләнең гаҗәеп чибәр кыяфәтенә игътибар итмичә кала алмый – ул да сөю утында яна башлый. Егетнең кешеләргә хас бу яратуы ныгый барган саен идеаллаша, Ләйлә озакламый аның өчен табыну объектына әверелә. Әсәр башында егет белән кызның мәхәббәтләре җаваплы, шул рәвешле, хикәят тә бәхетле тәмамланыр кебек. Тик яратудан шашкан егет кыз янына бармый, ә чүлгә чыгып китә. Гашыйклык хисе аны туры мәгънәсендә акылдан яздыра. Егет ашау-эчүдән кала, чүлдә йөргән киек хайваннар аның якын дусларына, сердәшләренә әвереләләр. Ләйләнең кешеләргә хас яратуы җавапсыз булып кала: Мәҗнүнгә гади җир кызы кирәкми, чөнки ул инде аның аңында табынырга лаеклы илаһи зат буларак формалашкан [Татар халык иҗаты. Дастаннар, б. 204]. Әлеге сюжет белән суфичылык арасында нинди элемтә бар соң? Суфи кеше үзен дөньяви ләззәтләрдән өстен тота, бөтен җанытәне белән Аллаһка бирелгән. Мәҗнүн дә җир йөзендәге барлык рәхәтлекләрдән ваз кичкән, ертылып беткән кием, чүлдә яшәү, кешеләрнең аннан мыскыллы көлүләре – ул боларның берсенә дә аңа игътибар бирми. Ул үзен тулаем Ләйләсенә багышлаган, аны ярату, аңа табыну егетнең барлык матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, мәхәббәт дастаннары арасында читтән тыш дини идеология белән сугарылган бер әсәр бар. Ул – «Йосыф китабы». Бу табигый да, чөнки әсәрнең сюжеты Тәүрат, Инҗил, Коръән китапларында урын алган. Йосыф – Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре. Ул диндар, аның өчен иң мөһиме: Аллаһы Тәгалә кушканча яшәү. Каһарманның нәкъ менә шушы сыйфатлары әсәрдә суфичылык

идеяләре булуын раслый да инде. Чөнки биредә Йосыф образы аша «камил инсан» төшенчәсе бирелгән. Әлеге төшенчә беренче тапкыр фәлсәфә галиме Ибн Гарәби (1165–1240) тарафыннан тәкъдим ителә. «Камил инсан» төшенчәсе дигәндә абсолют, бар яктан да камил булган образ күздә тотыла. Идеаль кеше образын ачып бирү өчен Ибн Гарәби беренче пәйгамбәр Адәмнән башлап соңгы пәйгамбәр – Мөхәммәдкә кадәр булган барлык пәйгамбәрләрне куллана [Юсупов, с. 221]. Әлеге традицияләр соңрак Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан», Сәйф Сараиның «Гөлстан бит төрки» әсәрләрендә дәвам иттерелә.

Билгеле булганча, Е. Бертельс борынгы фарсы суфи шагыйрьләренең әсәрләрен төп дүрт өлешкә бүлә. Шуларның дүртенчесе – дидактик өлеш. Татар романик дастаннарында урын алган суфичыл идеяләр дә әсәрдә дидактик функция башкара дип әйтә алабыз. Чөнки биредә тугрылык, көчле ихтыярга ия булу, дөньяның алдавыч ләззәтләреннән баш тарту кебек сыйфатларга өстенлек бирелә. Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ы белән Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» дастаннарының озак вакытлар дөньяви дәреслекләр сыйфатында кулланылуы да әсәрләрдә әдәп-әхлак мәсьәләләренә зур урын бирелү хакында сөйли.

Урта гасырлар татар эпик шигъриятендә Аллаһы Тәгаләне зурлау һәм аның сыйфатларын бәян итү традицион башлам буларак киң таралган була. Асылда мондый кереш укучыга иман нигезләрен өйрәтүдән кала, җәмгыятьнең киң катлауларында әсәргә уңай мөнәсәбәт тә тудырган [Яхин, б. 5].

Аллаһы Тәгаләне мактау белән башланып китү мотивы XI гасырда яшәп иҗат иткән Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» әсәреннән үк билгеле. Җитмеш өч бүлеккә – фасылга бүленгән әлеге әсәрнең беренче ике өлеше Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә, хәлифәләргә, Буграханга дан җырлаудан гыйбарәт. Алга таба әлеге традицияне башка шагыйрьләр дәвам итә.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»әсәренең башлангыч өлешенә игътибар итик:

*Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим*
*Мактаулар һәм күп шөкерләр Бердәнбергә,*
*Милке даим һәм мәңгелек бер Тәңрегә,*
*Мөлкәтендә тиңдәше юк ул Тәңрегә, –*
*Аны мәңге үлемсез дип белдек инде.*

*Аңардан соң аның дусты Мөхәммәдкә,*
*Нәбиләрнең иң олугы ул Әхмәткә,*
*Ике уклык урыны бар ул Әхмәдкә,*
*Аңа бик күп сәлам – хөрмәт булсын инде* [Кол Гали, б. 5].

Әлеге юллардан соң Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң идарә икән дүрт сәхабә-хәлифәләргә мактау әйтелә. Болар Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң килгән җитәкчеләр: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали һәм пәйгамбәрнең оныклары Хәсән белән Хөсәен. Моңа охшаш мисаллар

Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек дастаны»ында да күзәтелә. Әсәр Аллаһы Тәгаләгә мәдхия җырлау белән башланып китә. Алга таба автор Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның сәхабәләренә багышлап озын гына касыйдә яза, аңа бер мөнәҗәт өстәлеп килә.

Кол Гали әсәре тәэсирендә Йосыф сюжеты Идел буенда бик нык популярлашкан. Татар халкында әлеге сюжетка күпләгән вариантта шигъри, чәчмә, катнаш характердагы халык әсәрләре иҗат ителгәнлеге билгеле. Халыкта «Йосыф китабы» исеме белән танылган әлеге романик дастаннарга күзәтү ясау шуны күрсәтә: халык вариантларында Кол Галидәге кебек мәдхияле башлам очраклары юк диярлек. Алар, гадәттә, хикәяләү белән башланып китә. Фольклор галиме Ф. Урманчеев фикеренчә, бу традицион тотрыклы формулалар вакытлар үтү белән онытылган, төшеп калган [Урманчеев, с. 84]. Шулай ук әлеге халык иҗаты әсәрләренең күп очракта Совет чорында язып алынганлыгын да онытмаска кирәк. Атеизм хөкем сөргән чорда дини моментлар махсус төшереп калдырылган дип уйларга да нигез бар.

Татар романик дастаннарында геройларның еш кына Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап дога кылулары күзәтелә. Әлеге күренешкә мисал итеп, охшаш сюжетка корылган «Таһир белән Зөһрә», «Шаһсәнәм белән Гариб», Кузы Көрпәч белән Баянсылу» әсәрләрен китерергә мөмкин. Биредә каһарманнар – диндар, бәла-каза килгәндә яки нинди дә булса эшнең чынга ашуын теләгәндә, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәләр. Кайвакыт догага җавап буларак, Хозыр образы җибәрелә. Ул халыкта «дөрес юл күрсәтүче», «ярдәмче» буларак билгеле. Хызыр – яшел дигәнне аңлата. Ул күренү белән табигатьтә бөтен нәрсә яшәрә башлый. Алтын Урда чоры әдибе Рабгузи язуынча, Хызыр белән Ильяс пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәңгелеккә җирдә калдырылганнар, мәңгелек суын эчкәннәр һәм җирдә мәңге яшәячәкләр. Татар фольклорында бу икәү бер пәйгамбәр буларак күзаллана һәм аны һәркем очрата ала [Садыйкова, Хәйретдинова, б. 40].

Хозыр Ильяс (Хозыр галәйһиссәлам) турында ислам динендә берничә фикер яшәп килә. Бер төркем галимнәр аны пәйгамбәр дип санаса, икенчеләре зур гыйлемгә ия булган хикмәт иясе дип исәплиләр. Ләкин бу фикерләрне Хозырның авыр хәлдә калган кешеләргә ярдәм итеп йөрүе берләштереп тора. Татар дастаннарында да бу зат нәкъ шушы функцияне үти. Гади кешеләрдән аермалы буларак, аңа алдан күрүчәнлек хас. Әйтик, экияти-мифологик сюжетка корылган «Түләк» дастанында әсәрнең башында ук төп геройга үлем куркынычы яный – башка хезмәтче егетләр аны патшадан нык көнләү сәбәпле, башта атын, соңрак үзен юк итәргә сүз куешалар. Аллаһы Тәгаләнең күндәм колы булып яшәргә күнеккән, пакь күңелле Түләк иптәшләренең хыянәтләре хакында белми. Тик егеткә аларның золымнары тими кала, чөнки йокларга яткач, Түләкне бәла сагалап торуын хәбәр иткән төш керә.

Ләкин «Таһир белән Зөһрә»дә Хозыр төшкә генә кереп калмый, ә үзе геройга ярдәмгә килә. Ул гашыйк егеткә зинданнан котылырга,

Гөл падишалыгыннан кайтырга ярдәм итүче буларак тасвирлана. Соңрак, Хозыр Таһирны, үзенең тылсымы ярдәмендә кыз итеп киендереп, сөйгән ярын күрергә җибәрә [Яхин, б. 307].

«Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанында бу дини образ гашыйклар арасында арадашчы функциясен үти. Сахрада мәхәббәттән шашып йөргән Мәҗнүн янына көннәрдән беркөнне атка атланган карт килә. Килүенең сәбәбен сорагач, ул Ләйлә исемле гашыйк кыздан хат китерүен хәбәр итә. Мәҗнүн дә бу хатка җавап яза һәм Хозырга тапшыра. Шул рәвешле, ул бу әсәрдә гашыйкларның хәлен җиңеләйтүче образ буларак бирелә.

Татар романик дастаннарында Аллаһы Тәгалә белән кеше арасында торган тагын бер образ бар. Ул – Җәбраил фәрештә. Әлеге образ ислам динендә Аллаһы Тәгалә һәм аның пәйгамбәрләре арасында торган арадашчы буларак билгеле. «Йосыф китабы»нда да ул шушы ук вазифаны башкара. Йосыф, үзен коега ташлагач, ярдәм сорап ялвара һәм аның янына Җәбраил төшә. Бирелә ул Йосыфка пәйгамбәр булачагы хакында хәбәр итә.

Дастан ахырында Йосыф белән Зөләйханың бергә калуында Җәбраилнең дә йогынтысы зур була. Нәкъ менә ул үсмер егеткә хатынның хәйләсенә бирешмәскә, каты торырга киңәш бирә. Әгәр Йосыф сабыр гына нәфесен тыя алса, киләчәктә аларны кавышу көтәчәген вәгъдә итә [Гашыйк гариб хикәясе..., б. 34].

Чынлап та, фәрештәнең сүзләре дөрес булып чыга: күп еллардан соң Зөләйха потлардан баш тартып, бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кыла башлый.

Әлеге дастанда Йосыф үзенең барлык эш-гамәлләрендә Аллаһ әмерләренә буйсынып эш итә. Җәбраил аларны даими тапшырып тора. Пәйгамбәренең һәр адымын Хак Тәгалә һәрвакыт күз алдында тота, чөнки аның илчесе, рәсүле – үзенең гамәлләре белән дә Аллаһның хак дине булган исламның көчен күрсәтүче. Йосыфның сабырлыгы, диндарлыгы, хатын-кыз фетнәсенә бирешмәве әсәрнең бәхетле тәмамлануына сәбәп була да инде. Янәдән Җәбраил образына кайтыйк. Әлеге фәрештә мәхәббәт дастаннарында, Хозыр Ильяс кебек, адәм балаларына ярдәмче буларак бирелә. Алар икесе дә ялгызлыктан, дөньяның гаделсез кагыйдәләреннән җәфа чиккән каһарман өчен якын дуска әйләнәләр дә куялар. Алдан әйтеп үтелгәнчә, бу дини геройлар дастандагы каһарманнарның догаларына җавап буларак җибәрелгән.

Язылганнардан күренгәнчә, романик дастаннарның геройлары гаделсезлеккә яки явыз рухларга каршы торганда бөек Аллаһка таяналар. Димәк, татар романик дастаннары егет белән кыз мәхәббәтен генә сурәтләп калмый, ә әсәрләрдәге геройларның Аллаһы Тәгалә белән тыгыз мөнәсәбәттә булуын да күрсәтә.

Мәхәббәт тарихын бәян иткән романик дастаннар арасында мөселманнарның изге китабы Коръәнгә таянып иҗат ителгән сюжетлар, дини персонажларга бай булган әсәрләр бихисап. Ислам тарихында зур урын тоткан Сөләйман, Якуп, Йосыф, Мөхәммәд, Гайсә, Юныс

кебек пәйгамбәрләрнең бу дастаннарда зурлап искә алынулары да халыкның пәйгамбәрләр тарихын ни дәрәҗәдә яхшы белүен һәм аларга булган хөрмәтен күрсәтә.

XII гасырда үтеп кергән суфичылык идеяләре әдәбиятка, халык иҗаты әсәрләренә бик зур йогынты ясаган. Суфи шагыйрьләр бер Аллаһка гына гашыйклыкны һәм аңа хезмәт итүне өстен күргәнннәр, шул сәбәпле аларның әсәрләре дә суфичыл карашларны, аскетизмны ныграк яктырткannaр.

Әлеге мәкаләдә татар романик дастаннарының ислам дине белән бәйләнеше фәкать өлешчә генә яктыртылды. Биредә әйтеп үтелгән дини мотивларга тагын да күбрәк мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Болардан тыш, мондый төр дастаннарда «язмыш», «Кыямәт көне», «җәннәт һәм җәһәннәм» төшенчәләренә дә зур урын бирелгән. Бу мәсьәләләр аерым өйрәнүне сорый.

Халкыбызның мәхәббәт сюжетына нигезләнгән дастаннарының язма вариантлары бүгенге көндә дә табылып тора. Димәк, әсәрләрне фәнни яктан тагын да киңрәк тикшерү ихтыяҗы туа. Шулай ук алга таба романик дастаннарны героик эпостагы дини мотивлар белән дә чагыштырып өйрәнү – мөһим бурычларның берсе.

**Әдәбият**


Гашыйк гариб хикәясе вә Таһир илә Зөһрә хикәясе вә Фәрһад илә Ширин хикәясе... Төркия, 1303 һ./1886 м. 48 б.

*Гринцер П.А.* Две эпохи романа (вводная статья) // Генезис романа в литературах Азии и Африки. Национальные истоки жанра. М.: Наука, 1980. С. 3–14.

*Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974.728 с.

*Кол Гали*. Кыйссаи Йосыф: Поэма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 221 б.

*Мелетинский Е.М.* Введение в историческую поэтику эпоса и романа. М.: Наука, 1986. 320 с.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Хөсәенова Г.Р.* Татар эпосында романик төр дастаннар // Фәнни Татарстан. 2017. № 4. Б. 79–84.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарской эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2014. 380 с.

*Неклюдов С.Ю.* От эпоса к роману// Неклюдов С.Ю. Героический эпос монгольских народов. М.: Наука, 1984. С. 251–267.

*Садыйкова А.Х., Хәйретдинова Р.Р.* XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор: дәреслек. Казан: КФУ, 2016. 384б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

*Урманче Ф.И.* Тюркский героический эпос. Казань: ИЯЛИ, 2015. 448 с.

*Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

*Юсупов А.Ф., Юсупова Н.Ф.* Суфизм в Средневековой татарской культуре: роль, особенности и модели мира // Филологические науки. Вопросы теории и практики Тамбов: Грамота, 2012. № 5 (16). С. 219–222.

*Яхин Ф.З.* Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Икенче басма. Казан: Раннур, 2003. 416 б.



***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*

УДК 371.214.41=512.145

*М.М. Шәкүрова,*
*Л.М. Гыйниятуллина*

# 1940–1970 ЕЛЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ МЕТОДИКАСЫНЫҢ ТОРЫШЫ
## (М.Ш. Галләмова, В.Н. Хангилдин эшчәнлеге мисалында)

Данная статья посвящена исследованию научного наследия по методике преподавания татарского языка в 1940–1970 гг. Особое место в методике преподавания татарского языка в школе этого периода занимают работы М.Ш. Галлямовой, В.Н. Хангильдина. В статье рассматриваются структура и содержание учебников татарского языка М.Ш. Галлямовой, В.Н. Хангильдина в историко-методическом плане.

**Ключевые слова**: научно-методическое наследие, преподавание татарского языка, структура и содержание учебников, М.Ш. Галлямова, В.Н. Хангильдин.

This article is devoted to the study of the scientific heritage according to the methodology of teaching the Tatar language in 1941–1970. This period is characterized by an active search for new theoretically grounded methods, techniques and forms of teaching the Tatar language in public educational organizations. A special place in the methodology of teaching the Tatar language at school of this period is occupied by the works of M.Sh. Gallyamova, V.N. Hangildin. The article reviews the structure and content of the Tatar language textbooks by M.Sh. Gallyamova, V.N. Khangildin in historical and methodological terms.

Keywords: scientific and methodological heritage, teaching of the Tatar language, structure and content of textbooks, M.Sh. Gallyamova, V.N. Hangildin.

Методика тарихын, аның тамырларының кая барып тоташуын, шул чорда танылган татар методистларын, аларның хезмәтләрен белү, телгә өйрәтүнең максат-бурычларын ачыклау, нинди уку-укыту ысулларын куллануларын өйрәнү дә зарур. Татар телен укыту методикасы тарихының үсеш этапларын, нигездә, алты чорга бүлеп карыйбыз: татар телен укыту методикасының нигезе салынган чор, татар телен укыту методикасының яңа юлларын эзләү чоры, методиканың чәчәк аткан чоры, укыту методикасының торгынлык чоры һ.б.

1940–1970 елларда методика фәне зур үсеш кичермәсә дә, татар телен укытудагы яңалыкларны һәм махсус хезмәтләрне барларга кирәк (М.Ш. Галләмованың «Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү» (1944), «Татар теле. Грамматика, дөрес язу һәм сөйләм телен үстерү. Башлангыч мәктәпнең 1 нче классы өчен дәреслек» (1946), В.Н. Хангилдинның «Татар теле грамматикасы» (1959), Б.М. Мифтаховның «Татар теле синтаксисын укыту методикасы» (1968) һ.б).

Бу чорда татар халкының күренекле методисты, танылган педагог **Мәрьям Шакир кызы Галләмованың** методик мирасы гаять

киңкырлы: «Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү» (1944), «Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. Педучилищелар өчен дәреслек һәм башлангыч мәктәп балалары өчен кулланма» (1945); «Татар теле. Грамматика, дөрес язу һәм сөйләм телен үстерү. Башлангыч мәктәпнең 1 нче классы өчен дәреслек» (1946); «Татар теле: Грамматика, дөрес язу, сөйләү телен үстерү. 4 нче класс өчен дәреслек» (1969) (И.И. Исламова, М.Г. Каюмова белән берлектә һ.б.).

М.Ш. Галләмова авыр тормыш юлын уза. 1919–1920 елларда «сәнәкчеләр фетнәсеннән очраклы гына исән калган» укытучы ул [Бакиров, 1977, 59]. Методист-укытучының намуслы, тырыш һәм нәтиҗәле хезмәт юлы шул чорның яшь мөгаллимнәре өчен үрнәк булып тора [Әхмәтгалиева, 1973, 10]. Ул «Совет мәктәбе» журналында укытучыларның сорауларына җаваплар урнаштыра, грамматика һәм дөрес язу кагыйдәләре буенча дәрес үрнәкләре бирә, татар телен укытуга караган мәкаләләрен бастырып чыгара.

1940 елда «Совет мәктәбе» журналында М.Ш. Галләмованың «Грамматика буенча дәрес типлары һәм дәрес төзелеше» дигән мәкаләсе чыга. Бу мәкаләнең башлам өлешендә үк автор мәктәптә һәр укучыны үз туган теленең кагыйдәләрен аңлап кулланырга өйрәтүне төп бурычларның берсе дип саный. Ул, дәрескә куелган максаттан чыгып, грамматика дәресләрен өч төргә бүлә:

1) яңа материалны аңлату дәресе;

2) күнегү дәресе;

3) укучыларның үзләштерүләрен сынау дәресе [Галләмова, 1940, б. 31].

Методист яңа материалны аңлатканда, түбәндәгеләргә игътибар итә: 1) яңа материалны үткәннәре белән бәйләп кабатлауга; 2) балаларга максатны хәбәр итүгә; 3) алдан хәзерләп килгән мисалларга нигезләп аңлатуга һәм нәтиҗә ясауга (нәтиҗә чыгару авыр булганда, укытучыга кагыйдәне турыдан-туры үзенә әйтергә тәкъдим итә). М.Ш. Галләмова грамматика дәресләрендә, нигездә, укытучының сөйләп аңлатуын күздә тота.

Әлбәттә, укытучы барлык темаларны да үзе сөйләп аңлатса, укучыга эзләнергә, иҗади фикерләргә урын калмый. 1950–1970 еллар аралыгында тел дәресләрендә иҗади характердагы ысулларга игътибар тагын да көчәя. 1970 еллар уртасында М.Н. Скаткин, И.Я Лернер тарафыннан биш ысул тәкъдим ителә: репродуктив, аңлату-күрсәтү, проблемалы укыту, өлешчә эзләнү, тикшеренү [Скаткин, 1975, с. 67]. Әлеге гомумдидактик характердагы ысуллар белән төрле фәннәрне өйрәтеп була. Шул уңайдан бүгенге көндә дә татар мәктәпләрендә тел өйрәтү, нигездә, шушы ысуллар ярдәмендә башкарыла. Биш ысулның икесе, ягъни репродуктив, аңлату-күрсәтү ысуллары материалны турыдан-туры әзер килеш бирүгә (хәбәр итү төсендә аңлату, күрсәтмәле аңлатуга) корылган, ә калган өчесе – проблемалы укыту, өлешчә эзләнү, тикшеренү методлары укучыга иҗади эшләргә,

эзләнергә тулы мөмкинлек бирә торган, кагыйдәләрне үзләре чыгара торган ысуллар буларак карала.

М.Ш. Галләмованың «Укучыларның грамоталылыкларын күтәрү өчен язу күнегүләре системасы» дип аталган мәкаләсе баланы дөрес итеп язарга өйрәтүгә багышланган язу төрләрен үз эченә ала, һәрберсенә аңлатма бирә һәм үткәрелү тәртипләрен сөйли: төрле формадагы күчереп яздыру, аңлатмалы диктант, яттан язу, изложение, сочинение, контроль диктант һ.б. «Язу күнегүләр системасы дигәндә, – ди М.Ш. Галләмова, – язу эшләренең төрләрен, аларның эзлеклелеген, күләмен-үлчәвен һәм өйрәнелә торган кагыйдәгә җавап бирерлек булуын аңларга тиешбез» [Галләмова, 1940, б. 39]. Методист әлеге мәкаләдә дә укытучының сөйләп аңлатуын күз уңында тота.

М.Ш. Галләмованың «Ике яки бер коплектлы мәктәпләрдә ана теленнән укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру алымнары» исемле мәкаләсе яшь укытучылар өчен кирәкле чыганак булып тора. Авыл җирләрендә, балалар саны аз булганга, укытучыларга берүк вакытта ике сыйныф белән эшләргә туры килә. Методист, ана теленнән укучыларның мөстәкыйль эшләрен дөрес оештырып, укытучыга программа материалын үтәргә тулы мөмкинлек бирә. «Мөстәкыйль эшне дөрес оештыруның белем-тәрбия бирү ягыннан да әһәмияте зур», ди автор [Галләмова, 1949, б. 40].

М.Ш. Галләмова ана теленнән уздырыла торган мөстәкыйль эшләрне өч төркемгә бүлеп тикшерә.

1. Тел дәреслекләреннән яки тактадан төрле текстларны күчереп язу. Бу төр эш текстны сүзгә-сүз күчерү рәвешен генә алмыйча, һәр класста укучыларның яшь һәм белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле биремнәр белән катлауландырылырга тиеш.

2. Төрле формадагы грамматик тикшерү, күнегү эшләрен 1 нче сыйныфтан ук башлап бирә башларга кирәк (1 нче сыйныфта – аерым сүзләрне, җөмләләрне сайлап күчерү, кисмә хәрефләрдән сүзләр төзү; 2 нче сыйныфта предметны, билгене, эш һәм хәрәкәтне белдерә торган сүзләрне аерып алып, сорау кую, җөмләләр төзү; 3 нче сыйныфта сүзләрне кисәкләргә аерып язу: *эшче – эш = тамыр, -че = кушымча;* 4 сыйныфта схема буенча җөмләне тулы грамматик тикшерү: *Фәрит язгы имтиханга яхшы хәзерләнде*: *Фәрит* – (кем?) – ия, исем, баш килештә, берлектә һ.б.) [Галләмова, 1949, б. 42].

3. Хәтердә калганча язу күнегүләре.

Бу төр күнегүләрне системалы рәвештә үткәргәндә, укучы теоретик материалны истә тизрәк калдыра, грамоталы итеп язарга өйрәнә.

1944 елда М.Ш. Галләмованың «Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү» дигән китабы нәшер ителә. 1944–1945 елда чыккан башлангыч мәктәптә татар телен укыту программаларында «Сөйләү һәм язу телен үстерү» аерым бер бүлек итеп тәкъдим ителә. Шуңа күрә мәктәптә укучыларның сөйләм культурасын үстерү иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Методист фикеренчә,

укучылар башлангыч мәктәптә үк яхшы уку һәм яхшы сөйләү күнекмәләре алырга тиешләр [Галләмова, 1944, б. 3].

Хезмәтнең беренче бүлегендә автор укучыларның сөйләменә түбәндәге таләпләрне куя: укучының сөйләме дөрес, анык, ачык һәм шул ук вакытта бәйләнешле булырга тиеш; укучының сөйләме чиста булырга, ягъни ул төрле вульгаризм, урам сүзләрен кулланмаска тиеш; сөйләмдәге авазлар әйтелеше дә дөрес, аңлаешлы булырга тиеш; сөйләм үстерү грамматика, уку, язу дәресләре белән бәйләнештә, ныклы бер план буенча эзлекле рәвештә алып барылырга тиеш һ.б. Боларны тормышка ашыру өчен, М.Ш. Галләмова түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

1. Күрсәтелгән таләпләргә тел буенча алып барыла торган барлык шөгыльләрнең бердәмлеге аша ирешү, чөнки татар теле буенча үткәрелә торган һәр дәрес, эчтәлеге нинди булуга карамастан, сөйләм культурасы белән эшләү мөмкинлекләре бирә.

2. Планлы һәм эзлекле рәвештә татар теленнән үткәрелә торган дәресләр арасына укучының сүзлеге белән эшләү, изложение, сочинение, укыганны сөйләү буенча эшләү дәресләрен дә кертергә кирәк.

3. Нинди генә дәрес булмасын, укытучы укучының сөйләменә игътибар итәргә тиеш (ялгыш тәгъбирләрне төзәтергә, урынсыз сүзләрне алыштырырга һ.б.)

4. Укытучының сөйләме балаларга үрнәк булып торырга тиеш.

5. Балаларның сөйләм телен үстерүдә ярдәм итә торган сыйныфтан тыш чаралар үткәрү (күмәк уку, укыганны хикәяләү, радио тыңлау һ.б.) зарур.

6. Мәктәп эчендәге плакат, белдерүләрнең стилистик грамоталы язылуларын истә тотарга [Галләмова, 1944, б. 6] кирәк.

М.Ш. Галләмованың «Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү» исемле хезмәтендә сөйләмә тел һәм язма сөйләм, аларның аермалары һәм бәйләнешләре, сүзлекләр һәм фразеология белән эшләү юллары күрсәтелгән. Бу төр эшләрне бүген дә тел, бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләрендә иркен кулланып була.

Автор балаларның «ирекле сөйләүләр»ен укучыларның бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү эшендә беренче баскыч дип атый. Ул укучыларда бәйләнешле сөйләм күнекмәләре тудыруда ярдәм итәрдәй түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итә: план белән эшләү, формасызландырылган текст белән эшләү, үзеңчә сөйләү һәм язма изложение, сөйләмә һәм язма сочинение, күңелдән ятлау, укытучының хикәяләве, эш сөйләме белән эшләү [Галләмова, 1944, б. 39].

М.Ш. Галләмова 1946 елда «Татар теле. Грамматика, дөрес язу һәм сөйләм телен үстерү. Башлангыч мәктәпнең 1 нче классы өчен дәреслек»тә текстлар сайлауга зур урын бирә: өзекләрдә батыр сугышчылар, аларга дан җырлау, туган илне саклау, ел фасыллары, табигать, кошлар, җәнлекләр һ.б. турында сүз бара. И.И. Исламова, М.Г. Каюмова белән берлектә төзегән «Татар теле: Грамматика, дөрес язу, сөйләү телен үстерү. 4 нче класс өчен дәреслек»кә килгәндә,

биредә алынган өзекләрнең авторлары да күрсәтелгән (Г. Тукай, Ф. Кәрим, Х. Вахит, Җ. Тәрҗеманов һ.б.). Әлеге текстлар, табышмаклар, мәкальләр, иҗади характердагы күнегү-биремнәр – барысы да аңлап уку-язуны, грамматик материал белән сөйләм эшчәнлегенең берлегенә ирешүне күздә тотып язылганнар.

Октябрь революциясеннән соң башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен программалар, дәреслекләр төзүдә **Вәли Нигъмәт улы Хангилдин** да катнаша: «Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен (Грамматика һәм дөрес язу)» (1934), «Татар теленең грамматикасы һәм орфографиясе» (1934, 1935), «Татар теле: 1–2 нче класслар өчен грамматика» (1935; 1936; 1937) (Гыйбадулла Алпаров белән берлектә); «Грамматика һәм орфография дәреслеге» (1938) (Х. Шабанов белән берлектә) һ.б.

1934 елда В.Н. Хангилдиннең «Татар теле дәреслеге» басылып чыга. Китап төгәл, бер системага салып эшләнгән. Ул ике өлештән тора: беренче елда укучылар *җөмлә, җөмләдә сүзләр бәйләнеше, исемнәрдә баш (зур) хәреф, иҗек, аваз һәм хәреф* һ.б. өйрәнәләр, икенче өлешендә *сорау һәм өндәү җөмләләр, сузык һәм тартык авазлар, җөмләдә сүзләр бәйләнеше, тагылмалар* һ.б. үзләштерәләр. Әлеге китапта кагыйдәләр рамкалар эченә алынган, рәсемнәр, схемалар, таблицалар урнаштырылган. Алынган өзекләрдә 1930 еллар турында күп материал табарга мөмкин (*Кызыл Армия юлбашчылары, эшче-крестьяннар, октябрь маршы, колхоз дошманнары* һ.б.). Дәреслекнең беренче өлешендә укучыларны дөрес язарга өйрәтү күнегүләре (язу үрнәкләре) күз уңында тора (9, 13, 19, 20, 37 биремнәр).

В.Н. Хангилдиннең (Гыйбадулла Алпаров белән берлектә) «Татар теле: 1–2 нче класслар өчен грамматика» китабында теоретик материал катлауландырылган, шартлы тамгалар белән күрсәтелгән, күнегүләр дә «җиңелдән – авырга» принцибына нигезләп корылган: 84 күнегү. (Түбәндәге мәкаләне күчереп язygыз. Аннары ияләрнең асларына бер сызык, хәбәрләрнең асларына ике сызык сызып чыгыгыз.); 98 күнегү. (Түбәндәге өземтәләрне укып чыгыгыз (авторлар зур күләмле өзек тәкъдим итәләр. – *М.Ш.)* һәм туры сөйләмнәрне билгеләгез. Күчереп язганда, туры сөйләм алдыннан нокта куегыз. Туры сөйләмне куш җәяләр эченә алыгыз.); 140 күнегү. (Күчереп языгыз һәм өтерләр куегыз.) һ.б. Алга таба барлык күнегүләр диярлек теоретик материалны гамәли яктан ныгытуга корылган. Авторлар үзләре тәкъдим иткән текстлардан тыш, Г. Тукай, Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Горький, М. Әмирдән алынган өзекләр белән дә эшлиләр.

1938 елда В.Н. Хангилдин (Х. Шабанов белән берлектә) «Грамматика һәм орфография дәреслеге»н чыгара. Бу дәреслектә «*Белешмә өчен хәрефләр – әлифба*», «*Каләмне менә болай тот*», «*Баш хәрефләр язылышын күзәтегез*», «*Үрнәктәгечә матур итеп языгыз*» кебек күнегү-биремнәр, плакатлар урнаштырылган. Текстларда патша Россиясе, 1936–1937 елларда гомуми белем мәктәпләрендә укучы бала-

ларның саны, күләме, уку йортлары, халыкның яшәү шартлары, батыр сугышчылар, 1 май, ел фасыллары турында мәгълүмат бирелгән. Мәсәлән: 4 күнегүне язганда укучылар баш хәрефләрнең язылышын күзәтергә һәм саннарның биеклеген баш хәрефләр биеклегендә язарга тиешләр: *«1936–1937 елларда гомуми белем мәктәпләрендә 27 миллион 400 мең кеше укыды. Техникумнарда 767 мең кеше укыды. 1935–1936 елда югары уку йортларында 525 мең кеше укыды. Дәүләт тарафыннан 1935 елда 8 миллиард 300 миллион сум акча тотылды. 1924 елдан алып, 1935 елга кадәр булган вакыт эчендә 23 миллион 800 мең кеше башлангыч белем алды. СССР халыкларының культура дәрәҗәләре көннән-көн үсә бара»* [Хангилдин, 1938, 5].

Теоретик материалның эчтәлегенә килгәндә, В.Н. Хангилдиннең «Грамматика һәм орфография дәреслеге»ндә авазлар һәм хәрефләр (*сузык һәм тартык авазлар, калын һәм нечкә сузыклар, сузыкларның язылышы, тартыкларның язылышы, борын авазлары),* җөмлә, хикәя җөмлә, өндәү җөмлә, сүз, көчәйткеч кисәкләр, кушма сүзләр, җөмлә төзелеше, ким җөмлә, теркәгечләр, исемнәрнең килеш белән төрләнеше һ.б. кыска, аңлаешлы итеп урнаштырылган. *Нинди булса да бер хәбәр белдергән яки ни турында булса да хикәя итә торган җөмлә* ***хикәя җөмлә*** *дип атала. Хикәя җөмләнең азагында нокта куела* (19 биттә). *Җөмләдә нәрсә турында сөйләнсә, әнә шул әйберне белдергән һәм кем, нәрсә, ни сорауларына җавап була торган сүз* ***ия*** *дип атала.* Мәсәлән*: Клубка газеталар алалар. Нәрсәләр алалар? Газеталар* (ия) (58 биттә). ***Фигыль*** *– әйбернең эшен яки хәлен аңлата торган сүз. Фигыльгә Нәрсә эшли? Ни эшли? яки Нәрсә эшләтә? Ни эшләтә? Нәрсә эшләтелә? Ни эшләтелә? дигән сораулар куярга мөмкин* һ.б. [Хангилдин, 1938, 86].

«Грамматика һәм орфография дәреслеге»нең 98 битеннән «Кушымта» башлана: «Сүз өстендә эшләү» (98–101 битләр), «Эш теле» (101–105 битләр), «Китап өстендә эшләр» (106–110 битләр) һ.б. «Сүз өстендә эшләү» бүлегендә укучылар сүзләрнең төгәл мәгънәсен ачыклыйлар: *Бер үк вакытта ура, суга һәм орлыкны сортларга аера торган машина* ***комбайн*** *дип атала. Дөрес язу кагыйдәләре* ***орфография*** *дип атала* һ.б. (159 бирем); *Китап, газета, журналларны басып чыгара торган фабрика* ***типография*** *дип атала*; *Нинди булса бәхәсле мәсьәләләрне тикшерү* ***дискуссия*** *дип атала* һ.б. (160 бирем). Хәзерге заман дәреслекләрендә, кызганычка каршы, бу төр эшләрне сирәк очратасың. Рус һәм татар телләрендә басылып чыккан контроль эшләрдә «Нәрсә ул журнал? Нәрсә ул хикәя? Китап нәрсә ул?» кебек сораулар еш очрый. Һәр сыйныфта сүзлек, китаплар белән эшләргә өйрәтсәк, бәлки балалар тел, әдәбият белән күбрәк кызыксына башларлар иде.

1940 елда В.Н. Хангилдин «Совет мәктәбе» журналында «Татар теленең синонимикасы» дигән күләмле мәкалә бастыра. Бу – татар телендә синонимнарга багышланган беренче хезмәт булу белән бергә, грамматик синонимнарны билгеләү юлында беренче омтылыш та

[Ибраһимов, 1976, 14]. Әлеге мәкаләдә автор синонимнарның телебезне баету, сөйләм матурлыгын арттырудагы әһәмиятен күрсәтә.

1954 елда В.Н. Хангилдин «Татар теле грамматикасы» дигән хезмәтен бастырып чыгара. Автор бу хезмәттә татар теленең морфологик һәм синтаксик төзелешен тирәнтен тикшерә, тюркологиянең һәм татар тел белеменең теге яки бу грамматикаларындагы мәсьәләләргә тәнкыйди бәя бирә, күп кенә проблемаларга оригиналь чишелеш тәкъдим итә, катлаулы проблемаларның чишелешен күрсәтә [Ганиев, 2001].

В.Н. Хангилдин «Татар теле грамматикасы» дигән китабының кереш өлешендә татар грамматикаларының язылу, басылу тарихына кыскача белешмә бирә. Ул татар теле грамматикасы буенча «әле аерым рәвештә һәм хаслап тагын да күбрәк тикшерүне, фикер алышуны таләп итә торган» мәсьәләләр байтак икәнлеген искәртә [Хангилдин, 1959, 23].

Галим сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтләрен тикшерә, аларны өч зур типка аера: мөстәкыйль сүз, ярдәмлек һәм ымлык сүз. Мөстәкыйль сүз дип телнең төп һәм иң эре лексик берәмлеген атый [Хангилдин, 1959, 246].

В.Н. Хангилдин синтаксисның төп берәмлекләре мәсьәләсенә туктала. Сүз тезмәсе белән җөмлә төзелмәләрендә синтаксик бәйләнеш турында мәгълүмат бирә: ияртү бәйләнеше һәм тезү бәйләнеше [Хангилдин, 1959, 305].

В.Н. Хангилдиннең «Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре» дигән хезмәте дә игътибарга лаек. Бу хезмәт ике өлештән тора: 1) әдәби тел тарихы; 2) әдәби тел практикасының бүгенге көндәге әһәмиятле мәсьәләләре. Галим фикеренчә, «тел культурасы дигән төшенчә әдәби тел нормаларын яхшырту, камилләштерү чараларын һәм шул юлдагы эшләрне үзенең эченә ала. Тел культурасына ия булу исә әдәби телнең нормаларын тулысынча өйрәнеп үзләштерүдән гыйбарәт. Бу, – билгеле, күп вакыт һәм көч таләп итә торган эш. Ләкин ансыз булмый, әдәби телнең нормаларын өйрәнү һәм дөрес үзләштерү – кешеләрнең төп культуралылык билгеләреннән берсе». Татар теле культурасының нигезләрен мәктәпләрдә һәм балалар бакчасында салырга кирәк [Хангилдин, 1976, 39].

В.Н. Хангилдин «Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре» дигән хезмәтендә язудагы ялгышларны ике төрле сәбәп аркасында килеп чыга дип саный: беренчедән, алфавит белән орфографиянең үзләрендә булган җитешсезлекләр тудырган ялгышлар; икенчедән, булган кагыйдәләрнең тиешенчә һәм төгәл үтәлмәве аркасында килеп чыккан ялгышлар [Хангилдин, 1976, 76]. Шулай итеп, автор әлеге хезмәттә татар телен куллануның үзенчәлекле якларын ачып бирә, укучыларны да язуда еш очрый торган хаталардан арынырга чакыра.

Димәк, танылган тел галиме, методист В.Н. Хангилдиннең грамматика һәм орфография, синтаксик синонимнар, сөйләм культурасын

үстерү өлкәсендәге эшчәнлеге татар телен укыту методикасының фәнни эшкәртелү дәрәҗәсен яңа бер баскычка күтәрә.

Методика тарихын, танылган татар методистларын, аларның хезмәтләрен, нинди уку-укыту ысулларын куллануларын өйрәнү, телгә өйрәтүнең максат-бурычларын ачыклау татар теле һәм методика фәненең нигезен, үзенчәлекләрен ачыкларга, үсеш баскычларын билгеләргә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Галләмова М.Ш.* Грамматика буенча дәрес типлары һәм дәрес төзелеше // Совет мәктәбе. 1940. № 1. Б. 31–33.

*Галләмова М.Ш.* Укучыларның грамоталылыкларын күтәрү өчен язу күнегүләре системасы // Совет мәктәбе. 1940. № 11–12. Б. 40–42.

*Галләмова М.Ш.* Ике яки бер комплектлы мәктәпләрдә ана теленнән укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру алымнары // Совет мәктәбе. 1949. № 1. Б. 40–41.

*Галләмова М.Ш.* Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү. Казан: Татгосиздат, 1944. 112 б.

*Гиниятуллина Л.М.* Исследование сложноподчиненных предложений с аналитической связью частей в учебниках XX века / Л.М. Гиниятуллина, М.М. Шакурова. Казань, 2018. 148 с.

*Хангилдин В., Шабанов Х.* Грамматика һәм орфография дәреслеге. I басма. Казан, 1938. 152 б.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле грамматикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 641 с.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 237 б.

*Ханбиков Я.И.* История развития педагогической мысли татарского народа. Казань: КГПИ, 1975. 160 с.

*Шакурова М.М., Юсупова З.Ф.* Татарско-русское двуязычие и его использование в обучении татарскому языку // Вестник Челябинского гос. пед. ун-та, 2017. № 7. С. 122–126

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 75

***С.В. Синцова***

# Ә. ФӘТХЕТДИНОВНЫҢ ТИРӘН ҺӘМ КҮПКЫРЛЫ СӘНГАТИ ДӨНЬЯСЫ ТУРЫНДА
## («Өмет» картинасы мисалында)

Предпринята попытка определить особенности творческой индивидуальности А. Фатхутдинова на основе выявления процессов смыслопорождения в картине «Өмет» («Надежда»). Системно-комплексный анализ позволил обнаружить сложную и во многом уникальную структуру смысловых горизонтов, имеющих скрытую философскую ориентированность, перекликающуюся с идеями экзистенциалистов (человек в разнообразных контекстах бытия). Обнаружена сложная палитра изобразительно-выразительных средств, позволяющих художнику-мыслителю воплощать свое усложненное мировидение. В заключение высказана гипотеза о перспективности герменевтического исследования наследия А. Фатхутдинова. Именно такой подход позволит наиболее полно раскрыть наиболее характерные черты этой творческой личности.

**Ключевые слова:** герменевтика, скульптура, живопись, татарский фольклор, орнамент, резьба по дереву, татарский костюм.

An attempt is made to determine the peculiarities of A. Fatkhutdinov’s creative individuality on the basis of identifying the processes of generating meaning in the painting “Omet”. The system-integrated analysis made it possible to discover a complex and unique structure of semantic horizons with a hidden philosophical orientation that echoes the ideas of existentialists (a person in various contexts of being). A complex palette of pictorial and expressive means has been discovered that allow the artist-thinker to embody his complicated worldview. In conclusion, a hypothesis is put forward about the perspective of the hermeneutic study of A. Fatkhutdinov’s legacy. It is this approach that will most fully reveal the most characteristic features of this creative personality.

**Keywords:** hermeneutics, sculpture, painting, Tatar folklore, ornament, woodcarving, Tatar costume.

Әхсән Фәтхетдиновның әсәрләре һәрвакыт тамашачыны җәлеп итә. Әмма алар шул ук вакытта фәнни анализ өчен бик катлаулы. Беренче карашка, алар гади генә булып, бу ялганчы күренешне еш кына эшкәртелеп бетмәгән кебек тоелган агач кисәкләре тудыра. Иске, ярылып беткән мондый агачларны тормыш-көнкүрештә мичкә генә ягарлар иде, мөгаен. Ә рәссам аларның кайрысын чистартып, бераз төзәткәләгән дә сыннар, паннолар, картиналарына сәер агач рамнар ясау өчен файдаланган. Аның нәкыше скульптураны хәтерләтә: купшы түгел, әле күптән түгел модада булган примитив манерада. Әсәрләрнең тематикасы да новаторлыгы һәм нәфислеге белән шаккатырмый: ияләр, мәҗүси тәңре образлары, Библия мотивлары (Адәм һәм Хава, аяк-кулларны кадаклау өчен трансформацияләнгән тәре),

авыл тормышы детальләре һәм күренешләре. Төссез палитра гадилек, табигыйлекне, артык таләпчән булмау хисен көчәйтә генә. Буяулар картиналарны рамлап торган агачның төсләрен һәм фактурасын кабатлый. Сәнгать белгечләре кат-кат билгеләп үткән кызыклы эффект барлыкка килә: тәрәзәдән авыл кешесе игътибар белән нәрсәнедер күзәтә яисә күз кырые белән генә күреп кала, көтмәгәндә очраклы рәвештә күрә.

Бу эшләрне анализларга керешкән сәнгать белгеченә бәйләнергә урын да юк кебек. Нәкыш манерасы буенча дөньякүләм сәнгать агымнары һәм юнәлешләре контекстында барысы да таныш һәм икенчел: «соңарган модернизм» (Татарстан нәкышенең бу үзенчәлеген Й.Г. Нигъмәтуллина әнә шулай билгеләде) [Нигматуллина, 2002], соц-арт (Р.Р. Солтанова) [Султанова, 2001]. Тематикада да яңалык юк: табигать, көнкүрештәге образлар һәм сюжетлар, мәҗүси мотивлар (өй иясе, Тәңре, урман, су, тыкрык һ.б. ияләре), татар орнаментикасы элементлары.

Сәнгать тенденцияләре контекстында бары тик ияләрнең кешеләштерелгән образларыннан торган «Ияләр» циклы гына гадәти түгел.

Ә. Фәтхетдинов эшләреннән төзелгән альбомга (2002) кереш сүз буларак язылган мәкаләсендә Р.Г. Шаһиева ияләргә аеруча зур игътибар бирә. Рәссам һәм скульптор иҗатының төп үзенчәлекләреннән: гомуми эмоциональ тон буларак «якты сагыш», гомумкешелек планы, фәйләсүфлеккә тартылу билгеләнә, образларның милли колориты ассызыклана.

Ә. Фәтхетдинов иҗаты мондый традицион фәнни алымнар яктылыгында аеруча үзенчәлекле, күренекле булып тоелмый, ул «Татарстан Республикасының яңа шәһәрләре рәссамнары» (Р.Р. Солтанова) иҗади эзләнүләре контекстына туры килгән (кызыклы гына табышлары да булган) маргиналь рәссам образын тудыручы сәнгать белеме клишелары кысасына җиңел кереп утыра [Султанова, 2001, с. 67–68]. Аларның күбесе шулай ук милли сәнгать элементларын «соңарган модернистик» яңалыклар белән тоташтыру, җәмгыятьтәге социаль-рухи үзгәрешләрне алдан сизү, рәсем һәм скульптурада яңа темалар ачу юлларын эзләделәр. Һәм югары дәрәҗәдәге осталыкка, масштаблы мәгънә тирәнлегенә ирешеп, моны матур, үзенчәлекле һәм лаеклы итеп башкарып чыктылар.

Ә. Фәтхетдинов, – һичшиксез, алар арасында, шушы рәттә тора, әмма сәер генә аннан читкә дә чыга. Әлеге скульптор һәм рәссамның ниндидер кабатланмас, уникаль сыйфатлары бар, бу аның иҗатына үзгәлек өсти.

Аның эшләре тудырган ауранын ашыкмыйча һәм уйланып хыялга бирелүдә булуын ирексездән сизәсең. Картиналар карашны җәлеп итеп кенә калмый, аларны озаклап һәм җентекләп карыйсы килә. Алар таныш түгел дөньяларга чакыра, тамашачыга гомер күрмәгән җан ияләрен, сәер үзгәрешләргә дучар булган кеше йөзләре һәм гәүдәләрен, хайван, кош образларын, көнкүреш детальләрен тәкъдим

итә. Бу трансформацияләр, бозып күрсәтүләр артында рәссам һәм скульптор фантазиясе генә түгел, ә тамашачыга нәрсә турындадыр әкрен генә сөйләү, аның белән үзенең тормышы, аллалар, әкияти һәм мистик үлчәмнәр турындагы серләре белән уртаклашу теләге дә яшерenә. Картиналарның рамнары якынрак килергә һәм гадәти тормышта күзгә күренмәгән, әмма яшәешнең билгесез үлчәмнәрендә яшеренгән нәрсәләргә игътибар белән карарга чакыра кебек.

Шул рәвешле Ә. Фәтхетдинов балаларча гади кызыксыну гына уятып калмый, ә тамашачының интуициясен, борынгы дәверләрдән мираска калган рациональлеккә кадәрге белемен активлаштырырга омтыла. Рәссам тамашачы белән тирән күпүлчәмле диалог кору өчен уңай шартлар тудыра. Тамашачыга автор тудырган образларга һәм дөньяларга чуму, аның тирәнгә яшеренгән уй-фикерләрен һәм хәл-халәтен аңлау, алдан белү мөмкинлеге бирелә. Шунда тәмам гаҗәпкә калган, игътибарлы, хыялый кеше алдында дөнья, инсан, Алла, чит дөньяларда яшәүче җан ияләре һәм тереклек булган серле киңлекләр турындагы тирән белемнәрне аңлау һәм белдерүдә авторның катлаулы һәм киеренке омтылышларыннан гыйбарәт очсыз-кырыйсыз офыклар ачыла. Гади һәм тыйнак сюжет, тонык палитра артында кеше рухы тудырган югары сәнгать әсәрләренә генә хас катлаулы мәгънәләр динамикасы тора. Мәгънәләрнең бер-берсенә үрелеп баруы кайвакыт масштаблы гомумиләштерүләргә китерә, яшәешнең мәңгелек серләрен аңлауга, аларның фәлсәфи (әмма һичкайчан рационалистик түгел) асылын төшенүгә якыная.

Картиналарның исемнәре үк әлеге катлаулы һәм күпүлчәмле мәгънә офыкларына кереп чумарга чакырып тора: «Яшьлек. Картлык», «Наз», «Тәңре», «Вөҗдан ирегe», «Адәм һәм Хава», «Күк иясе» һ.б.

Алар кайвакыт үтә гади чаралар белән картиналарда сурәтләнгән мәгънә агымнарның офыкларын күрсәтә. Әйтик, «Өмет» картинасы да әнә шундыйлардан.

Аның сюжеты, тематикасы, образлары бик гади кебек тоела. Малай һәм милли күлмәк кигән һәм башына җилдә җилфердәүче чәчәкле яулык япкан карчык тамашачыга арты белән юлда басып торалар. Фигуралар гадиләштерелгән, схемалаштырылган, үзәктән бераз сулгарак күчерелгән. Шул рәвешчә рәссам тамашачының карашын картинаның төп образына – сәер җемелдәп торган упкынга күчерә, соңгысы исә әлләни ерак тоелмаган офык сызыгы артында ачыла. Ерактан үзенең дөрес булмаган эллипс формасы һәм күз карасына ошаган якты табы белән ул күзне хәтерләтә. Аксыл төстә булуы белән ул ерактан күзгә төшкән акка да ошап тора. Картинаның сул өлешендә карчык һәм малай фигуралары артында урнашкан «каш»ка ошаган ак төстәге дугалар да күз иллюзиясен көчәйтә. Күзнең «керфекләре» дә бар: җиңелчә генә милли татар орнаментына ишарәләүче чәчәк-үсемлек орнаментының гадиләштерелгән сурәте. Ул хатынның җилфердәп торган яулыгындагы чәчәкләр, күлмәгенең бәби итәкләре (алар колориты ягыннан «күз» – упкынның

«керфекләр»енә караганда яктырак һәм нәфисрәк) белән яраша һәм контраст тудыра. «Җирле колорит»ка мәгънәви ишарә Казан Кремленең ике очлы башлы корылмасы: Спас һәм Сөембикә манараларының күренер-күренмәс силуэтлары белән көчәйтелә. Алар – персонажларның карашы төбәлгән упкынның да, упкынның очсыз-кырыйсыз ераклыкка этәрелүен күләгәләүче офыкның да бер өлешен тәшкил итә.

Ике кешенең әллә сукыр, әллә бүтәнчә (кеше күзе түгел, антропоморф булып тоелучы гына) «күк күзе», «яшәеш күзе» белән киеренке диалогының тирән образы әнә шулай кыска, төзек һәм чагыштырмача гади итеп тудырылган. Малай һәм карчыкның офык артында бөтенләй төрле әйберләр күрүе бәхәссез. Бала өчен бу киләчәк, яхшы, якты тормышка өметләнү һәм ул, мөгаен, Казан белән бәйле. Аның архитектурасы (аңа ишарә) картинаның уң почмагында сурәтләнгән пычрак юл, җил, корыган кызгылт агач белән кискен контраст тудыра. Рамнан тырпаеп торучы ботак эзләре дә эшкәртелмәгән корыган агач кисәге вәйранлык, фәкыйрьлек һәм җайсызлык төсмерен бик нык көчәйтә. Симметрияле рәвештә диярлек урнашкан икенче бер таяк та аны кабатлый кебек, монысының контурлары нәзек, корыган, шома. Әлбәттә, бу агач детальләрнең картина полотносына кертелүе очраклы түгел. Алар провинциаль тын һәм аулак дөньяда тере, табигый бар нәрсәнең үлүен генә күрсәтеп калмыйлар. Рәссам тарафыннан алар карчык һәм малай белән дә ассоциацияләнә (берсе вакытлар узу белән шомарып беткән, икенчесе әле сынган ботак башындагы ярыкларда аз гына булса да тормыш эзләрен саклый).

Бу детальләр барысы да, аларга салынган мәгънә офык артындагы кызыктыргыч упкын образына ике символик мәгънә бирә: бу – тормыш та, үлем дә. Мондый мәгънәви офык сызыгында упкын-«күз»дәге орнамент бизәгенә охшаш «керфекләр»нең дә капма-каршы төсмерләре билгеләнә: бала өчен табигатьнең (яки аның суррогатының) кеше тырышлыгы белән югары күтәрелгән кызыктыргыч матурлыгы, ә карчык өчен – кабер ташындагы уеп язулар турында сак кына искә төшерү яисә башка тормыш турындагы хыялларының сулган чәчәкләрне хәтерләтүе рәвешендә…

Аның яулыгындагы чәчәкләр, күлмәгендәге бәби итәкләр – әлеге мәгънәви төсмергә ишарә. Шул рәвешле рәссам сиздермичә генә әйтү юлын тапкан: хатын-кызны да кайчандыр матур хыяллар үзенә җәлеп иткән, һәм ул өлешчә гомерен шуны гамәлгә ашыруга багышлаган, тормышын хәленнән килгәнчә шуларга охшаш, хәтта яктырак һәм назлырак төсләр белән бизәгән. Әмма бәхеткә һәм җан тынычлыгына ирешә алмагандыр, күрәсең. Һәм ул авылның һәм табигый яшәешнең пычрак-хәерче киңлегендә сәер чит «тап» ка әверелгән. Ләкин ул матурлык һәм башка нәрсәләр турында хыялланудан туктамаган, күрәсең (оныгы – аның варисы, дәвамчысы). Хәтта үлем хәбәре дә аның гадәти һәм хәерче тормыш «офыгы артына» балаларча көчле тартылу теләгенә киртә була алмый.

Малай образының да әби белән охшаш төсмерләре бар (киемендәге соры-ак төсләр, басып торуларының охшашлыгы, аяк астында – бер үк юл). Аны да, бәлки, шул ук язмыш көтәдер: еректагы һәм өметле күренгән нәрсәләргә омтылыш үз тормышын ямьсезләндерүгә генә китерер. Яшәеш шартлары аның хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Ул рамның коры таягы кебек җиргә, юлга «кагылган», хәтта алга таба бер адым да ясамый. Рамның телгә алынган фрагменты юкка гына кул чугын хәтерләтүче ярык белән тәмамланмый, күрәсең: «бармак» хәрәкәтләре сулыш алуны хәтерләтә. Агач «кисәге» үзенең очы белән «күз»гә барып төртелә. Шулай итеп, әлеге детальнең тагын бер мәгънәсе туа: кызыктыргыч хыялга каршы торучы ниндидер тоткарлагыч көч; ул бу хыялны, җирдән тырпаеп торучы корыган агач куагыннан аермалы буларак, тере һәм «сулый торган» (катлы-катлы буяулардан торган импрессионистик манера) һава шарын тишкән кебек тишәргә тели. Әлбәттә, мондый очраклы детальнең барлык мәгънә төсмерләре картинадагы төп образларның символик мәгънәләре чигендә генә барлыкка килә. Бу мәгънәләрнең төрле төсмерләре авырлык белән акылга сыя, аларның «аурасы»н чамалавы да кыен. Тамашачы аны интуитив рәвештә генә тоемлый ала.

Мәгънәви «флюоресценцияләү»гә охшаш процесс картинаның башка үзәк образлары өчен дә хас, бигрәк тә төп, үзенә чакырып торучы упкын образы өчен. Анда, алда әйтеп узганча, өмет һәм үлем (хыял кебек үк) үзенә тартып тора, тормыштагы ялган һәм матурлык, шатлык-куанычлар вәгъдә итү бергә кушыла. Әмма урын һәм вакыт белән чикләнгән аныграк мәгънәләр дә бар. Әйтик, Казан үзәктән читтәге һәм йортсыз-җирсез провинциягә каршы куелган. Ассоциацияләрнең әлеге дәрәҗәсендә хыялга ирешү абстракт түгел, ә реаль төс ала, һәм малай гына түгел, ә карчык та аны җиңел генә гамәлгә ашыра ала. Бу очракта Чеховның «Өч кыз туган»ы белән диалогка керергә мөмкин булыр иде, алар да бит үзләренең балачак һәм яшьлеге белән бәйле Мәскәү турында хыялланалар: рәхәтләнеп тормышка ашырырдай булса да, бу хыял аларга ирешелмәслек булып тоела…

Әмма бу упкын-күз образының мәдәнияттә тирән тамыр җәйгән әлеге мәгънәви рәтләреннән тыш бөтенләй гадәти булмаганы да бар: ул чит дөнья затының кешегә, аның мескен яшәешенә карашы. Яшерен, тын, битараф, һәртөрле кызыксынудан мәхрүм караш, борынборыннан сукыр зат карашы, әмма ул һаман сөзеп, нәрсә турындадыр уйланып, бәлки, сорап карый... Күзе тормыш юлына, җилгә чыгып баскан әлеге ике фигурага төбәлгән затның кем булуын белергә теләп, тамашачы мең төрле фараз кыла. Әллә инде бу ялган һәм вәгъдәләр тулы тормыш үзе, әллә инде бу Алла, галәм, ниндидер аңлап һәм билгеләп булмый торган объектив чынбарлык күзе... Яисә бу күк күземе, кешелекнең үзе кебек үк борынгы мәҗүси тәңре күземе... Бу очракта хәтта космос белән аналогия үткәрергә мөмкин, чөнки аксыл төстәге үзәкне болытлар артына качкан кояш дип тә гөманлап була. Космос төсмерләре картинаның төп образы төренгән серләрне гаять

масштаблы итә, барлык мәгънәви агымнарны мистик, теге дөнья, мәңгелек, җир акылы белән генә ирешеп булмаслык яссылыкларга күчерә. Картинаның реаль сюжеты да, аның персонажлары да, азсанлы детальләре дә әлеге яссылыкларга тартып кертелә.

«Күз»нең ике төрле мәгънәгә ия булуы очраклы түгел. Ул батынкы, үзенең якты табы һәм аның тирәли боҗрасыман буялышы белән (космик тирәнлекләр һәм чит дөнья упкыннары күзе) фигураларны үзенә тартып тора. Әмма шул ук вакытта ул кабарынкы булып та күренә, чөнки аның якты «күз карасы» зиһенгә алу законнары буенча алгы планга омтыла. Ул «Казан» өстендә үк диярлек урнашкан. Мондый кабарынкылык иллюзиясендә теге дөнья җан иясенең антропоморфлыгы тоемлана, ул ике персонаж фигурасына гына түгел, ә тамашачыга да («күз»нең зур булуы аркасында) төбәлеп карый кебек. Шулай итеп, картинаның үзәк образында гәүдәләндерелгән серле көчнең масштабы кеше яшәешенең реаль киңлекләренә, аның үз һәм дөнья тарихына, кеше гомеренең чикләнгән һәм вакытлы булуына, кыйммәтләренә (хыял, өметләренә), яшәешнең мәгънәсен (тормышка ашырыла алмый торган хыяллардамы? буыннар алмашынудамы? шартлар һәм кешенең аларны җиңүгә өмете арасындагы мәңгелек каршылыктамы? акыл ирешмәслеккә һәм мәңгелеккә омтылудамы? Аллаһ белән кушылудамы? табигатьнең һәм галәмнең серләренә төшенергә омтылудамы?..) эзләүгә күчә.

Картинаның мәгънәле агымнары аннан читкә – кеше яшәеше горизонтларына чыгып кына калмый, ә тамашачыны рәссамның объектив чынбарлык турындагы гаҗәеп тирән һәм кешене мәңгегә борчый торган уй-фикерләренә дә алып кереп китә. Бу – фәлсәфи гомумиләштерүләрнең масштаблары гына дию аларны бик нык тарайту булыр иде. Философия үз сорауларын тел ярдәмендә куя, һәм ул акыл эшчәнлеге, аның кешегә хас кысалары белән чикләнгән. Ә. Фәтхетдинов ачык итеп кеше акылы (һәм фәлсәфә фәне) ирешә алмаслык офыкларга күрсәтә. Аларны тамашачының интуициясе, аның күпмедер дәрәҗәдә рациональлеккә кадәрге һәм хәтта «кешелек дөньясы туганга кадәрге» белеме-тоемлавы белән генә аңлап була, кешеләр телендә моның өчен хәтта сүзләр дә юк... Шул рәвешле упкын-күз – безнең яшәешебездә мәңге булган, бөтен процесслар белән идарә итүче, шул ук вакытта читтән генә күзәтүче, тел белән әйтеп булмый торган, акылга сыймаслык, серле, кешедән өстен көчнең чагылышы ул.

Бу мәгънәләрне картинада шулай ук танып-төшенеп була. «Күз»нең контуры бөтен сызык һәм композицияләрне тулаем колачлый һәм бер үк вакытта рамның өске ягындагы идеаль диярлек арка белән билгеләнгән күчәрне җимереп, сурәтләнгән киңлекнең үзәген күчерә. Шул рәвешле таныш булмаган чит дөнья көчләренең безнең яшәешебездә урын алуы һәрвакыт тормышка ниндидер дисгармония, киеренкелек алып килүе, аның иң әһәмиятле оештыру бәйләнешләрен үзенә тартып алуы турындагы идея бик гади һәм нәтиҗәле итеп бирелгән. Әмма ул бер үк вакытта, тормышның «соры эш көннәрендә»

ниндидер тәрәзә ачып, яшәешне бизи дә. Ул тормышка яктылык, кызыктыргыч, бик үк анык булмаса да, алдан әйтеп була торган мәгънә өсти. Мондый мәгънәле төсмер яктылыгында картинадагы кешеләр кире кагылган һәм «тормыш читенә»ташланган булып күренми. Ниндидер бөек зат (тавыш-тынсыз гына) һәрвакыт аларга карап тора. Аның аша алар кешелек дөньясына гына түгел, ә бөтен объектив чынбарлыкка, космоска, Аллага, галәмнең мәңгелек серләренә якыная. Аларның кеше буларак һәм вакыт ягыннан чикләнгәнлеге, тормышларының, акылларының, белемнәренең, телләренең, биредә һәм хәзер (пычрак юлда, җилдә, ташландык хәлдә һәм ялгызлык халәтендә) булуының чиклелеге шул рәвешле җиңеп чыгыла.

«Күз»нең Аллаһ белән бәйләнешен дә аз гына тоемларга мөмкин. Ул рамдагы кисеп-уеп ясалган бизәкләрдә төсмерләнә. Аның арка рәвешендәге рамының өстәге уң һәм сул почмакларында тупас итеп кисеп уелган каен җиләгенекенә охшаган чәчәкләр бар. Сулда чәчәк батынкы урынга гына урнаштырылган, ә уңда чәчәккә ярымай тоташа һәм ике детальне дә мөселман диненең иң мөһим атрибутына әверелдерә. Рамда тирән уемтыдагы ике чәчәк картинадагы «күз» һәм аның «керфекләр»е орнаменты белән ассоциация тудыралар. Өстәвенә рамда табигый материалга батырып эшләнгән «күз»гә ошаган ике күренеш бар. Шулай итеп, рам да картинаның динамикасын үстерүдә катнаша: рәссам шундый мәгънә булу мөмкинлегенә ишарә итә.

Күрәсең, шул рәвешле тамашачының чит дөньядан төбәлгән караш белән диалогка керүе көчәйтелгән һәм ассызыкланган, чөнки персонажлар картинаның эчендә, ә рамны кеше читтән күреп кабул итә. Тик бу «күз» нең сәер «дублер»ы яңа мәгънә төсмеренә дә ия, чөнки ул иске, тузып беткән агачка төшерелгән, ә серле көчнең бу яңа ипостасеның «күз карасы» магнит кебек үзенә тартып тормый. Шул рәвешле, автор, мөгаен, полотнода ачык һәм көчле булып күренгән серле көчнең табигатьтә үз аңлатмасы булуы турындагы фикерен белдерәдер. Ул шулай ук кешене үзенең табигый һәм таныш формалары белән җәлеп итеп, аңа мәңге һәм тын гына карап торырга сәләтле. Табигатьнең мондый «күзләре» күбрәк «сукыр», кечерәйтелгән, гадиләштерелгән һәм хәтта өлешчә гап-гади чәчәкләргә охшатып шаржлаштырылган. Мондый контекстта ярымай да дини мәгънәсен югалтып, нибары табигый тартылу белән күк җисеме арасындагы бәйләнешкә генә ишарәли.

Ә. Фәтхетдиновның «Өмет» картинасына герменевтик анализ ясау рәссамның кечкенә генә картинада бер-берсе белән үзара бәйләнгән мәгънәләрне берләштерә алуын раслый. Алар тирән, кызыклы, мавыктыргыч; тамашачыны (кайгы-хәсрәтне) бергә кичерергә этәрү генә түгел, ә актив фикер йөртергә, интуитив белемен эшкә җигәргә мәҗбүр итә. Рәссам кешенең серле, ваемсыз галәм, ә бәлки аны бар итүче алдында торуы турында гаять кызыклы уйлануларын шактый гади чаралар ярдәмендә белдерүгә ирешә. Ә. Фәтхетдинов кеше яшәешенең мәгънәсе, аның кыйммәтләре, әлеге кыйммәтләргә таянган

буыннар дәвамчанлыгы, кешенең теге дөньядагы мистик үлчәнешләр белән серле диалог кору формалары турында, һәм хәтта провинция һәм башкала мөнәсәбәтләре хакында уйлануларга этәрә…

Картинаның мондый тыгыз мәгънәле «болыт»ы (теләсә нинди, хәтта бик кечкенә генә деталь, нюанс, яктылык чишелеше, композиция, рам бизәлеше дә аны тудыруга хезмәт итә) – һичшиксез, гаять югары сәнгати осталыкның бер дәлиле. Рәссамның әлеге һөнәри тырышлык куюларының максаты – кеше һәм кешенең үз-үзе, киләчәк буыннар, хыял һәм үлем, Аллаһы Тәгалә, галәм белән бәйле мөнәсәбәте турында шәхси һәм масштаблы күзаллауларны чагылдыру. Бу яшәешнең башлангыч нигезләре акыл, тарих һәм хәтта вакыт кысаларыннан читтә ята. Нәкъ менә шул тирән һәм катлаулы фикерләү, күңел күзе белән тормышның беренчел нигезләренә төбәлү сәләте Ә. Фәтхетдинов иҗатын үз чорының башка рәссамнарыныкыннан аерып тора да. Ул, – беренче чиратта, кеше тормышындагы, табигатьтәге, галәмдәге рациональ анализларга бирелмәүчән серле күренешләргә күпкырлы һәм киң карашлы рәссам һәм акыл иясе.

Әлбәттә, бу – әлегә гипотеза гына, чөнки бер картинаны гына анализлау бу нәтиҗәне югары дәрәҗәдә дөрес дип раслау мөмкинлеге бирми. Әмма үткәрелгән тикшерену Ә. Фәтхетдиновның иҗатын, аның оригинальлеген алга таба өйрәнүнең төп юлларын билгеләргә ярдәм итә. Безнең фикеребезчә, бу юлда иң нәтиҗәлесе – картина яки скульптура турында (рәссам тарафыннан) катлаулы итеп оештырылган системалы күзаллауга нигезләнгән герменевтик алым. Анда очраклы, әһәмияте аз бернәрсә дә юк.

Анализның герменевтик ысулын XX гасырның фәлсәфи агымнары, бигрәк тә экзистенциализм белән диалог урнаштыру тулыландырырга мөмкин. «Өмет»нең мәгънәви конструкцияләренә анализ нәкъ менә шундый охшашлыкны фаразлый. Бу юнәлешнең С. Кьеркегор, М. Хайдеггер, Ж.-П. Сартр һ.б. кебек күренекле вәкилләре объектив чынбарлыкның һәм кеше яшәешенең тирән серләрен танып белүнең интуитив ысулларына өстенлек бирделәр. Нәкъ менә экзистенциалистлар шәхес, дөньяда аның катнашындагы һәм Илаһи башлангыч белән мөнәсәбәт киңлекләре арасындагы чикләрнең җуелуын үз хезмәтләренең үзәгенә куялар. Алар үлемнең киләсен алдан сизү, бетми торган курку, вөҗдан газабы кебек халәтләрнең гаять мөһим булуы турында белдерделәр. Алар кешелеккә очсыз-кырыйсыз һәм мәңгелек объектив чынбарлыкта, дөньяда яшәүнең вакытлы булуын һәм аның барыбер бер бетәсен аңларга мөмкинлек бирәләр. Шул ук вакытта кешегә юнәлтелгән тавышсыз-тынсыз «объектив чынбарлык чакыруы» турындагы идея дә аларныкы.…

«Өмет» картинасында әлеге фәлсәфи проблематиканың эзләре, һичшиксез, бар. Ул картинага ничек килеп кергән? Бу – рәссам турындагы биографик мәгълүматларны, аның эпистоляр мирасын, замандашларының бәяләмәләрен тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган тагын бер фәнни проблема.

Әмма экзистенциалистик идеяләр белән аналогияләр төзү юлында артык мавыгып китәргә ярамый, мәдәнияттә параллель рухи эзләнүләр һәм ачышлар булу мөмкинлеген һәрвакыт истә тотарга кирәк. Моны бигрәк тә дөньяны сәнгати төшенү белән эш иткәндә исәпкә алу зарур, ул еш кына белемнәрнең рациональ фәнни формулировкаларыннан алда килә, мәдәнияттә аларның тууына җирлек әзерли. Бу уңайдан гаять зур фәлсәфи потенциалга ия XIX гасыр рус әдәбияты, аның абсурд әдәбият вәкилләренең иҗаты, XIX гасыр азагы – XX гасыр башы рәссамнарының яңалыклары турында искәртү дә җитә. Шуңа күрә экзистенциализм фәлсәфәсе белән аналогияләр китерүдә без Ә. Фәтхетдинов иҗатындагы мәгънәләрнең фәнни аңга авырдан бирелгән өлкәсендәге проблемаларны чагыштырмача рациональләштерү ысулын гына күрәбез. Элегрәк ул «чагылдырып булмастай», ахырына кадәр аңлап һәм сүз белән әйтеп булмый торган өлкә дип билгеләнде. Бу планда экзистенциализм төшенчә-сүз «арсеналы» булып күренә, һәм ул Ә. Фәтхетдиновның иҗат интуициясе юнәлтелгән мәгънә офыкларын бераз гына булса да аңларга һәм тасвирларга мөмкинлек бирәчәк. Алар күп яктан рәссамны үзенчәлекле шәхес итеп формалаштырган, аның уникаль йөзен барлыкка китергән.

**Әдәбият**

*Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 175 с.

*Синцов Е.В.* Природа невыразимого в искусстве и культуре. Казань: Фэн, 2003. 304 с.

*Синцова С.В.* Художественное предвидение новых искусств. М.: Изд-во Нобель Пресс, 2013. 200 с.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960-1990 гг.). Живопись, графика, монументально-декоративное искусство, скульптура. Казань, 2001. 192 с.

*Шагеева Р.Г.* Ахсан Фатхутдинов. Казань: Рухият, 2002. 220 с.

***Синцова Светлана Викторовна,***
*филология фәннәре докторы, профессор (Казан)*

УДК 75

***Р.И. Ильясова***

# 1960–1970 ЕЛЛАР СОВЕТ СЫНЛЫ СӘНГАТЕНЕҢ ЯҢА ПАРАДИГМАСЫ ЧАГЫЛЫШЫ БУЛАРАК «6 ЯШЬ РӘССАМ КҮРГӘЗМӘСЕ» (Казан, 1970)

Статья посвящена одной из первых полуофициальных выставок молодых художников Татарстана второй половины XX в., представившей художественные поиски в живописи и графике Н.У. Альмеева, И.Н. Башмакова, Е.Г. Голубцова, Г.А. Иванова, В.А. Нестеренко, Р.Ш. Фаттахова, идущие вразрез с официальными установками социалистического реализма, отражающие увлечения авангардистскими направлениями в искусстве. Выставка рассматривается в контексте художественной обстановки в Казани на рубеже 1960–1970-х гг. Отмечается роль ведущих деятелей культуры Татарстана Б.И. Урманче и Н.Г. Жиганова в организации выставки и поддержке молодых художников. Анализируется вклад участников выставки в изобразительное искусство Татарстана в последующие годы.

**Ключевые слова:** живопись, графика, скульптура, дизайн, выставочная деятельность, искусство молодых, авангардизм, Н.У. Альмеев, И.Н. Башмаков, Е.Г. Голубцов, Г.А. Иванов, В.А. Нестеренко, Р.Ш. Фаттахов.

The article is devoted to one of the first semi-official exhibitions of young artists of Tatarstan of the second half of the twentieth century, where artistic search in painting and graphics of N.Almeev, I. Bashmakov, E. Golubtsov, G. Ivanov, V. Nesterenko, R. Fattakhov were presented. The exhibition did not correspond to the official guidelines of socialist realism, but reflected the hobbies of young artists for avant-garde trends in art. The exhibition is viewed in the context of the artistic setting in Kazan at the turn of the 1960s – 1970s. The article notes the role of the leading cultural figures of Tatarstan B.I. Urmanche and N.G. Zhiganov in organizing the exhibition and supporting young artists, and also analyzes the contribution of the exhibition participants to the fine arts of Tatarstan in the following years.

**Keywords:** painting, graphics, sculpture, design, exhibition activities, art of the young, avant-garde, N. Almeev, I. Bashmakov, E. Golubtsov, G. Ivanov, V. Nesterenko, R. Fattakhov.

1950 еллар ахыры – 1960 елларда социаль-сәяси өлкәдә шактый тиз тәмамланган «җепшеклек» чоры Россиянең төрле төбәкләрендә сынлы сәнгать үсешенә зур этәргеч бирә. Рәссамнар, бигрәк тә иҗат ирекен татып караган яшь буын вәкилләре, «социалистик реализм»-ның катгый кысаларына гына сыеша алмый. Казанның яшь рәссамнары да сәнгатьтә яңа юнәлешләрне үзләштерергә, эстетик төшенчәләрне һәм сәнгать практикаларын алыштырырга, үзләренең иҗади эзләнүләрен тамашачыга күрсәтергә омтыла. Бу җәһәттән «6 яшь рәссам күргәзмәсе» (Казан, 1970) игътибарга лаек: ул анда катнашкан рәссамнар язмышында да, республика сәнгатендә дә мөһим роль уйный. Бу мәкаләдә без күргәзмә оештыру тарихына, Татарстанның әйдәп баручы мәдәният әһелләренең бу өлкәдәге эшчәнлегенә

тукталырбыз (аларның бер өлеше бу гамәлгә каршылык күрсәтсә, икенчеләре яшь талантларга ярдәм итә), күргәзмәдә тәкъдим ителгән әсәрләргә кыскача анализ бирербез, шулай ук катнашучыларның алга таба иҗат эшчәнлегенең төп юнәлешләрен ачыкларбыз.

Татарстанның иҗат яшьләре сәнгать тарихын яңача аңларга гына түгел, ә академик сәнгать белән дә, авангард сәнгате белән дә диалогка керергә омтылдылар. Әмма ТАССР Рәссамнар берлеге йөзендә сәнгати иҗат өлкәсендәге идеологик контроль структуралары күзәтчелек итүдән туктамыйлар. Әйтик, күргәзмә комитеты яки Сәнгать советы аша уңышлы узган тәҗрибәле профессиональ рәссамнар гына күргәзмә оештыра алган. Әле күптән түгел генә сәнгать уку йортларын тәмамлаган яшьләр үзләренең «бәйсез» әсәрләрен тәкъдим итү мөмкинлегенә ия булмаганнар. Шуңа бәйле рәвештә, яшь рәссамнарга үз сукмакларын үзләренә салырга туры килгән. Шулай итеп, 1970 елның маенда Надир Әлмиев инициативасы белән «6 яшь рәссам күргәзмәсе: Н. Әлмиев, И. Башмаков, Е. Голубцов, Г. Иванов, В. Нестеренко, Р. Фәттахов» оештырыла. Һәм ул республика сынлы сәнгатендәге яңа этапның символына әверелә.

Яшь рәссам Надир Усман улы Әлмиев (1946 елгы) әле шушы елларда гына Казан сәнгать училищесын тәмамлаган Георгий Алексеевич Ивановны (1946–2012), Рөстәм Шәйгали улы Фәттаховны (1946–2019), Евгений Георгиевич Голубцовны (1949 елгы) һәм Мәскәү югары сәнгать-сәнәгать училищесы (хәзер С.Г. Строганов исем. Мәскәү дәүләт сәнгать-сәнәгать академиясе) студентлары булган Владимир Александрович Нестеренко (1947 елгы) һәм Игорь Николаевич Башмаковны (1943–2012) күргәзмәдә катнашырга чакыра. Казан дәүләт консерваториясе ректоры, танылган композитор, СССРның халык артисты Нәҗип Гаяз улы Җиһанов һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре Илгиз Кәлимулла улы Хәйруллин ярдәме белән «яшь һәм кыю» рәссамнар Казан дәүләт консерваториясенең 1967 елда төзелгән яңа актлар залының пыяла фойесында күргәзмә оештыралар (хәзер аның урынында С. Сәйдәшев исем. Зур концерт залы).

Күргәзмә оештыру өчен күп кенә мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк була. Кыска гына вакыт эчендә Игорь Башмаков күргәзмәнең символы булган «6» санын кертеп афиша һәм күкрәк билгесе эшли; Надир Әлмиев чакыру билетлары әзерли һәм аларны ул вакытта үзе эшләгән Камил Якуб исем. Матбугат комбинатында бастыра. Картиналарны әзерләү һәм элү белән яшь рәссамнар барысы бергә шөгыльләнгәннәр: Әлмиевнең пластикта эшләнгән 12 гравюрасын диварга элгәннәр, ә күргәзмәдә катнашкан һәр рәссамның 3 әр әсәрен мольбертларга урнаштырганнар.

Күргәзмәгә куелган һәм бүгенге көнгә кадәр сакланган әсәрләрнең бер өлеше рәссамнарның «җепшеклек» чорында совет тамашачысына кире кайткан рус һәм Европа авангарды мирасын тирәнтен үзләштерүләрен раслый. Шул ук вакытта бу эшләрдә оригинальлеккә

һәм үз сәнгать телен булдыруга омтылыш сизелә. Мәсәлән, Н. Әлмиевнең 12 гравюрасында иҗатының буеннан буена рәссамның үзенә генә хас үзенчәлекләрнең (темалар, сәнгать чараларын сайлау, басма графиканы ярату) чагылышын күрергә мөмкин. Н. Әлмиев әсәрләрендә һәрвакыт композицияләр һәм орнаментны үзара якынайтучы төрле график фактуралар, көчле сызыклар, киеренке ритм ярдәмендә тудырылган тирән фәлсәфи образлар өстенлек итә.

1970 елгы күргәзмәдә Владимир Нестеренконың да берничә әсәре тәкъдим ителгән була, әмма бүгенге бүгенге көндә үзенең гадәти булмаган фактурасы һәм төсләр уены белән әсир иткән «Бию» (1970) картинасы гына исән. Бу – рус бәйрәмнәренә һәм күңел ачуларына абстракциягә якын мәдхия, тыелгысыз хәрәкәтнең футуристик динамикасы.

Җитлеккән оста Евгений Голубцовның сәнгати образлары – классик композицияле, борынгы рус иконасыннан алып Европа авангардына кадәрге әсәрләргә таянып язылган монументаль формалар. Әмма бу – уен түгел, ә җитди тикшерелгән эш. Алданрак язылган һәм 1970 елгы күргәзмәдә тәкъдим ителгән «Шәһәр күренеше»ндә дә (1970) Евгений Голубцов шәһәрне геометрик өлешләргә һәм мозаик фрагментларга бүлә, конкрет архитектура пейзажында аның универсаль формуласын китереп чыгара.

Георгий Ивановның станок сәнгате, проект эшләреннән аермалы буларак, иҗатының үтә нык шәхси өлкәсе һәм дөньяны төшенүенең иң интим чикләрен чагылдыра. Аның әсәрләрендә, мәсәлән, (XX гасырның икенче яртысында яшь рәссамнарның күбесе омтылган) концептуализм юк. Табигатьнең лирик халәтләренә мәхәббәт иҗатының башлангыч дәверендә үк туа, күргәзмәдә урын алган «Көз» (1970) картинасы моның ышанычлы дәлиле булып тора – ул меланхолик рух белән сугарылган тасвирый һәм декоратив башлангычлар синтезы.

Рөстәм Фәттахов һәм Игорь Башмаковның 1970 елгы күргәзмәгә куелган әсәрләрен табып булмады. Әмма замандашларының истәлекләренә караганда, анда бу рәссамнарның яраткан темалары – иске Казанның шәһәр мотивлары тәкъдим ителгән була. Бу тема киләчәктә ике рәссамның да иҗатын билгеләячәк: Рөстәм Фәттахов үзенең иҗади импульсын тузган, әмма уңайлы архитектуралы иске Казанны, ә Игорь Башмаков үз сәнгатен, нигездә, яңа Казанга – тарихи мирас белән диалог коручы заманча динамик шәһәргә багышлаячак.

Шуны да әйтергә кирәк, үз күргәзмәләрен оештырганда яшь рәссамнар рәсми сәнгать даирәләренең каршылыгына да очрый. Мәсәлән, консерватория бинасына күргәзмә ачылышына ТАССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе Х.А. Якупов һәм сәнгать белгече Б.С. Яхлиель килә. Алар яшь рәссамнарның инициативасын җитди тәнкыйть утына тоталар һәм күргәзмәне тыюны таләп итәләр. Татар сынлы сәнгате аксакалы Бакый Идрис улы Урманче катнашыннан башка ул ачылмас та иде. Ул татар зыялыларының формаль булмаган

рухи лидеры буларак яшь рәссамнарны яклап чыга, ышанычлы дәлилләре белән Рәссамнар берлеге делегациясен күргәзмәне ачарга рөхсәт бирергә күндерә. Шул рәвешле алты яшь рәссамның беренче мөстәкыйль күргәзмәсе Казан зыялыларының игътибарын җәлеп итә. Яшь рәссамнар турында сөйли башлыйлар, ул гына да түгел – аларны таныйлар. Иҗаттагы амбицияләр, яңа карашлар, сәнгать экспериментлары, яңа темалар эзләү, бөтен дөньяга үзләрен борчыган нәрсәләр турында сөйләргә омтылу тамашачыга аеруча якын булып чыга.

Б.И. Урманче ТАССР сынлы сәнгатендә сәнгать парадигмасын алмаштыру зарурлыгын барысыннан да яхшырак аңлый һәм совет вакытлы матбугатында әлеге күргәзмә турында уңай фикерләр әйтә, «иҗади активлык, графикада һәм нәкыштә темаларны чишүдә яңа һәм кыю формалар эзләү, композициянең кискенлеген» ассызыклый, һәм «алардагы самими сәләт үсентеләрен сакларга» чакыра [Валеев, с. 3].

Ил, аерым алганда, Татарстан АССР җитәкчелеге дә җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең котылгысызлыгын аңлаган, күрәсең. Шуңа бәйле рәвештә, бөтен Советлар Союзы буенча иҗат профессияләре вәкилләрен берләштерүгә юнәлдерелгән төрле мәдәни проектлар гамәлгә куела. Мондый чаралар ил мәдәнияте һәм сәнгатенең киләчәген билгеләүче яшь талантларга булышу, шулай ук яшьләр хәрәкәтен контрольгә алу максатыннан оештырыла. Мәсәлән, комсомолның Татарстан өлкә комитеты башта «6 күргәзмәсе»ндә катнашкан яшь рәссамнарга булышлык күрсәтә, аннан аларны иҗат яшьләренең 1970 елның июнендә «Идел» Халыкара лагерында узган Беренче семинары эшенә җәлеп итә. Анда Советлар Союзының төрле почмакларыннан катнашучылар агыла [Гости «Волги», с. 3]. «6 күргәзмәсе»нең кыскартылган варианты лагерь гөмбәзе астында да эшли башлый. Цех буенча танылган хезмәттәшләре һөҗүм итүдән туктамый, тик «яшьләр һәм кыюлар» бирешеп тормый. «6 яшь рәссам күргәзмәсе» озак эшләми – консерваториядә – 3 атна һәм «Идел» лагеренда – 4 көн, әмма яшь рәссамнар өчен бик тә файдалы була. Бу аларның эзләнүләренең иҗади актуальлеген һәм җәмгыятькә кирәкле булуын күрсәтә.

«6 күргәзмәсе» 1960 еллар азагында Казандагы иң якты вакыйгаларның берсе була, ул сәнгатьтә яңа чор – «кырыс стиль» пафосының төшүе, алдагы унъеллыктагы «гади эш көннәре каһарманлыгы»ның акрынлап лиризм, камералылыкка, әйләнә-тирә дөньяны үз хисләрең һәм борчуларың аша үткәреп аңларга омтылуга күчеше белән билгеләнгән җитмешенче еллар башлануын күрсәтә.

Өч дистә елдан соң, 2000 елда, Рөстәм Фәттахов инициативасы белән, Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында «6. XXX ел» дип аталган күргәзмә ачыла, ул әлеге алты рәссамны яңадан бергә җыя һәм аларның 1980–1990 еллардагы иҗатын яктырта [XXX лет со дня проведения...]. Бу күргәзмә әлеге феноменның культурологик һәм сәнгати кыйммәтен ачып сала. Бүген, ярты гасырдан соң, Надир Әлмиев инициативасы буенча, яңа проект оештырыла, ул «Күргәзмәләр 6» ны һәм анда катнашучы һәр рәссамның кеч-

кенә ретроспекцияләрен үз эченә ала. Аларда Казан тамашачысына яхшы таныш картиналар да күрсәтелә, бу рәссамнар эшчәнлегенең аз билгеле яклары да ачыла [Улемнова, Ильясова, с. 116–123]. Нәкъ менә Н. Әлмиев 1970 елгы күргәзмәнең афишасын һәм чакыру билетын саклаган, ә В. Нестеренко остаханәсендә күргәзмәнең И. Башмаков ясаган бакыр значогы табылган. Бу һәм башка материаллар төрле еллардагы фоторәсемнәр белән бергә 2020 елда Шәһәр ратушасы залында оештырылган күргәзмә экспозициясендә тәкъдим ителде.

1970 еллардагы «6 яшь рәссам күргәзмәсе»нең анда катнашучыларның һөнәри яктан җитлегүендә мөһим роль уйнавы бәхәссез. Аларның һәркайсы үзенең уникаль иҗат телен булдырды һәм алга таба үстерде, Татарстанның сәнгать һәм иҗтимагый тормышында һәм аннан читтә дә тамашачыга үз әсәрләрен тәкъдим итте. Күргәзмәнең инициаторы – Надир Әлмиев китап һәм станок графикасы, кинематография, яктылык музыкасы сәнгатен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә; Казан кинохроника студиясендә, башкалабыз нәшриятларында эшли, «Прометей» МКБ белән хезмәттәшлек итә. Владимир Нестеренко һәм Евгений Голубцов сәнгати проектлау белән шөгыльләнәләр, без бүген аны дизайн дип атыйбыз: 1980 елларда «группа 17» конструкторлык бюросының идея илһамчылары һәм оештыручылары булып, Казанда һәм республикада күп кенә популяр җәмәгать интерьерларын бизәделәр. Рөстәм Фәттахов Казан телестудиясендә эшли, нәкыш белән шөгыльләнә. Игорь Башмаков – металл рәссамы, Казанның танылган символларына әверелгән скульптура композицияләренең авторы. Георгий Иванов Кама буе төбәгенең әйдәп баручы рәссам-проектчысына әйләнде, Яр Чаллы шәһәр тирәлеген булдыруда һәм КАМАЗның дизайнерлык эшләнмәләрендә катнашты, шулай ук актив педагогик эшчәнлек алып барды. «6 яшь рәссам күргәзмәсе»ндә катнашучыларның һәркайсы үз юлы белән барды, әмма барысы да – социалистик реализм белән бәхәстә үсеп, Татарстан авангардының «икенче дулкыны»на башлангыч биргән, милли сәнгать тарихында тирән эз калдырган рәссамнар.

**Әдәбият**

XXX лет со дня проведения I выставки молодых художников г. Казани. 6. Н. Альмеев. И. Башмаков. Е. Голубцов. Г. Иванов. В. Нестеренко. Р. Фаттахов: [Буклет]. Казань, 2000. 6 с.

*Валеев Д.* Три интервью // Комсомолец Татарии. 1970. № 75–76. С. 3

Гости «Волги» – полпреды муз // Комсомолец Татарии. 1970. № 70. С. 3

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960 – 1990 гг.). Казань, 2001. 192 с.

*Улемнова О.Л., Ильясова Р.И.* Выставка шести молодых художников. Версия 1970 // Казань. 2020. № 11. С. 116–123.

***Ильясова Рәмилә Ирек кызы,***
*Татарстан Республикасы сынлы сәнгать музее өлкән фәнни хезмәткәре, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 82-95

***Ф.Ш. Хуҗин***

## КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ МӘШҺҮР ХАТЫННАРЫ ТУРЫНДА РОМАН-ТРИЛОГИЯ

**(Иванова Ольга. Повелительницы Казани. Нурсолтан. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 495 с.; Повелительницы Казани. Гаухаршад. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 382 с.; Повелительницы Казани. Сююмбика. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 471 с.)**

В статье дана оценка, с точки зрения ученого-историка, роману-трилогии русскоязычной писательницы Татарстана Ольги Ивановой, посвященной выдающимся женщинам-повелительницам Казанского ханства: Нурсолтан – жене трех и матери двух ханов; Гаухаршад – главе правительства при хане Джанали и Сююмбике – жене трех ханов и правительнице при малолетнем сыне. По мнению рецензента, художественное исполнение, прежде всего, литературный язык произведений, показывает высокую степень совершенства; основные события и факты соответствуют данным исторических источников, а образы и события, рожденные авторской фантазией, не выходя из рамок исторической логики, служат более полной характеристике основных персонажей, определению места и роли женщин в общественно-политической жизни государства.

**Ключевые слова:** Казанское и Крымское ханства, Московская Русь, казанские и крымские ханы, Нурсултан, Гаухаршад, Сююмбика.

The article assesses, from the point of view of a scientist-historian, the novel-trilogy of the Russian-speaking writer of Tatarstan Olga Ivanova. The novel is dedicated to the outstanding women-masters of the Kazan Khanate: Nursoltan – the wife of three and the mother of two khans; Gauharshad – the head of the government under Khan Janali and Syuyumbika – the wife of three khans and the ruler with a young son. According to the reviewer, artistic performance, primarily the literary language of works shows a high degree of perfection; the main events and facts correspond to the data of historical sources, and the images and events born by the author’s fantasy, without leaving the framework of historical logic, serve as a more complete description of the main characters, determining the place and role of women in the social and political life of the state.

**Keywords:** Kazan and Crimean khanates, Moscow Russia, Kazan and Crimean khans, Nursultan, Gauharshad, Syuyumbika.

Рус телендә язып иҗат итүче Ольга Иванова исеме бүгенге татар әдәбияты дөньясында соңгы елларда гына яңгырый башлады. Аның «Повелительницы Казани» сериясеннән «Нурсолтан» исемле беренче китабы Казанның «Эксклюзив» нәшриятында 2002 елда ук басылып чыккан иде. Язучының үз акчасына нәшер ителгән бу китап, шактый гына (3 мең данә) тиражы булуга карамастан, кибетләрдә сатылмады, укучылар кулына таныш-белешләре аша гына килеп

керде, шуңа күрә, авторның исеме дә күпләр өчен билгесез булып кала бирде. «Нурсолтан»ның кайбер бүлекләре «Казанский альманах» җыентыгында һәм, татарчага тәрҗемә ителеп, «Безнең мирас» журналында басылдылар. 2017 елда Татарстан китап нәшрияты әлеге китапның икенче басмасын, 2019 һәм 2020 елларда исә шул ук сериядән «Гәүһәршад» һәм «Сөембикә» исемле яңа китапларын дөньяга чыгарды.

Мәгълүм булганча, узган гасырның туксанынчы елларына кадәр, ягъни илдә совет идеологиясе хөкем сөргән чорда, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихы белән иркенләп шөгыльләнергә мөмкинлек булмады. Хәзер исә андый мөмкинлекләр бар, әмма татар тарихын урта мәктәпләрдә укытуга чик куелды. Глобальләшү шартларында милләтебезне юкка чыгудан саклап калуда, ана телен белмәүче татарларның милли үзаңын үстерүдә тарих фәненең роле арта бара. Соңгы елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкләр тарихы институты һәм Казан федераль университеты галимнәре татар тарихының төрле чорларына караган күпсанлы хезмәтләр бастырып чыгардылар. Татарлар – укымышлы халык, фәнни әдәбиятны да үз итәләр, укып баралар, әмма аларның күбесе барыбер авыр тел белән язылган, коры фактлардан гына торган монографияләрне түгел, бәлки фәнни-популяр китапларны, бигрәк тә профессиональ язучыларның тарихи романнарын якынрак күрә.

Шөкер, язучыларыбыз ялган тарихтан туйган, дөреслеккә сусаган татар укучыларының ихтыяҗларын тиз аңлап алдылар. Әдәбиятыбызның тарихи романнар жанрына караган өлкәсе чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә татарларның борынгы төркиләр һәм болгарлар чорыннан башланып киткән тарихын чагылдырган әсәрләр белән баетылды. Казан ханлыгында булып үткән катлаулы вакыйгаларга, дәүләтнең күренекле шәхесләренә багышланган әсәрләр – Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Рабит Батулланың «Сөембикә», Флүс Латыйфиның «Хыянәт», Марат Әмирхановның «Олуг Мөхәммәд», «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», Вахит Имамовның «Сөләйман солтан», Нурулла Гарифның «Мәмеш Бирде» исемле романнары һәм тарихи кыйссалары укучылар арасында аеруча популярлык казанды.

Ольга Ивановaның «Повелительницы Казани» трилогиясенә кергән өч романы турында сүз башлаганчы, кыскача гына аның үзе белән таныштырып үтим. Ул чыгышы белән Себердән – Кемерово өлкәсенең Новокузнецк шәһәрендә туган. Әнисе – татар, әтисе – украин. Тиздән аларның гаиләсе Сочига, күп тә үтми, 1982 елда, Казанга күчеп килә. Бирелә Ольга урта мәктәпне тәмамлый, югары белем ала, бухгалтерлык эшенә өйрәнә, икътисадчы һөнәрен үзләштерә. Белеме һәм кызыксыну даирәсе буенча гуманитар фәннәрдән, филологиядән ерак торган кыз татар тарихы белән очраклы рәвештә кызыксына

башлый – кулына килеп кергән бер газетада Казан ханбикәләре турында мәкалә басылган була. Үзендә дә татар каны ага ич – ерак бабалары белән ныклап кызыксына башлый. Унбиш ел чамасы, берөзлексез диярлек, аз гына вакыты булдымы, Милли китапханәгә чаба, дәфтәренә Казан ханлыгына караган факт-вакыйгаларны теркәп бара. Әкренләп аның күңелендә китап язу теләге уяна. Җыелган материалларны яңадан бер тапкыр күңеленнән үткәрә, җентекләп анализлый, чагыштыра һәм тәвәккәлләп кулына каләм ала. Ярты елдан да кимрәк вакыт эчендә Нурсолтанга багышланган беренче китап әзер була.

Ул китапларны мин бик кызыксынып, әйтергә кирәк, ниндидер бер ләззәт белән, башта гади бер укучы, икенче тапкырында профессиональ тарихчы күзлегеннән карап укып чыктым. Беренче тапкыр укыганда мине иң шаккаттырганы – әсәрнең югары дәрәҗәдә сәнгатьчә эшләнеше иде. Авторның үз стиле: җөмләләре төзек, музыкаль яңгырашлы; сюжет сызыклары катлаулы, әмма укыганда «адашырлык» түгел, әсәрнең эчтәлегенә туры килеп тора, бер максатка буйсындырылган. Еш кулланудан таушалып беткән эпитетлар, чагыштырулар, метафоралар юк – Ольга Иванова каләменә генә хас сурәтләү чаралары. Образларның характеры, хәтта эпизодик күренешләрдә чагылып китүчеләрнеке дә, киемнәре, хәрәкәтләре, сөйләшү манералары аша тулысынча ачылган дияргә мөмкин. Автор – менә дигән психолог һәм аның шул сыйфаты образларның эчке халәтен аңларга, кылган гамәлләренең асылына төшенергә ярдәм итә. Әйтергә кирәк, психологик тирәнлек һәм сәнгатьчә камиллек трилогиянең өч китабы өчен дә хас. Әсәрне укудан тукталу кыен, ул уйландыра, нәфрәтләндерә, берүк вакытта ерак бабаларыбыз тарихы белән горурлану хисләре дә уята.

Хәзер трилогиягә кергән әсәрләргә тарихчы күзлегеннән карыйк. Бу җәһәттән мине тагын бер нәрсә шаккатырды – язучы ханымның Евразиянең Казан ханлыгы чоры белән бәйләнгән Урта гасырлар тарихын тирән үзләштергән булуы. Беренче чиратта мин аның шул чорлардан сакланып калган язма чыганакларны, архив материалларын яхшы белүенә басым ясап үтәр идем. Ул чыганаклар арасында рус елъязмалары, билгесез авторның «Казан тарихы» («Казанский летописец»), хан ярлыклары, дәүләт идарәчеләре арасында йөргән хатлар, чит ил дипломатлары калдырган истәлекләр (мәсәлән, Австрия илчесе С. Герберштейн язмалары), сәяхәтнамәләр һәм башка төрле документлар бар. Халык авыз иҗаты әсәрләреннән риваятьлегендалар, мәкаль-әйтемнәр һәм дә мәшһүр Шәрык шагыйрьләре Фирдәүси, Җами, Гомәр Хәйям, Низами, Нәваи, болгар-татар шагыйрьләре Кол Гали һәм Мөхәммәдьяр поэмаларыннан өзекләр бик урынлы кулланылган.

Ольга Иванова шул заман халыкларының этнографиясеннән дә киң мәгълүмат туплаган. Әсәрдә югары катлау вәкилләренең һәм гади халыкның, картларның һәм яшьләрнең, сугышчыларның һәм сәүдәгәрләрнең киемнәре, аш-су төрләре, көнкүреш әйберләре, эш һәм сугыш кораллары, гади йортларның һәм хан сарайларының эчке һәм

тышкы күренешләре – барысы да дөрес тасвирланган һәм бу, – беренче карашка, «вак-төяк» детальләр, укучыга шул чор атмосферасына җиңел генә кереп китәргә, әсәр геройлары белән бергә яшәргә, хәрәкәт итәргә ярдәм итә.

Табигый ки, Ольга Иванова Казан ханлыгын гына түгел, Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән башка дәүләтләр тарихын да җентекләп өйрәнгән. Миңа калса, аның язучылык эшенә керешүенең төп сәбәбе дә фәнни әдәбият белән танышканнан соң туган фикерләр, уй-кичерешләр, ә кайчакта теге яисә бу авторның фикерләре белән килешмәүдән килеп туган канәгатьсезлек хисләре булгандыр. Чыннан да, атаклы рус тарихчылары В.Н. Татищев, С.М. Соловьев, В.О. Ключевский, үзебезнең М.Г. Худяков, М.Г. Сәфәргалиев, Н.Ф. Калинин, А.Х. Халиков, С.Х. Алишев һәм, ниһаять, бүгене көн тарихчыларының хезмәтләрен алып карагыз. Әлеге галимнәр Казан ханлыгының бер гасырдан аз гына артыграк гомере эчендә тупланган серләрен ачуга күпме көч куйган?! Бер-берсенә каршы килә торган күпме фикер-фаразлар әйтелгән?! Ә сораулар кала бирә, серләр һаман да җиңел генә ачылырга җыенмый – аларның күбесе ханлык архивының тулысынча юкка чыгуы аркасында барлыкка килгән. Тарихыбызның Сөембикә, Нурсолтан һәм Гәүһәршад белән бәйле сәхифәләрен исегезгә төшерегез! Алар бит, документлардан күренгәнчә, ханнар алып бара торган сәясәтне читтән генә күзәтеп торучы назлы ханымнар түгел, шул сәясәттә актив катнашучылар да! Нишләп алар турында бик аз беләбез? Әйе, чыганаклар аз, әмма моның белән акланырга ярамый. Булганын тәфсилләп өйрәнергә кирәк! Менә шул теләк-омтылыш, минемчә, язучы Ольга Ивановадан Казан ханбикәләренең дәүләт идарәсендә тоткан урынын калкурак итеп, әмма чынбарлыкка булдыра алганча хилафлык китермичә күрсәтергә этәргәндер.

Әлеге максатка ирешүнең төрле юллары бар. Өч ханбикәне бер китапка да «сыйдырып» бетерергә мөмкин иде, югыйсә. Автор башка юлны, минемчә, иң дөрес юлны сайлаган. Һәм бу аңлашыла да. Казан ханбикәләренең бөтен тормышы, гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам иткән сәяси эшчәнлеге Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан, Касыйм, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыклары һәм Нугай Урдасы белән бәйләнгән. Әлеге дәүләтләр исә үз чиратында Мәскәү Русе, Бөек Литва кенәзлеге, Төркия (Госманлы империясе) һәм Византия белән тыгыз мөнәсәбәттә торганнар. Ольга Иванова шул дәүләтләрнең тарихын да яхшылап өйрәнгән, аларның идарәчеләре алып барган тышкы сәясәтне җиңел генә һәм бик оста итеп безнең ханбикәләр белән бәйле тарихи вакыйгаларга тоташтырып куйган, фактларны бер җепкә тезеп, бер төенгә бәйләп күрсәтә алган. Боларның барысы да трилогия авторын укучылар алдына киң эрудицияле галимә буларак күз алдына китереп бастыралар.

Кыскача гына трилогиянең беренче китабын тәшкил иткән «Нурсолтан»га тукталып үтик. Нурсолтан – Нугай далаларында туып-үскән кыз. Унҗиде яшьләр тирәсендә аны Казан ханы Хәлилгә ки-

яүгә бирәләр. Хәлил ханлык белән озак идарә итә алмый, 1467 елда яшьли гүр иясе була. Тол калган Нурсолтанны, борынгыдан килгән йола буенча, Хәлилнең энесе Ибраһим хан үзенә икенче хатынлыкка ала (беренче хатыны Фатыйма-солтан шулай ук нугай кызы була). Бу никахтан аларның Мөхәммәдәмин, Габделлатыйф исемле уллары һәм Гәүһәршад исемле кызлары дөньяга килә. 1479 елда Ибраһим хан, яшь кенә балаларын – ятим, хатынын тол калдырып, якты дөнья белән хушлаша. Мәрхүмнең өлкән хатыны Фатыйма-солтан Казанда кала, чөнки улы Илһамны әтисе урынына хан тәхетенә утыртып куялар. Нурсолтанны Кырым ханы Миңлегәрәй үзенә хатынлыкка сорый – ул бу чибәр һәм акыллы хатынны кыз чагыннан ук белгән була инде. Нурсолтан ризалыгын бирә һәм яңа гына ун яшен тутырган Мөхәммәдәминне Мәскәүгә, Иван III хозурына озатып, үзе төпчек улы Габделлатыйф һәм сабые Гәүһәршад белән Кырымга китеп бара.

Миңлегәрәйнең Нурсолтанга кадәр дә хатыннары булган, әлбәттә, әмма нәкъ менә Нурсолтан тиз арада Кырым ханының иң дәрәҗәле һәм сөекле хатынына әверелеп китә. Миңлегәрәй күзлегеннән чыгып караганда, Нурсолтан – Казан ханлыгын һәм Нугай Урдасын Кырым белән туганлаштырган илче-дипломат та әле ул. Мәскәү кенәзе белән дә дустанә мөнәсәбәттә. Шунлыктан яшь хатынның әкренләп хан киңәшчесенә әверелеп китүен аңлау бер дә авыр түгел. Вакыйгалар агышы да нәкъ менә Нурсолтан фаразлаганча: елдан-ел көчәеп барган Мәскәү кенәзе Иван III 1487 елда Казанны яулап алып, Илһамны тәхеттән бәреп төшерә һәм аның урынына Мөхәммәдәминне утырта. Төпчек малай турында да уйларга вакыт – Габделлатыйфны Мәскәүгә, шул ук Иван III тәрбиясенә җибәрергә карар кылалар. Нурсолтан Мәккә-Мәдинәгә хаҗ сәфәре кылып йөргән арада Мәскәү – Казан хәлләре бераз катлауланa: 1496 елда Мөхәммәтәминне тәхеттән куып, Себер угланы Мамыкны хан итеп куялар. Әмма озакка түгел, берничә айдан Казан тәхете (Иван III ризалыгы белән) Габделлатыйфка тапшырыла. Хакимлек итүенең беренче елларында ул Мәскәү кенәзенә тугрылыклы булып калачагы турындагы антын онытмый, әмма озак еллар Кырым шартларында тәрбияләнгән хан мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый һәм башында олугбәк Коләхмәт торган хөкүмәтнең каршылыгына очрый. Көрәш 1502 елда Габделлатыйфның тәхеттән куылуы белән тәмамлана. Аны, тоткын итеп, Мәскәүгә алып китәләр һәм Белоозерога сөргенгә озаталар. Казан тәхетенә яңадан Мөхәммәтәмин менеп утыра.

Мөхәммәтәминнең Казанга кайтуы Нурсолтанны сөендерсә, Габделлатыйф язмышы кайгыга сала. Бакчасарайдан Мәскәүгә хатлар агыла башлый. Мөхәммәтәмин дә Мәскәү кенәзеннән энесен әсирлектән азат итеп, Кырымга кайтаруын сорый. Моңа Боярлар думасы каршы килә. Нурсолтан үзе Мәскәүгә омтыла. 1510 елда ул Мәскәүдә улы Габделлатыйф белән күрешә, аннан соң Казанга юл тота, Мөхәммәтәмин янында ярты ел чамасы кунак була, 1511 елда

яңадан Мәскәүдә, әмма никадәр тырышса да улын әсирлектән азат итүгә ирешә алмый.

Нурсолтан Кырымга кайтып егыла. Монда үзенең проблемалары – Миңлегәрәй авыру, урын өстендә; уллары әтисенең Мәскәүгә кагылышлы тышкы сәясәтен хупламыйлар, солых урынына сугышны өстен күрәләр.

1515 елда Миңлегәрәй хан гүр иясе була. Шул арада Мөхәммәтәминнең озакка сузылган авыруы башлана. Ул тәхетне Габделлатыйфка калдырырга теләве турында белдерә. Казан илчеләре бу турыда Василий III кә хәбәр җиткерәләр. 1517 елның ноябрендә Габделлатыйф кинәт үлеп китә. Көтелмәгән үлемнең сәбәбен ачыклый алмыйлар, әмма ул күпләр өчен сер булмый. 1518 елда Мөхәммәтәмин дә якты дөнья белән хушлаша. Өч иренең һәм сөекле улларының үлемен күреп тирән хәсрәтләр кичергән, җитмештән артык яшәп, олы дөнья мәшәкатьләрен татыган Нурсолтан бу хәлләрдән соң озак яши алмый...

Күргәнегезчә, әсәрнең «скелеты» тарихи документлар белән расланган факт-вакыйгалардан гыйбарәт. Төп персонажларның исемнәре дөрес бирелгән, вакыйгалар хронологиясе – фәнни әдәбиятта, дәреслекләрдә күрсәтелгәнчә. Кыскасы, әсәрнең таяну ноктасы, нигезе – ныклы. Шушы «скелетка» кундырылган «ит», – әлбәттә, автор фантазиясе. Әйе, махсус уйлап чыгарылган вакыйгалар һәм аерым сюжет сызыклары да күп без тикшерә торган әсәрдә. Әмма ни хикмәт, автор фантазиясе, хәтта маҗарага якын күренешләр дә, күп очракта тарихи факт, реаль тормышта булган вакыйгалар рәвешендә кабул ителә. Чөнки алар нәкъ менә шул реаль тормышта булган вакыйгаларны тулыландыру өчен уйлап чыгарылганнар да, шуңа күрә ышандыру көче күп аларда. Моны, әлбәттә, талантлы авторның зур уңышы дип бәяләргә кирәк.

Трилогиянең икенче китабы Ибраһим хан белән Нурсолтанның төпчекләре Гәүһәршад ханәкә турында. Атаклы Олуг Мөхәммәд династиясенең соңгы вәкиле Гәүһәршад исеме тарихи документларда сирәгрәк очрый. Булган чыганакларга таянып, аның 1478–1479 еллар тирәсендә туганлыгын һәм, әнисе Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыкканнан соң, Бакчасарайда тәрбияләнеп үскәнлеген фаразларга мөмкин. Казан ханлыгындагы иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда Гәүһәршад 1530 еллар башыннан актив катнаша. Аның олуг максаты – Казан ханбикәсе булу. 1532 елда Сафа Гәрәй тәхеттән куылганнан соң оешкан яңа хөкүмәттә (диванда) җитәкчелек эшен олугбәк Булат Ширин белән Гәүһәршад ханәкәгә тапшыралар. Хөкүмәт Казан дәүләте алып барган тышкы сәясәткә Кырым ханнары йогынтысы көчәюгә каршы көрәшә. Гәүһәршад һәм аның Мәскәү яклы тарафдарлары тәкъдиме белән хан тәхетенә Касыймнан 15 яшьлек Җангали ханзадә чакырыла. Сәхиб һәм Сафа Гәрәйләр заманында мөстәкыйльлеккә ирешкән Казан яңадан Мәскәү кулына эләгә. Шәһәрдә йөзләгән рус сугышчылары пәйда була, Мәскәүдән килгән «киңәшчеләр» күбәя. Җангали балигълык яшенә җиткәч, Гәүһәршад

тәкъдиме һәм бөек кенәз Василий III рөхсәте белән аны нугай морзасы Йосыф кызына өйләндерәләр. Казан дәүләте белән чынбарлыкта Җангали түгел, Мәскәү яклы, әмма шул ук вакытта мөстәкыйльлекне дә инкяр итүдән ерак торган Гәүһәршад белән Булат Ширин идарә итә.

Василий III нең вафатыннан соң Мәскәү тәхетенә өч яшьлек Иван IV утыра. Боярлар арасында тәхет өчен көрәш туктамый. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, Казан илен үзенең төньяк биләмәсе дип санаган Кырым ханы Сәхиб Гәрәй туганнан туган энесе Сафа Гәрәйне яңадан тәхеткә кайтарырга хыяллана. Һәм аның ул хыялы тиздән тормышка да аша: 1535 елның көзендә Эчке/Иске Казан тирәсендә Җангали ханның үле гәүдәсен табып алалар. Сафа Гәрәй Казанга кайта һәм җиңел генә хан тәхетен яулап ала. «Гәүһәршад ханәкә белән Булат бәк һәм барлык Казан җире кенәз Иван Васильевичка хыянәт итте», – дип теркәп куя көндәлегенә рус елъязмачысы, әле вакыйгаларга бәя биреп. Сафа Гәрәйнең икенче мәртәбә ун ел чамасы хакимлек итү чорында Казан хөкүмәтендә Гәүһәршадка урын табылмый, әмма ул әле сәяси активлыгын югалтмаска тырыша.

1546 елда Казан аксөякләренең Мәскәүгә йөз тотучы төркеме Сафа Гәрәйне яңадан тәхеттән куа, ләкин ул тугандаш нугайлар ярдәме белән тәхетне тиз арада янәдән үзенә кайтара. Гәүһәршад һәм аның тарафдарлары каты эзәрлекләүгә дучар ителә. Кызганыч, әлеге чорга караган тарихи документлар юк дәрәҗәсендә. Гәүһәршадның 1546 ел вакыйгаларыннан соңгы язмышы билгеле түгел. Һәм бу хәл язучы фантазиясенә киң юл ача.

Укучы Гәүһәршадны Ольга Иванова тасвирлаганча кабул итә: чибәрлеге ягыннан әнисенә охшамаган, шуңа күрә үзен Аллаһ тарафыннан кимсетелгән дип саный; яшьтән үк якын туганнарыннан үзсүзле булуы һәм ирек сөючән, буйсынмаучан характеры белән аерылып тора; астыртын, хәйләкәр һәм мәкерле, интригалар остасы, шул ук вакытта зирәк акыллы, кыю һәм максатчан – морадына ирешмичә тынычланмас. Әйе, ялгыш адымнар да ясый ул, әмма максатына ирешү юлында уңышлары да күп, Ничек кенә булмасын, укучы әлеге персонажны, кайчакта бераз кызгану хисе аша булса да, яратып кабул итә, сәясәт өлкәсендә кылган гамәлләрен хуплый, бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндәге зирәк акылына, катлаулы хәлләрдән җиңел чыга белү осталыгына соклана. Ахыр чиктә бит Гәүһәршад үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртмый, дәүләт иминлеген дә күз алдында тотып эш йөртә, үзенчә тырыша. Һәм бу тарихи шәхес безгә нәкъ шуның өчен кадерле дә!

Ниһаять, трилогиянең өченче китабы – «Сөембикә». Халкыбыз хәтерендә Сөембикә образы бүген дә каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык символы буларак кабул ителә. Аның язмышы тарихыбызның бәхетле мизгелләрен дә, кайгы-хәсрәтләрен дә, киләчәккә юнәлдерелгән өмет-хыялларын да – барысын да сыйдырган. Шуңа күрә халык күңелендә саклана да ул.

Ләкин соңгы елларда һәвәскәр, хәтта фәнни дәрәҗәләргә ия булган тарихчылар арасында да Сөембикәгә башкачарак, дөресен әйтик, тискәре караш ташлаучылар да күренә башлады. Имеш, ул әхлакый яктан бозык хатын: башта Җангали ханга кияүгә чыга, ул үлгәч, Сафа Гәрәйгә «кала», гомеренең соңгы көннәрен Касыйм шәһәрендә, Шаһгали хәрәмендә үткәрә. Кырым килмешәге Кошчак белән дә гыйшык-мыйшык уйнамыйча калмагандыр, мөгаен... Казанның Явыз Иван тарафыннан яулап алынуында да Сөембикәне гаепли башладылар хәтта! Шуңа күрәдер инде, Ольга Ивановaның бу әсәрен саклык белән генә, бераз шикләнебрәк тә укый башладым – үзебезнең татарлар шулай кыланганны, безнең милләттән булмаган язучы каләменнән нәрсә чыкмас?!

Шөкер, Ольга Иванова Сөембикә образын иҗат иткәндә дә, башка тарихи персонажлары кебек, фәндә булган барлык тарихи чыганакларны нигез итеп алган. Ә ул чыганаклар Сөембикәне яман хатын итеп сурәтләргә һич тә мөмкинлек бирмиләр. Аның Казандагы тормышы (сабые Үтәмеш Гәрәй урынына дәүләт башлыгы булып торган ике ел чамасы гомерен дә кертеп) тоташ борчулардан, кайгы-хәсрәтләрдән, кагу-сугулардан торган кебек. Җангали белән никахы уңышлы булып чыкмый. Бу ханны автор, без күз алдына китерергә гадәтләнгәнчә, йомшак характерлы, сүлпән хәрәкәтле, хатын-кызга сүз әйтергә дә базмый торган пешмәгән ир заты итеп түгел, бәлки дуамал, Сөембикә кебек чибәр һәм яшь хатынына да кул күтәрергә тайчынмый торган тупас һәм усал бер адәм итеп сурәтләгән. Сафа Гәрәй белән яшәгәндә бәхетле мизгелләре дә булгандыр, әлбәттә. Әмма ханның көнче хатыннары, алар янындагы сарай әһелләре оештырган ызгыш-талашлар, чыш-пышлар, төрле интригалар Сөембикәгә каршы юнәлдерелгән була. Сөембикә тешен кысып түзә, Сафа Гәрәй вафатыннан соң башланып киткән катлаулы вакыйгаларда да югалып калмый, идарәне үз кулына ала. Язучы Ольга Иванова сурәтләвендә акыллы, кыю һәм тәвәккәл хатын буларак килеп баса ул безнең күз алдыбызга. Сөембикә ханбикәнең башка идарәчеләрдә булмаган тагын бер өстенлеген күрсәтеп үтә язучы – чибәрлеге белән түгел, гамәлләре белән абруй казанып өлгергән була ул гади халык арасында, эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәштә халык белән аралашудан ала ул көч-куәтне.

Казан фаҗигасы – Сөембикәнең шәхси фаҗигасы да ул. Ләкин аның сәбәбе Сөембикәдә генә түгел, ул бик тирәндә ята һәм тамырлары белән Алтын Урда чорына ук барып тоташа. Китапны игътибар белән укысаң, уйлансаң, туп-туры шундый фикергә киләсең.

Сөембикәнең Касыймдагы тормышы турында китапта бер сүз дә әйтелмәгән. Бәлки шулай кирәктер дә. Ханбикәнең язмышын тагын да фаҗигалырак итеп күрсәтергә теләмәгәндер язучы. Болай да аңлашыла ич.

Бәяләмәм гел мактаудан гына тора кебек. Җитешмәгән яклары да бардыр инде дип уйлаучыларга шуны әйтәсе килә: әлбәттә, бар,

ләкин алар вак-төяк детальләргә генә карый, минемчә. Мәсәлән, Урта гасырлар Казанын, хан сараен, мәчетләрне, мунчаларны мин, археолог буларак, үземчә күз алдына китерә идем. Бераз гадирәк иттереп. Безнең башкалабызны язучы матурлабрак бирә кебек: таш сарайлар, фонтаннар, биек манаралы мәчетләр, җәннәт бакчалары. Хан һәм ханбикәләрнең, бәкләрнең, бай сәүдәгәрләрнең киемнәре, бизәнү әйберләре, көн саен кулланыла торган савыт-сабалар – артык бай, кыйммәт, күбесе чит илләрдән кайтарылган. Ярый, шулай булсын, гафу итмәслек кимчелек түгел.

Данияр, Илнур, Айнур кебек кеше исемнәре артык заманча яңгырый, минемчә. Булды микән шундый исемнәр ханнар заманында? Борынгы язмаларда очрамый кебек.

Бер-берсенә каршы сугышучы гаскәрләрдәге сугышчылар саны да бераз күпертелгән. Дөрес, язучы гаебе түгел бу, елъязмачылар үзләре дә ярата шундый зур саннарны. Күпсанлы дошман гаскәрен җиңүчеләрнең дәрәҗәсе югарырак була бит инде.

«Сөембикә» романындагы Сафа Гәрәй ханның үлеме белән бәйле эпизодта бераз күңелне тырный торган тагын бер нәрсә бар. Билгесез рус авторының 1560 елларда язылган «Казан тарихы»ндагы хәбәрләренә таянып (биредә, галимнәрнең бердәм фикеренчә, уйлап чыгарылган әйберләр күп), хөрмәтле язучыбыз Сафа Гәрәйне исерек килеш мәҗлестән кайтып юынган вакытында башы белән җиз комганга бәрелеп үлгән дигән версияне китерә. Хан тикле хан сакчыларсыз йөрми, әлбәттә. Исерек булган очракта (мөселман кешесенең шул дәрәҗәгә җитеп исерүенә дә ышанмыйм мин) аны йокы бүлмәсенә кадәр озатып куярлар иде. Сафа Гәрәйне дошманнары үтергән – бу фараз чынбарлыкка күбрәк туры килә, минемчә.

Ярый, нәтиҗә ясыйк. Ольга Ивановaның без югарыда тикшергән роман-трилогиясен язучыларыбызның соңгы елларда чыккан иң яхшы тарихи әсәрләре рәтенә куярга була. Мин аны мәктәп укучыларына да, югары уку йортлары студентларына да (бигрәк тә булачак тарихчыларга), гомумән, татар тарихы белән кызыксынган һәркемгә укырга тәкъдим итәр идем. Бу китапларны укып чыккан кеше Казан ханлыгы һәм аның белән тыгыз мөнәсәбәттә торган башка дәүләтләр тарихыннан бик күп һәм дөрес мәгълүмат алачак. Тиздән аның татарчага тәрҗемәсен дә күрербез, дип ышанып калам.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты баш гыйльми хезмәткәре*

# «ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОЭПИК СҮЗЛЕГЕ» ТУРЫНДА
## (Сәфәров Р.Т., Тимерханов А.Ә., Галимова О.Н. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2019. 156 б.)

Орфоэпик сүзлекләрдә сүзләрнең әдәби телдә дөрес әйтелеш кагыйдәләре урын ала. Аларның төп максаты – әйтелеше яки басым куелышы ягыннан кыенлык тудырган сүз турында мәгълүмат бирү. Бу төр сүзлекләр башкалардан сүзне тасвирлау рәвеше белән аерыла, аларда сүзләр фәкать орфоэпик аспектта гына ачыклана.

Рус телендә, шулай ук башка телләрдә дә орфоэпик сүзлекләр эшләүнең күпьеллык традицияләре булса да, татар теленең орфоэпик сүзлекләре XX гасыр ахырында гына төзелә башлый. Х.Х. Сәлимовның «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» (1995) бу өлкәдә беренче тәҗрибә булып санала. 2004 елда әлеге автор тарафыннан төзелгән «Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге» дә басылып чыга. Сүзлек бер үк вакытта орфографик сүзлек булып та, орфоэпик сүзлек буларак та файдаланыла ала. Бу хезмәтләрдә татар телендәге сүзләрнең дөрес әйтелеш нормалары (авазларның әйтелеше һәм басым төшү), шулай ук төрләнеш вакытында әйтелешнең үзгәргән вариантлары күрсәтелгән. 2004 елдагы басмада, алдагы хезмәттән аермалы буларак, тулыландырылган лөгатьлек яңа алфавит тәртибендә бирелгән һәм сүзләрнең язылышы кириллицада да, латиницада да тәкъдим ителгән.

Татар теленең моңа кадәр нәшер ителгән орфоэпик типтагы лексикографик чыганаклары шушы ике сүзлек белән чикләнгән иде. Ниһаять, 2019 елда татар лексикографиясендә яңа хезмәт – «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» дөнья күрде. Аны Р.Т. Сәфәров, А.Ә. Тимерханов, О.Н. Галимовадан торган авторлар коллективы төзеде. Фәнни редакторы – Р.Т. Сәфәров. Х.Х. Сәлимов белешмәлекләрендәге бүгенге татар теленә хас орфоэпик нормаларны чагылдыру ноктасыннан уңышлы дип табылган сыйфатлар әлеге сүзлектә мөмкин кадәр исәпкә алынган. Кулланма яңа принциплар нигезендә үстерелүе белән кыйммәтле. Ул, хәзерге татар телендәге 4 600 дән артык актив кулланышта йөргән сүзләрдән тыш, әйтелеше язылышына тәңгәл килмәгән, басым куюда авырлык тудырган, грамматик формалары ясалганда басым гомуми кагыйдәгә буйсынып соңгы иҗеккә күчмәгән һ. б. лексик берәмлекләрне эченә алган.

Төзүчеләр нинди сүзнең лөгатьлеккә керәсен нәкъ менә шушы критерийлардан чыгып сайлаганнар. Шулай ук басымның күчүен я күчмәвен күзәтү, төрләнгән вакытта әйтелештә үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка килү һ. б. мәсьәләләрне күз уңында тотып, сүзләрнең грамматик формалары тутырып язылган рәвешен тәкъдим иткәннәр.

Татар теленең башка сүзлекләре кебек үк, бу орфоэпик сүзлек тә гамәлдәге орфографик кагыйдәләр нигезендә төзелгән, лөгатьлектәге сүзләр гамәлдәге алфавит тәртибендә бирелгән:

**куә́т** [қуў̆ә́т],
куәте́, куәткә́, куәттә́н
**куәтле́** [қуў̆әтлӗ́],
куәтлерә́к
**кубы́з,**
кубызы́, кубызга́, кубызда́н
**кувши́н** [куфшы̆́йн],
кувшины́, кувшинга́ [шы̆йңға́]
*шулай ук* [шы̆йнға́],
кувшинна́н, кувшинна́р
... һ. б.

Сүзлекнең отышлы ягы – транскрипция проблемасының заманча хәл ителүе. Татар теленең Х.Х. Сәлимов төзегән белешмәлекләрендә эзлекле рәвештә һәр сүзнең транскрипциясе тәкъдим ителгән. Басылып чыккан сүзлектә авторлар бу мәсьәләгә яңача якын килгәннәр: лөгатьлектәге сүзләрнең фәкать әйтелеш һәм язылышта аерма булган иҗек яки хәрефләр тезмәсе генә фонетик транскрипциядә бирелгән:

**авыру́** [а°ў̆ы̆ру́ў̆],
авыруы́ [руў̆ы̆́], авыруга́,
авыруда́н
**авырырга́** [а°ў̆ы̆],
авы́р, авыры́й, авырача́к
**ага́**,
агасы́, агага́, агада́н
**ага́й**,
агае́ [а°ғайы̆́], агайга́,
агайда́н
**ага́й-эне** [а°ға́йнĕ],
ага́й-энесе, ага́йэнегә,
ага́йэнедән
**агарга́**,
ак, ага́, агача́к
... һ. б.

Рус һәм башка кайбер телләрнең сүзлекләрендә шушы принцип саклана, чөнки грамматик формаларның да, баш сүзләрнең дә әйтелешен күрсәтеп бирү белешмәлекне чуарлый, кулланучының аңардан файдалануын, мәгълүматны кабул итүен катлауландыра гына.

Сүзлектә фонетик транскрипциянең нигезен моңарчы чыккан орфоэпик сүзлекләрдәге билгеләр тәшкил итә, шулай ук «Советская тюркология» журналы редакциясе тарафыннан кабул ителгән латиницага таянган халыкара фонетик транскрипциядәге кайбер билгеләр дә өлге буларак алынган. Яңа берничә билге исә авторларның фикер алышуы нәтиҗәсендә кабул ителгән. Авторлар билгеләвенчә, кайбер хезмәтләрдә [w] билгесе белән бирелгән өрелмәле ирен-ирен авазы

*тау* [та́ᵒw] һәм *дәү* [дә́w] кебек сүзләрдә катылык-йомшаклык нигезендә дифференциацияләнә, әмма транскрипциядә бу күренеш чагылмый. Шул сәбәпле сүзлектә яңа [ў] һәм [ү̆] билгеләре кулланылган:

**ба́у** [ба́ᵒў],
бавы́ [баᵒўы́], баугá,
баудáн

...

**дә́ү** [дә́ү̆],
дәүрә́к [дәү̆ᵉрә́к]

...

**сáу** [сáᵒў],
саурáк [саᵒўᵘрáқ]
... *һ. б.*

Билгеле булганча, басым сүзне оештыруда мөһим роль уйный. Күп очракта язылышлары бер үк төрле булган сүзләрнең мәгънәләрен басымны дөрес кую белән генә аерып була. Татар телендә басым һәрвакыт сүзнең соңгы иҗегенә төшә дигән караш дөреслеккә туры килеп бетми, чөнки басым төшү күп кенә шартларга бәйле. Бер иҗекле сүзләрдән тыш, басымның һәр очракта күрсәтелүе бу хезмәтнең, һичшиксез, әһәмиятен арттыра:

**ак,**
агы́ , аккá, актáн

...

**баягы́ча**

...

**бәйлә́м,**
бәйләмé, бәйләмгә́,
бәйләмнә́н, бәйләмнә́р

...

**бө́тен** [бө́төн] (һәммә)
**бөтé н** [бөтө́н] (тулы, камил),
бөтенрә́к [төнĕрә́к]
**бөтé н** [бөтө́н],
бөтенé, бөтенгә́ [төңгә́]
*шулай ук* [төнгә́], бөтеннә́н,
бөтеннә́р
... *һ. б.*

Рус, рус теле аша кергән Европа телләре алынмаларының татар телендә үзләшкәннәре дә, үзләшмәгәннәре дә бар. Шул алынмаларның әйтелеше, аларда басымның урыны, күчү-күчмәве еш кына сорау тудыра. Сүзлектә татар теленең үз сүзләре белән беррәттән, рус, рус теле аша кергән чит тел алынмаларына да урын бирелгән. Лөгатьлектә шулай ук гарәп-фарсы алынмалары да чагылдырылган:

**генера́л** [г$^{ь}$ин$^{ь}$ира́л],
генералы́, генералга́, генералда́н
**генера́ль** [г$^{ь}$ин$^{ь}$ира́л$^{ь}$]
**гер** [гĕр],
гере́, гергә́, гердә́н

...
**геро́й** [г$^{ь}$иро́й],
герое́ [г$^{ь}$иройы́], геройга,
геройда́н

...
**гыйбадә́т** [ғиба],
гыйбадәте́, гыйбадәткә́,
гыйбадәттә́н
**гыйбарә́т** [ғиба]

...
**гыйле́м** [ғилё́м],
гыйлеме́, гыйлемгә́, гыйлемнә́н,
гыйлемнә́р
... һ. б.

Бүгенге көнгә кадәр татар язма телендә фигыльнең бу формаларын куллану практикасында һәм язылышта бик күп ялгышларны очратабыз. Барлык сүзлекләрдә диярлек *у* һәм *ү* гә тәмамланган исем белән фигыль (бу очракта исем фигыль) аерып бирелми. Әмма язылыштагы ялгышлыклардан качу өчен, инфинитив формаларны аерым бирү, ягъни *у* һәм *ү* гә тәмамланган исемнәрне фигыльләрдән аерып алып күрсәтү зарурлыгы шиксез. Әлеге сүзлектә, баш сүз булганда, фигыльләр бирелгән. Фигыльләр парадигмасыннан боерык форма, хикәя фигыльнең хәзерге һәм киләчәк заман формаларының III зат берлек саны күрсәтелгән:

**гадәтләнергә́** [ғә],
гадәтлә́н, гадәтләнә́, гадәтләнәчә́к
... һ. б.

Исем фигыльләрдә, шулай ук [и] авазына тәмамланган сүзләрдә [$^{ў}$], [$^{ү̆}$] һәм [$^{й}$] аваз төсмерләре күрсәтелгән. Шул ук вакытта, урта иҗек, уртадан өзелмичә, тулысынча бирелгән. Сүз формаларында фонетик үзгәрешләр күзәтелсә, шул үзгәреш иҗеге/иҗекләре квадрат җәяләр эчендә чагылдырылган:

**гадәтләнү́** [ғәдәтләнү́$^{ү̆}$],
гадәтләнүе́ [нүү̆$^{ё́}$], гадәтләнүгә́,
гадәтләнүдә́н

...
**кенәри́** [и$^{й}$],
кенәрие́ [рийĕ], кенәригә́, кенәридә́н
... һ. б.

Сүзлектәге сүзләрнең әйтелештәге вариантлары да бирелү – аның тагын бер мөһим ягы. Беренчедән, Х.Х. Сәлимов белешмәлекләрендә бу момент күз уңыннан төшеп калган. Икенчедән, әйтелештә, язылыштан аермалы буларак, берникадәр аерма булу да норма чиген бозу булып саналмый. Авторлар, язылыш белән укылыш арасында аерма булса, сүзнең укылырга тиешле иҗеген (яки сүз тулысы белән) квадрат җәяләр эчендә күрсәткәннәр:

**бизә́ү** [зә́ӳ],
    бизәве́ [зәӳе́], бизәүгә́, бизәүдә́н
...
**гыйльми́** [ғилми́[й]]
**гыйнва́р** [ғинӳа́р],
    гыйнвары́, гыйнварга́, гыйнварда́н
**гыйшы́к** [ғишы́қ],
    гыйшкы́, гыйшыкка́, гыйшыкта́н
  *... һ. б.*

Белешмәлеккә кушымчалар кушканда әйтелеше проблемалы булган күп кенә еш очрый торган сүзләр кертелмәгән:

– химая (-сы? -се?) -се
– дая (-сы? -се?) -се
– хәя (-сы? -се?) -сы
– хәят (-ы? -е?) -ы һ б.

Шулай ук күләме дә, рус теле орфографик сүзлекләре (80 000 сүзне эченә алган) белән чагыштырганда – кимрәк. Киләчәктә әлеге авыр очракларны да теркәп, сүзлекнең күләме зурайса, аның кыйммәте, безнеңчә, тагын да артачак.

«Татар теленең орфоэпик сүзлеге», һичшиксез, уңай бәяләнергә хаклы. Ул сөйләмә тел белән бәйле белгечләр – филологлар, татар теле укытучылары, лекторлар, радио һәм телевидение дикторлары, актёрлар һ. б. өчен бик кирәкле кулланма булачак. Татар әдәби теленең нормаларын үзләштерергә теләгән башка укучыларга да ул ышанычлы норматив белешмәлек хезмәтен үтәячәк. Бер үк вакытта бу сүзлек орфографик сүзлек буларак та кулланыла ала.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2021 елның 15–16 гыйнварында** Актаныш районы төзелүгә 90 ел, Актанышка нигез салынуга 310 ел тулуга багышланган «Көнчыгыш Кама аръягының тарихи-мәдәни мирасы һәм бүгенгесе» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Чарада Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, А. Халиков исемендәге Археология институты галимнәре, Татарстан һәм Башкортстаннан төбәк тарихын өйрәнүчеләр, мәгариф һәм мәдәният оешмалары хезмәткәрләре катнашты. Конференция барышында Көнчыгыш Кама аръягының тарихи-мәдәни мирасы һәм бүгенгесе турында докладлар тыңланды, «Уфа өязе татарлары (1722–1782 елларда халык санын алу материаллары)» дип исемләнгән фәнни-тарихи белешмә басма тәкъдим ителде.

**2021 елның 22–29 гыйнварында** Г. Тукай әдәби музеенда татар әдәбияты классигы, күренекле язучы, драматург, журналист һәм тәнкыйтьче Фатих Әмирханнның тууына 135 ел тулуга багышланган «Фатих Әмирхан атналыгы» үткәрелде.

Атналык программасы кысаларында лекцияләр, мәдәни чаралар узды, социаль челтәрләрдә «Безнең Әмирхан» һәм «Фатих Әмирхан һәм Габдулла Тукай» видеопроектлары тәкъдим ителде, «Фатих Әмирхан – 135» дип аталган, квест элементлары белән оештырылган экскурсияләр үткәрелде.

**2021 елның 8 февралендә** Казан Ратушасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советының һәм Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы узды.

Утырыш Россия Фәне көне уңаеннан фән өлкәсендә югары казанышларга ирешкән галимнәрне бүләкләү тантанасы белән тәмамланды.

**2021 елның 15 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое, СССРның Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулуга багышланган «М. Җәлилне өйрәнү фәне: бүгенгесе һәм киләчәге» темасына түгәрәк өстәл үтте. Чара Татарстан Республикасы Фәннәр акдемиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылды.

Түгәрәк өстәлдә татар әдәбияты тарихында М. Җәлил иҗатының урыны, М. Җәлилне өйрәнү фәненең торышы һәм алда торган бурычлар, «Идел-Урал» легионы фаҗигасына бүгенге караш, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә М. Җәлил фонды һәм башка мәсьәләләр каралды.

Чарада галимнәр, язучылар, журналистлар, татар җәмәгатьчелеге, шулай ук онлайн форматта Мәскәү шәһәренең М. Җәлил исемендәге этномәдәни татар компонентлы 1186 нчы мәктәбе, Татарстан Республикасының Минзәлә шәһәрендәге М. Җәлил мемориаль музее, Оренбург өлкәсе Мостафа

авылындагы М. Җәлил исемендәге мемориаль музей комплексы вәкилләре катнашты.

**2021 елның 16–19 февралендә** Татарстан Фәннәр академиясендә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына һәм Халыкара туган телләр көненә багышланган Туган телләр атналыгы үткәрелде.

16 февральдә галимнәр, җәмәгатьчелек, журналистлар катнашында атналыкның рәсми ачылышы булды. Чараны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Саләхов ачып җибәрде. Түгәрәк өстәлдә катнашучыларга сәламләү сүзе белән шулай ук тарих фәннәре докторы, Висконсин университеты профессоры, Назарбаев университетының казакъ теле һәм төрки тикшеренүләр кафедрасы мөдире Юлай Шамил-оглы; Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Күмер һәм күмер химиясе институты (Кемерово) директоры, Россия Фәннәр академиясе академигы, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Зинфер Исмәгыйлев; тарих фәннәре докторы, Жусуп Баласагын исемендәге Кыргыз милли университетының археология, этнология, чыганак белеме һәм тарих кафедрасы профессоры Әнисә Бикбулатовалар мөрәҗәгать итте.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин үз чыгышында оешманың татар телен саклап калуга һәм үстерүгә, аны дәүләт теле буларак куллану өлкәләрен киңәйтүгә юнәлдерелгән күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләде. Татар халкының һәм республиканың, тулаем алганда Россия һәм БДБ илләрендәге татар диаспорасы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү юнәлешендә эшләүче Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты проектлары белән Институт директоры Искәндәр Гыйләҗев таныштырды. Татар теле өчен заманча IT-эшләнмәләр Татарстан Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институты директоры Ринат Гыйльмуллин һәм аның урынбасары, техник фәннәр кандидаты Айдар Хөсәенов докладында тәкъдим ителде.

**2021 елның 17 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр акдемиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Фольклор һәм этномәдәни үзтәңгәллек» темасына түгәрәк өстәл оештырылды. Чарада катнашучылар татар халкының этник һәм мәдәни үзтәңгәллеге, татар халкының рухи дөньясында фольклорның роле, Россия төбәкләрендә милли эпик фольклор һәм башка мәсьәләләр буенча фикер алышты.

Түгәрәк өстәлгә чыгарылган мәсьәләләр белгечләрдә зур кызыксыну уятты, фикер алышуда Казанның академик, уку-укыту оешмаларыннан фольклорчы галимнәр, тарихчылар, социологлар, этнографлар һ.б. катнашты.

**2021 елның 17 февралендә** «Сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә заманча тикшеренүләр» темасына түгәрәк өстәл узды. Чарага республиканың танылган сәнгать белгечләре чакырылган иде.

Сәнгать белеме докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире Рауза Солтанова милли-төбәк сәнгать феномены тикшеренүләре үзәккә куелган яңа хезмәтләргә күзәтү ясады. Түгәрәк өстәлдә Р.Р. Солтанованың «Татар театрының сценографиясе: төп этаплары, закончалыклары (XX–XXI гасырлар)»

монографиясе («Театраль роман – 2020» премиясе лауреаты), О.Л. Улемнованың «Мәскәү казанлылары» сериясеннән «1920–30 еллар Казан графикасы» каталоглары (Д. Жилов, Д. Красильников, Д. Мощевитин), Л.М. Шкляеваның «Урта Идел буе татарларында йорт бизәлеше сәнгате: семантикасы һәм стиль үзенчәлекләре» китаплары тәкъдим ителде.

**2021 елның 18 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Туган телләр атналыгы язма мирасны саклау һәм популярлаштыру мәсьәләләренә багышланган түгәрәк өстәл утырышы белән тәмамланды. Язма һәм музыкаль мирас үзәге эшчәнлеген яктыртуга багышланган әлеге чарада татар мәдәниятенә турыдан-туры кагылышы булган кульязмаларны, документларны ачыклау, саклау, фәнни эшкәртү һәм әйләнешкә кертү мәсьәләләре, әлеге өлкәдә ирешелгән уңышлар, перспективалар һәм проблемалар турында сүз барды.

**2021 елның 18 февралендә** Туган телләр атналыгы кысаларында Татарстан һәм күрше республикалар (Чувашия, Мордовия, Марий Эл) галимнәре, укытучылары, методистлары, Мәгариф һәм фән министрлыклары вәкилләре катнашында узган чараларның берсе актуаль мәсьәлә – Татарстан Республикасында туган телләр һәм әдәбият укытуда заманча белем бирү траекторияләренә багышланган иде. Бу – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе, бүгенге көндә Институтта «Туган тел (татар теле)», «Туган (татар) әдәбият» фәннәре буенча уку-укыту методик комплекслары эшләү буенча максатчан эш алып барыла. Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, академик, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов үзләренең чыгышларында «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында алып барыла торган бу эшне аерым билгеләп үттеләр.

**2021 елның 19 февралендә** Татарстан Фәннәр академиясендә узган Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына һәм Халыкара туган телләр көненә багышланган Туган телләр атналыгы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан бер төркем галим Татарстанның Мамадыш районында булып, мәдәният хезмәткәрләре, укытучы һәм журналистлар белән очрашты. Очрашуда галимнәр – филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов, филология фәннәре кандидаты Ильмир Ямалтдинов, филология фәннәре кандидаты Энҗе Кадыйрова республикада игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы һәм 21 февраль – Халыкара туган тел көне уңаеннан татар теле фәне, татар әдәбияты һәм фольклоры турында чыгыш ясадылар. Чарада төбәк галимнәре эшчәнлегенә дә зур урын бирелде. Мамадыш районына уздырылган комплекслы фәнни экспедиция нәтиҗәләре буларак дөнья күргән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш» җыентыгы тәкъдим ителде. Казан галимнәре Мамадыш муниципаль районы ки-

тапханәсенә Институт тарафыннан чыгарылган китапларны бүләк иттеләр.

**2021 елның 25–26 февралендә** Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү буенча комиссиясе һәм Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының мәдәниятне үстерү һәм рухи мирасны саклау мәсьәләләре буенча комиссиясенең Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә «Этнокультура һәм тел төрлелеген саклау һәм яклау – гомумроссия бердәмлеген ныгытуның мөһим факторы» дип аталган уртак утырышы үткәрелде.

Чара кысаларында «Туган телләрне саклау, өйрәнү һәм укыту мәсьәләләре», «Цифрлы трансформация шартларында милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне саклауда һәм ныгытуда граждан җәмгыяте институтларының роле», «Халыкларның үзенчәлекле мәдәниятен саклап калу: төбәк практикалары» темаларына өч секция эше оештырылды, Татарстан Республикасында этномәдәни үсеш һәм тел сәясәтенең актуаль мәсьәләләре каралды, республика тәҗрибәсе анализланды.

Утырышта Россия Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Россия Фәннәр академиясе институтлары, Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен саклау һәм өйрәнү фонды вәкилләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкилләре, милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге экспертлар, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиллеге катнашты.

**2021 елның 25–26 февралендә** Казанда Бөтенроссия фәнни конференциясе (халыкара катнашу белән) узды. Конференция Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты тарафыннан Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә оештырылды.

Конференция эшендә Россия Федерациясенең төрле шәһәрләреннән (Әстерхан, Барнаул, Йошкар-Ола, Мәскәү, Ростов-на-Дону, Самара, Саратов, Севастополь, Чабаксар), Казакъстан Республикасыннан һәм Монголиядәнiксәнгә якын археолог катнашты. Галимнәр археологик мирасны саклау, дисциплинаара комплекслы тикшеренүләр уздыру, реставрация эшләре метод һәм алымнары, археология коллекцияләрен туплау һәм исәпкә алу, фәнни экспедицияләр үткәрү белән бәйле актуаль мәсьәләләр хакында фикер алыштылар.

Конференция кысаларында шулай ук «Евразиянең төрки-татар халкының шәһәр мәдәнияте» темасына фәнни семинар оештырылды.

**2021 елның 3 мартында** К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстан Язучылар берлегенең XIX корылтае узды. Чарада Татарстан Язучылар берлегенең соңгы дүрт елдагы эшчәнлегенә нәтиҗә ясалды, язучыларга дәүләт бүләкләре һәм рәхмәт хатлары тапшырылды. Киләсе дүрт елга берлек рәисе итеп язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла сайланды.

**2021 елның 11 мартында** Казан шәһәренең «Московский» мәдәният үзәгендә «Идел буе, Урал һәм Себер татарлары: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни экспедицияләре эзеннән» дип

аталган күргәзмә ачылды. Күргәзмә Татарстан районнарында һәм Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә яшәүче татарларның мәдәниятен өйрәнү максатыннан гамәлгә ашырыла торган комплекслы фәнни экспедицияләр вакытында тупланган материалларга нигезләнә. Экспозициядә Идел буе, Урал һәм Себер татарлары этнографик төркемнәренең тормышы һәм декоратив-гамәли сәнгатенең гомуммилли һәм локаль үзенчәлекләре чагылыш таба.

Күргәзмә 2021 елның 11 маена кадәр эшләячәк.

**2021 елның 15 мартында** Татар дәүләт филармониясе Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан Хәсән Туфан иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә оештырды. Чарада күренекле җырчылар, сүз осталары, әдипләр башкаруында Хәсән Туфан шигырьләре һәм аларга язылган җырлар, шагыйрь турында истәлекләр яңгырады.

**2021 елның 26 – 27 мартында** Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында КФУ профессоры Ф.Г. Галимуллинның 80 еллык юбилее уңаеннан «Милли әдәбиятлар һәм сәнгатьләрнең багланышлары контекстында татар әдәбияты һәм сәнгате» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Чарада Татарстан Республикасы, Россия төбәкләре һәм чит илләрдән галимнәр, белем бирү оешмалары укытучылары һәм аспирантлар катнашты.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары

– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)

– аннотация (рус һәм инглиз телендә)

– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)

– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2021. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 31.03.2020. Басылды: 09.04.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла